www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 45 (1461) 17 ноябрь 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga madanizhomga
madani_zhomga

5

Кәрим Тинчурин исемендәге татар драма һәм комедия театры бу көннәрдә үзенең 90 еллык юбилеен бәйрәм итсә дә, аның иҗат коллективы һәрвакыттагыча яшь һәм тамашачыны һаман яңа премьералары белән сөендереп тора.


8-9

Михаил Худяков рус галимнәре арасыннан бердәнбер булып, Рәсәй халкына Казан ханлыгының кыргыйларча басып алынуы һәм тоташ талануы турында китап язып бирә, шуның өчен аны 1936 елда атып үтерәләр.

19

Актаныш районындагы Иске Кормаш авылы мәктәбе татар милләтенә Әсгать Сәфәргалин, Васил Маликов, Зилфәт Басыйров кебек өч халык рәссамын үстереп биргән.

Газизләрдән газиз әнкәйләр күк Илаһидыр ана теле дә!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Дума комитеты ана капиталын Россия гражданы балаларына гына бирү закон проектын хуплады.
- Мәктәп укучыларына 2024 елда математика буенча Төп дәүләт имтиханында рәсми рәвештә калькулятор кулланырга рөхсәт ителде.
- Финляндиянең чик буе хезмәте Россиядән велосипедларда илгә керүне чикләде.
- РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Россия дипломатлары белән берлектә Газа секторыннан ватандашларын эвакуацияләү эшенә кереште.
- Татарстан Республикасыннан Газа Секторына 25 тонна гуманитар ярдәм җибәрелде.
- Казахстанның Семей шәһәрендә каһарман-шагыйрь Муса Җәлилгә бюст ачылды.
- Россиянең 51 төбәгендә бензин бәясе кимеде, алты субъектында кыйммәтләнде, Татарстанда бәяләр үзгәрмәде.
- Казанда Россия Федерациясенең 28 төбәгеннән һәм Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларыннан 800 гә якын татар теле һәм әдәбияты укытучысы катнашында I Бөтенроссия туган тел форумы узды.
- Кырлайда урнашкан Габдулла Тукай дәүләт әдәби-мемориаль музей комплексында «Күн мозаика сәнгате» күргәзмәсе һәм мастер-класслар сериясе ачылды.
- Рамзан Кадыйров балалары чечен телен белмәгән түрәләрне эштән азат итәчәген белдерде.
- Кыш бабай үзенең тылсымлы поезды белән Россия төбәкләре буйлап зур сәяхәткә чыкты.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

18 ноябрь – вакуум техникасы җайланмалары ясый һәм сериялап чыгара торган Казан «Вакуумммаш» акционерлык җәмгыятенә 80 ел (1943). «Вакуумммаш» – Хезмәт Батырлыгы предприятиесе.

20 ноябрь – Татарстанның халык шагыйре, республиканың Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Шәүкәт Галиевнең (Шәүкәт Галиулла улы Һидиятуллинның) тууына 95 ел (1928-2011).

22 ноябрь – рәссам, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның халык рәссамы Ефим Александрович Симбиринның тууына 100 ел (1923–2000).

23 ноябрь – артист Газиз Исхак улы Айдарский (Вәлитов)ның тууына 125 ел (1898-1933);

– филология фәннәре докторы Илида Басыйр кызы Бәшировага 85 яшь (1938).

СЫНАМЫШЛАР

19 ноябрьдә кар яуса, кыш карлы була ● 21 ноябрьдә агачларны бәс сарса, кышын кар күп була; кич томан төшсә – тиздән җепшетә ● 22 ноябрьдән чын кыш башлана; бу көнне болытлы һәм карлы булса, майда салкын һәм яңгырлы була; яңгыр яуса – бодай уңа ● 23 ноябрьдә агачларны бәс сарса, каты суыклар көтелә; томан төшсә, җылыта.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 23 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 36 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **8 сәгать 13 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **25 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **24 ноябрьдә 7 сәгать 48 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Ноябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(20-27 ноябрь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген җөмәдел әүвәл аеның 4 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Иршад ГАФАРОВ

ДӨНЬЯНЫ КЕМ ҮЗГӘРТЕР?..

Атаклы О.Бальзакның «Банкирский дом Нусингена» исемле әсәрендә мондый җөмлә бар: «Законы – это паутина: крупные мухи сквозь нее прорываются, а мелкие застревают».

Бу әйтемне «Татаринформ» хәбәрендә энергоуниверситетның 58 яшьлек профессоры Газизуллинның хезмәт урыныннан файдаланып, студентларның белемнәрен тикшермичә генә билгеләр куеп, шуның өчен алардан 94 мең сум ришвәт алуы турында хәбәрне укыгач искә төшердем. Бу законсыз түләү дип билгеләнә. Аңа карата җинаять эше кузгатыла. Билгеле, суд утырышында ул гаебен танымый. Әмма дәүләт гаепләүчесе аны 4 елга ирегеннән мәхрүм итүне һәм 1,5 млн. сум дәүләт файдасына акча түләтүне сорый. Суд аны 2,5 ирегеннән мәхрүм итүгә һәм 800 мең түләргә хөкем итә. Иреккә чыкканда Газизуллин пенсия яшендә булачак. Пенсиянең күләмен уртача 15 мең сум дип исәпләсәк, ул калган гомеренең соңгы көненә кадәр дәүләт алдында бурычлы булып калачак.

Профессорның хезмәт хакы 25-30 меңнәр чамасы. Бу акчага бик иркен яшәп булмый шул. Совет чорын күпме сүксәләр дә, ул вакытларда профессорның хезмәт хакы тормыш алып барырга гына түгел, өйдә хезмәтче тотарга да җитә иде.

Уйлана торгач, яңа сорау туа: «Ришвәт бирүче кешегә карата җинаять эше кузгатылганмы, булса, аның нәтиҗәсе нинди?» Без бу турыда хәбәрдар түгел.

Шуның өстенә айлык хезмәт хакларың берничәшәр йөз мең, хәтта миллион сум тәшкил иткән затларның да ришвәт алудан чирканмый. Интернетта Рәсәй таможнясының башлыгы А.Бельяниновның йортында тентү вакытында аяк киеменнән бушаган тартмаларда йөз меңләгән долларлар, дистә миллион сум акча табылуы турында хәбәр күренде. Кем дә булса җавап бирә алырмы: «Хезмәт хакы гына алып, тартмаларда долларлар саклар мөмкинме?» Моны күз алдыма да китерә алмыйм! А.Бельяминовның эштән азат ителүе турында гына хәбәр булды, ә җинаять эше кузгатылу турында әлегә ишетмәдек.

Бу урында ничек инде кино героеның сүзләрен искә алмыйсың: «Абдулла, я мзду не беру... За Державу обидно!» Әлеге сүзләрне патша заманындагы таможенник авызыннан ишетәбез бит!

Яки, шулай ук интернетта Ерак Көнчыгышны үстерү программасының бик начар үтәлеше турында хәбәр бирелгән иде. Әмма моның өчен җавап бирүче Көнчыгышны үстерү министрлыгының башлыгы А.Галушка шуннан берничә ай үтүгә Ерак Көнчыгышны үстерүдәге аерым уңышлары өчен орден белән бүләкләнүенә махсус тикшерүчеләрнең дә исе киткән.

О.Бальзак сүзләренә яңадан кайтып, Дәүләт советының 17нче утырышында Санау Палатасы рәисе Алексей Демидовның чыгышына тукталасы килә. Ул болай ди: «2015 елда Санау Палатасы бюджетка 2 млрд. 56 млн. сум акча кайтарырга ярдәм итте. Безнең материаллар буенча прокуратурага закончалыкны торгызу буенча 65 тәкъдим кертелгән. Шулар нәтиҗәсендә 214 вазифаи зат хакими һәм төзәтү (дисциплинар) җаваплылыкка тартылганнар, 4-се эштән азат ителгән (укы – бүтән кәнәфигә күчереп утыртылган), 2-сенә карата җинаять эше кузгатылган». Хуҗа Насретдин әйтмешли: «Ишкәннәр икән ишәк чукмарын!» Ә берәрсе тимер рәшәткә артына утыртылганмы соң? – дигән сорауга җавап тапмадык.

Бу урында Цицерон сүзләре дә искә төшә: «Величайшее поощрение преступления – безнаказанность». Шәп әйтелгән. Дөрестән дә: «Бер сүгәрләр дә шуның белән бетәр, ә шелтә-кисәтү ул чыршы чәере түгел, бераз ябышып торыр да төшеп китәр», – дигән фикер каракларның да, ришвәтчеләрнең дә күңелләрендә яши бирә. Шулай ук И.Крыловның: «А Васька слушает, да есть», – дигән сүзләрдән соң: «Чтоб там речей не тратить по-пустому, Где нужно власть употребить», – сүзләрен дә игътибарсыз калдырып булмый.

Әлеге авторның төлке тәкъдиме белән «мәхкәмәнең чуртанны суга батырып үтерү турындагы карар»ын ничек искә алмыйсың? Хәзер дә бит, дәүләт акчасын әрәм-шәрәм итүчеләрне, ягъни каракларны, рәшәткә артына утырту урынына йә депутат итеп сайлыйлар, йә бүтән кәнәфигә күчереп утырталар. Бер дә булмаса бөлгенлеккә чыгартып, җинаять эше кузгатудан йолып калалар. Бу уңайдан интернетта очраган бер фикер бик көчле: «Для таких деятелей всегда место найдут. Создадут... какое нибудь министерство по исследованию гаек с левой резьбой». Әлеге фикер запастагы өлкән лейтенантның илнең саклык министры дәрәҗәсенә күтәрелгәч, биш ел эчендә аның ярдәмчеләренең астыртын эшләре нәтиҗәсендә ил бюджетына 3 млрд. сумлык зыян китерүе уңаеннан әйтелгән. Дөрестән дә, әлеге шәхес 2013 елның 1 декабреннән (эштән азат ителгәч) машина төзү буенча Федераль өйрәнү үзәгендә 5 млн. сумлык оклад белән генераль директор итеп, ә 2015 елның 14 декабреннән «Вертолеты России» холдингының директорлар советы әгъзасы итеп тә билгеләнгән.

Биредә Маркиз Астольф де Кюстинның «Николаевская Россия» исемле хезмәтенә дә мөрәҗәгать итәсебез килә. Ул 1839 елда берничә ай Россиядә яши һәм үзенең күргәннәре турында китап язып калдыра. Әлеге хезмәтне Рәсәйдә бастырмыйлар, анда патша күңеленә хуш килмәгән фикерләр күп була. Әйтик, ул болай язган: «Россия – это страна, в которой правительство говорит, что хочет, потому что оно одно имеет право говорить».

Без бу сүзләргә А.Д.Медведевның хезмәт хакы түбән булуга зарланган укытучыларга бизнес белән шөгыльләнергә яки ничек булса да бүтәнчә акча эшләү юлларын эзләргә киңәшеннән соң игътибар иттек. Үзе турында ул: «Я выбрал аспирантуру и преподавание на низкой зарплате. И чтобы сводить концы с концами, читал много лекций и вел много семинаров». Билгеле, бу сүзләргә югары уку йортында эшләмәгән кеше ышанырга да мөмкин. Тик, беренчедән, аспирантлар лекция укыган югары уку йортларында студентлар нинди белем алды икән, дигән сорау туа, чөнки бу эш бары тик профессорларга, бер дә булмаса доцентларга гына рөхсәт ителә иде. Шәт шундый «аспирант-лекторлар» сүзен тыңлаганга, ул үзе дә хәзер шулай фикерлидер. Икенчедән, лекция һәм семинарларның күләме уку елы башланганчы ук билгеле була һәм ул ел барышында үзгәрми, шулай икән, кайда да булса өстәмә лекция уку мөмкинлеге буш сүз генә булып кала.

Сүзебезне дәвам итеп, чираттагы язучыга мөрәҗәгать итик. Заманында Ф.Мольер болай дип яза: «Многочисленность законов в государстве есть то же, что большое число лекарей: признак болезни и бессилия». Укучылар игътибар итәдерме – Дәүләт Думасында да, Федерация Советында да һәр чакырылышта дистәләгән канун кабул ителә. Кайсы вакытта: «Депутатлар алар белән танышып чыгарга өлгердеме икән?» – дип уйлап та куясың.

Мәсәлән, С.Миронов: «Алтынчы чакырылышта без Кырым буенча гына да 132 канун кабул иттек. Соңгы утырышта да 40 тан артык канун әзерләмәсен карадык», ди. Кирәкме икән соң вакыт уздырып, кәгазь әрәм итеп, шулкадәр канунннар кабул итәргә? Әгәр безнең җитәкчеләр китапны карандаш тотып укыса, бәлкем бу турыда уйланыр да иде. Чөнки Д.Локкның бик акыллы сүзләре бар бит: «Создавайте лишь немного законов, но следите за тем, чтобы они соблюдались».

Кайсыбер чакларда башка сыймаслык очраклар да була. Мәсәлән, күптән түгел авылдагы хуҗалыкларны терлек һәм кош тизәкләрен эшкәртү һәм зарарсызландыру турында тиешле оешмалар белән килешү төзүне таләп итә торган канун кабул ителгән. Бу эшләнмәгән очракта эшмәкәрләр җавапка тартылачак. Ә андый оешмалар әлегә республикада бөтенләй юк. Шуңа да Р.Н.Миңнеханов: «Исем китә, безнең илдә нинди генә ахмаклыклар кабул ителми. Фермаларда тирес ул калдык-пыстык түгел, ә киләчәктә кырчылыкта файдаланыла торган әйбер. Ул ашлама бит!» Шуннан аның залда утыручы Дәүләт думасы депутаты А.Сидякинга мөрәҗәгать итеп: «Сез анда ник кешеләрне мыскыллыйсыз?» – дигән сүзләрен залдагылар алкышлар белән кабул итә. Р.Миңнеханов: «Беркайчан тирес күргәннәре юк, авылга барганнары юк, белмим, нәрсә уйлап чыгаралар. Тормышта берни дә күрмәгән кешеләр ахмак канунннар кабул итә. Гомумән, терлекчелек тиресссез яши алмый. Хәтта сүз дә таба алмыйм», – дип чыгышын тәмамлый.

(Дәвамы 4 нче биттә).

ТАТАРСТАН – Идел буеның фәнни үзәге

Татарстан Фәннәр академиясендә урта гасыр тарихында иң кызыклы чорларның берсенә багышланган Альфред Халиковның «Идел белән Урал арасында Бөек Венгрия», Геннадий Белорыбкин, Искәндәр Измайлов, Олег Мельниченко, Татьяна Осипова, Артем Павлихин, Альфред Халиков авторлыгында тупланган «Армиёв грунт-курган каберлеге» басмасы һәм Татьяна Никитинаның «IX-XI гасырларда Ветлуга һәм Нократ елгалары арасында яшәгән халыкларның бил каешлары» китаплары тәкъдим ителде.

Фойеда зур булмаган Археология институты чыгарган китаплар һәм Идел-Уралдагы угыр-мажарлар тарихына бәйле Урта гасырның башлангыч чорына караган күмү комплексларыннан әйберләр күргәзмәсе оештырылган иде.

Чарада Татарстан Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов, Венгриянең Казандагы генераль консулы Сергей Сюч, Петер Пазманя исемендәге Католик университеты профессоры Атилла Тюрк, Пенза өлкәсенең Төбәкне үстерү институты ректоры Геннадий Белорыбкин, В.М. Васильев исемендәге Мари тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты директоры Людмила Григорьева, Татарстан Фәннәр академиясе карамагында эшләүче институт директорлары һәм хезмәткәрләре, музей-тыюлыклар җитәкчеләре һ.б. катнашты. Фәнни җәмәгатьчелек арасында Казандагы дипломатик корпус җитәкчеләрен һәм вәкилләрен күрү, аларның фикерләрен ишетү көтелмәгән яңалык булды.

Чыгыш ясаучылар, фикер алышучылар тарафыннан югарыда телгә алынган хезмәтләрнең һәркайсына югары бәя бирелде. «Бу хезмәтләрнең дөнья күрүе – халыкара дәрәҗәдә фән үсешенә җитди өлеш кертү, – дип билгеләде тарих фәннәре докторы Искәндәр Измайлов. – Аларны нәрсә берләштерә, дип миннән сорадылар. Альфред Хәсәновичның шәхес булуы. Мари республикасында беренче тикшеренүләрне ул башлады һәм борынгы мари каберлекләрен ачты. Аның ярдәмендә Зур Тигәнәле һәм Армиёв каберлекләре тикшерелеп өйрәнелде. Армиёв каберлеген әле ахырга кадәр аңлап бетерү кирәк. Анда бортаслар яшәгәне ачыкланды. Ләкин кемнәр алар бортаслар, токымнары кем икәнлеген без белмибез».

Татьяна Никитинаның китабы Венгриядәге Петер Пазманя исемендәге Католик университеты белән В.М.Васильев исемендәге Мари тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтының хезмәттәшлек нәтиҗәсе. Будапешта ике телдә нәшер ителгән китап мари халкы тарихында әлегә бердәнбер. Автор үзе белдергәнчә, бу эшнең башлангычы гына, алда әле бик күп тикшеренүләр көтә.

Әйтергә кирәк, Венгриянең Казандагы консуллыгының саллы ярдәм күрсәтүенә, хәтта шәхсән генераль консул Сергей Сючның чарада катнашуына карата рәхмәт сүзләре яңгырады. Пенза өлкәсенең Төбәк үсеше институты ректоры Геннадий Белорыбкин Армиёв каберлеге буенча хезмәтләрнең 30 ел элек чыгарга тиешлегенә басым ясап, «без остазыбыз алдында үз бурычыбызны үтәдек», – диде. Чыннан да, шактый еллар буе Археология институтының фәнни фондында тузаннар астына күмелеп, үз чиратын көтеп яткан хезмәтләрнең нәшер ителүе, киң катлам җәмәгатьчелек һәм чит ил вәкилләре алдында зурлап тәкъдим итү, ниһаять, Татарстан Фәннәр академиясе җитәкчелегенең бу юнәлешкә йөзе белән борылуын аңлата.

Идел буе төбәкләрендәге фәнни институтларның Татарстан Фәннәр академиясе белән хезмәттәшлек итәргә тартылуы, галимнәрнең бер-берсе белән килешеп, үзара аңлашып эшләргә тырышуы, республиканың җитди фәнни үзәк булып формалашканын күрсәтүче бер дәлил икәнлеген билгеләп үтмичә мөмкин түгел.

Тагын шуны да искәртик. Китапларны тәкъдим итү гадәттәгечә, тапталган сүзләр сөйләп, академик рәвештә түгел, ә киресенчә фән флагманнарының түгәрәк өстәл артына җыелып, дустанә мөнәсәбәттә, үзара эшлекле фикер алышу формасында барды. Шуңа күрәме, киң танылган абруйлы галимнәр дә нотыкларын озын-озакка сузмыйча, конкрет фикерләр белән чикләнде.

«Дипломатик һәм консуллык корпуслары вәкилләренең катнашуы яхшы күренеш, бу безгә киләчәк өчен стимул бирә, – дип, күтәренке рухта сүзен тотты тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев. – Коллегаларыбыз белән күрешеп, аралашуыбыз бик әйбәт, чөнки киләчәктә дипломат корпусларының фәнни эзләнүләрдә ярдәм итүе бик мөһим булачак. Әйтик, Кытайда барлыкка килгән татар диаспорасын бергәләшеп өйрәнә алабыз. Шулай ук, XIX гасыр ахырында татарларның Госманлы империясенә миграциясе зур кызыксыну уята. Бүгенге чара безгә киләчәктәге перспективалар, хезмәттәшлек өчен нигез бирә. Фәннәр академиясендә шундый чара узуына бик шат».

Үз чиратында Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов исә татар диаспорасы белән генә чикләнмәскә кирәклеген искәртте. «Безнең ата-бабаларыбыз кайдан килеп чыккан, башлангычта кем булган һәм нәрсәгә килгәнбез: венгрлargамы, татарларга яки башкортларгамы? Менә шуннан чыгып эш итәргә кирәк. Без кинрәк карарга тиеш», – дип мөнәсәбәтен белдерде ул.

Һәрхәлдә, Татарстан Фәннәр академиясенең, А.Х. Халиков исемендәге Археология институтының, Венгриянең Казандагы консуллыгының, Венгриянең Петер Пазманя исемендәге Католик университетының һәм В.М. Васильев исемендәге Мари тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтының бергәләшеп башкарылган эшләргә нәтиҗә ясап, киң катлам җәмәгатьчелеккә олы хезмәтләрне тәкъдим итү киләчәктә дә менә шундыйрак юнәлештә хезмәттәшлекне дәвам итәргә кирәклегенең өлгесе буларак катнашучылар һәм кунаклар күңелендә истә калачагына шик юк. Ә республика фәнни даирәсе өчен бу чара елның мөһим вакыйгасы буларак тарихта калыр.

Мөнирә СӘГЫЙДУЛЛИНА.

Халыкның асыл рәссамы

10 ноябрьдә Татарстанның халык рәссамы, график һәм монументаль сәнгать остасы Рөстәм Килдебәков 90 нчы яшендә вафат булды.

Рөстәм Килдебәковның монументаль-гамәли сәнгать өлкәсендә, станок рәсеме, графика, гобелен сәнгатендә күпкырлы таланты бар иде. Казанның тарихи рәвешенең бер өлеше булган объектлар: «Идел» кунакханәсе бинасы фасадындагы «Казан – биш диңгез порты», тимер юл вокзалы фасадындагы «Казан – Татарстан башкаласы», Казан милли тикшеренү технология университеты корпусы фасадындагы «Химия» сграффитолары һ.б. бик күпләр аның катнашында бизәлгән.

Килдебәков 1934 елның 30 мартында республика башкаласында туган. 1954 елда Казан сәнгать училищесын, 1960 елда Львов гамәли һәм декоратив сәнгать институтын тәмамлый. 1961 елдан 1998 елга кадәр сәнгать фондының татар бүлегендә эшли. 1987 елда СССР Рәссамнар берлегенә кабул ителә, Татарстан Рәссамнар берлеге идарәсе әгъзасы була.

Рәссамның күпкырлы иҗади эшчәнлеге күп бүләкләр белән билгеләп үтелә. Алар арасында «Фидакарь хезмәт өчен», «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медальләре, «ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе», «Татарстанның халык рәссамы» һәм «Россия Федерациясенең атказанган рәссамы» кебек мактаулы исемнәре бар.

2011 елда Килдебәков автордашы, тугры тормыш иптәше Мария Семеновна белән берлектә Тукай премиясенә лаек була. Татарстан Республикасы дәүләт бүләген алар шагыйрь иҗаты нигезендә монументаль рәсем сәнгате әсәрләре һәм татар халык әкиятләре мотивлары буенча кулдан туку техникасында башкарылган гобеленнар сериясе өчен («Су анасы», «Сак-Сок», «Шүрәле» триптихы) ала.

«Соңгы көннәренә кадәр Килдебәков үз эшенә, мәдәнияткә һәм сәнгатькә тугры калды. Иҗат еллары күренекле осталар плеядасын тәрбияләде. Ул креатив фикерләве, яңалыкка ачык булуы, ихласлыгы, кешеләклелеге, күңел җылылыгы, хезмәттәшләре һәм укучылары турында кайгыртуы белән аерылып тора иде. Талантлы рәссам турында якты истәлек безнең йөрәкләрдә мәңгегә сакланыр», – диелә некрологта.

Кайгынамәне Татарстан Рәисе Р.Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе М.Шәймиев, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин, Татарстан Премьер-министры А.Песошин, Татарстан Рәисе Администрациясе җитәкчесе Ә.Сәфәров, Татарстан Мәдәният министры И.Әюпова, Казан мэры И.Метшин һ. б. имзалаган.

Салисә Гәрәеваны хөрмәтләү

Ноябрь аенда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, танылган шагыйрә Салисә Гәрәевага 85 яшь тулды. Шушы уңайдан шагыйрәнең туган ягы – Минзәлә районы Тулбай авылында авылдашлары, туганнары, язучылар, журналистлар, район хакимият вәкилләре, киң җәмәгатьчелек катнашында Салисә Гәрәевага атап монумент ачылды һәм әдәби-музыкаль кичә булып үтте.

Салисә Гәрәева Тиргәвеш һәм Сармәт инешләре арасында урнашкан Тулбай авылы гүзәл табигатенең матурлыгыннан илһам алып, сандугачлы тугайларында уйнап үскән. Беренче иҗат җимешләре дә шунда туган. Соңыннан да шагыйрәнең күп кенә шигырьләре туган авылына багышлап язылуы гаҗәп түгел.

Монумент ачу тантанасында Минзәлә муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе Аида Биктимерова искәрткәнчә, С.Гәрәеваның шигърияттә талантлы шагыйрә булып танылуында туган ягының да тәэсире зур.

Ырыс авыл җирлеге башлыгы Ильмира Аксюкова исә С.Гәрәеваның авылдашлары, районнардашлары өчен зур горурлык булуын белдерде. Тулбайның үсеп килүче яшь буыны, авылдашлары Салисә апаның шигырьләрен яттан белүе белән куандыра. Әлбәттә, тулбайлыларның шагыйрәгә булган ихтирамы монумент куюга этәргән.

Монументны Ырыс авыл җирлеге башлыгы Ильмира Аксюкова һәм Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин ачты. Монументны, ташландык йорт урынын чистартып, үзара салым акчасына торгызганнар. Илмира ханым алга таба монумент янында Салисә Гәрәева исемендәге парк та төзеләчәген әйтте. Аның эскизлары әзер икән инде.

Аннары тантана мәдәният йортында дәвам итте. Язучы Ф.Сафин чыгышын шагыйрь Зөлфәтнең «Шагыйрь тудырган ана – бөек ана, шагыйрь тудырган авыл – бөек авыл!» – дигән сүзләрен искә төшерүдән башлады. Тулбай да татар дөньясына С.Гәрәеваны биргән. Шагыйрә Тулбай һәм Минзәлә тарихында бөек татар телен сөюе белән истә калачак. Ф.Сафин С.Гәрәеваның Чиләбедә иң беренче әдәби берләшмәне төзүен искә төшерде. Акмулла исемендәге әлеге китапханәдә Салисә ханымны хәзер дә сагыналар.

Танылган журналист, 30 ел дәвамында «Татар мөселман календаре»н чыгарып килүче Фәния Хуҗахмәт исә мондый монументның беркайда да булмавын, аның куелуы республиканың барлык районнарына да үрнәк гамәл икәнен искәртте. Чыгышлар Салисә апаның шигырьләрен сөйләү, аның сүзләренә язылган җырларны башкару белән үрелеп барды. Тулбайда яшәүче Зөлфирә Гәрәева Салисә апаның 40 лап шигырен яттан белүе белән истә калды. Җырле композитор Рөстәм Әхмәтханов С.Гәрәева сүзләренә язган җырларны башкарды.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотосы.

1 нче биттә – Айсылу Лотфуллина.

ДӨНЬЯНЫ КЕМ ҮЗГӘРТЕР?..

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Безнең карашка, маркиз де Кюстин моңа кирәкле сүз тапкан: «Россией управляет класс чиновников, прямо со школьной скамьи занимающих административные должности». Дөрес, хәзерге заманда мәктәптән үк булмаса да, югары уку йортын тәмамлагач, бер көн дә завод-фабрикада яки бүтән җирдә эшләмичә җитәкче кәнәфиенә менеп утыручылар аз түгел.

Билгеле, шул чаклы күп кануннарны үтәүне тәэмин итү дә җиңел түгелдер. Шуның өстенә аларның кайсыберләренең бер-берсенә капма-каршы килү очраклары да була. Җитмәсә, рәислек итүчеләрдән, җитәкчеләрдән аларны үтәүне катгый рәвештә таләп итү дә юк.

Кануннарның бозылуын да ассызыкламый булмый. Бу гади кануннарга гына түгел, илнең төп кануны булган Конституциягә дә кагыла. Аның 43 маддәсенең икенче өлешендә: «Граждане России имеют право на получение основного общего образования на родном языке, а также на выбор языка обучения в рамках возможностей, предоставляемых системой образования в соответствии со ст. 6 Закона «Об образовании»», – дип язылган.

2002 елның 30 августында III нче Бөтендөнья татар конгрессында ясаган чыгышында В.Путин: «Полная дурь и бред, если кто-то где-то запрещает в многонациональной стране изучать родной язык или препятствует этому... Абсолютно недопустимо, если кто-то говорит о том, что нужно сокращать изучение родного языка...»

Халыкта, шул исәптән русларда да: «Уң кул сулының ни эшләгәнен белми», – дигән әйтем бар. Әгәр ул аны белсә яки бу турыда аңа әйтсәләр, 2007 елның 1 декабрендә гомуми белем бирү мәктәпләренең программасыннан милли компонентны алып ташлау турындагы фәрманга кул куймас иде.

Бу инде милли мәктәпләрнең һәм гимназияләрнең ябылуларына, ә туган телләр предмет буларак кына укытыла торганнарында аның юкка чыгуына ук китерергә мөмкин. Шуның өстенә, оптимизация (укы – «яптымизация». – **И.Г.**) сылтавы белән балалар аз булган мәктәпләрне бергә кушып, рус телендә укытуга күчерәләр.

Хәзер мәктәпләрдә укытуны рус телендә алып бару концепциясе буенча фикер алышу бара. Аның нигезендә барлык фәннәрне дә бары тик рус телендә генә укыту күзаллана. Дөресләктә, ул милли мәктәпләрне юкка чыгаруга юнәлтелгән. Хәтта коммунистлар чорында да туган телдә белем алуга комачаулык тудырмадылар, ә үз чиратында укучылар ныклы белем алды. Моны туган мәктәбебезне ана телендә тәмамлап, төрле, шул исәптән төгәл фәннәр буенча да, докторлык һәм кандидатлык диссертациясе яклаган берничә дистә якташларым мисалында раслый алам.

Заманында К.Д.Ушинский: «Когда исчезает народный язык, – народа нет более», – дип язган иде. Ул хәзерге мәктәптә бер дәрес тә бирмәгән түрәләрдән акылсызрак булмагандыр. Ул шулай ук башлангыч мәктәптә туган телдә укытуның кирәклеген искәртә, тик шул вакытта гына бала катлаулы сүз төркеме төзи ала дип ассызыклый. Бу уңайдан СССРның булачак тышкы эшләр буенча халык комиссары Г.В.Чичеринның бертуган сеңлесе С.В.Чичеринаның сүзләренә дә тукталасы килә. Ул 110 еллар элек Чүпрәле якларындагы мәктәпләрдә имтиханнар уздыра. Аларның нәтиҗәсе турында түбәндәгеләрне яза: «Оказалось, что в тех школах, где преподавание шло на родном языке детей, ученики сдали экзамен удовлетворительно. Ученицы же школы, где учительница была русской, и преподавание велось все время на русском языке, совсем не могли сдать экзамен». Бу сүзләргә шәрехләү кирәк түгел. Бер уңайдан татар язуын латин хәрефләренә күчерүне тыю, бердәм дәүләт имтиханнарын бары тик рус телендә генә бирдерүне дә искә төшерергә кирәк.

Безнең халыкта: «Урман авызындагы күренә, борын астындагы күренми!» – дигән мәкаль бар. Элек тә, хәзер дә гаммәви мәгълүмат чыганакларында зур кайгы хисе белән Балтыйк буе илләрендә, Украинада рус телле мәктәпләрнең ябылуы турында сөйлиләр. Шул ук вакытта Рәсәйнең үзендә ничәмә-ничә йөзләгән милли мәктәпләрнең ябылуы турында бер кәлимә сүз дә ишетелми.

Бу урында 2016 елның 1 апрелендә интернетта урнаштырылган хәбәргә дә тукталасы килә. Япониядә Кю-Сиратаки тимер юл станциясен ябарга теләгәннәр. Ләкин бу тукталыштан бердәнбер пассажир – кыз баланың мәктәпкә укырга йөрүе билгеле булгач, бу эшне 3 елга кичектерәләр. Ул укуын тәмамлагач кына, станция эшләүдән туктый. Шулай булгач, табигый байлыклары юк дәрәҗәсендә, мәйданы кечкенә булган илнең нык үскән икътисадлы булуына гаҗәпләнергә урын калмыйдыр кебек.

Телгә генә түгел, хәтта намус ирегенә дә киртәләр шактый. Бу турыда Кюстин түбәндәгеләрне язып калдыра: «Религиозная нетерпимость является главным рычагом русской политики. Терпимость к иноверной церкви в России не гарантируется ни общественным мнением, ни государственными законами». Фикеребезне берничә сан белән генә раслыйк. 2012 елның 28 июнендә Пекин шәһәрендә – 70, Лондонда – 100, Нью-Йоркта 140 мәчет булса, ике миллион мөселман яшәгән Мәскәү шәһәрендә алар бары 4 кенә.

Чех язучысы З.Плугаржның «Если покинешь меня» исемле китабын укыганга инде ярты гасыр артык вакыт үтте. Шуңа да карамастан аның: «О культуре, развитии народа можно судить по двум вещам: дорогам и сортирам», – дигән сүзләре һаман истә тора. Дөрес, әйтемнең икенче өлеше буенча шактый гына эшләр башкарылды. Казанлылар Бауман урамының ишек алларындагы, тактадан ясалган бәдрәфләрне хәтерлидер. Кызганычка каршы, калабызга килгән кунаклар четерекле хәл калды, чөнки Тукай мәйданындагы метрода хаҗәтеңне үтәү өчен 10 сум, шунда урнашкан кибетнең икенче катында инде 20 сум түләргә кирәк. Акчаң булмаса, Җәлил урамындагы бушлай бәдрәфкә йөгерергә туры килә...

Инде юллар мәсьәләсенә килсәк, эшләр катлаулы. Заманында Наполеон: «Россиядә юллар юк, юнәлешләр генә бар», – дип әйткән. Рәсәйгә кагылмыйча, республика турында гына сүз йөртик. «Татарстан Республикасы тәҗрибәсендә авыл юлларын төзекләндерү» исемле Бөтенрәсәй киңәшмәсендә транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Л.Сафин чыгышыннан күренгәнчә, республиканың 3073 торак пунктының 748-ендә каты өслекле юллар юк. Алай гына да түгел, шәһәребезнең кайсыбер ишек алларыннан да җиңел машина белән үтү өчен «ас» булырга кирәк. Мәсәлән, 10-нчы хастаханәнең бер өлеше булган Бондаренко урамындагы 4 санлы йортка керә торган урын инде күп еллар буе чокыр-чакыр рәвешендә. Һәр сайлау алдыннан вәгъдәләр дә күп булды, тик вазгыять кенә үзгәрмәде. Алдагы сентябрь аенда безне Дәүләт думасына яңа сайлаулар көтә. Шул уңайдан Маркиз Астольф де Кюстинның тагын бер фикеренә мөрәҗәгать итик: «Покупать голоса, подкупать совесть, завлекать одних, чтобы обманывать других», – дигән сүзләр яза ул.

Ни кызганыч, бездә сайлаулар гадел дисәк тә, бу дөреслеккә туры килми. Инде яңалык булмаса да, искә төшерик: матбугат чараларында 1996 елда үткән сайлауларда президент булып Б.Н.Ельцинның сайлануы турында күп яздылар. Ә бит шул чорда 60 % рәсәйле аны ришвәтче, шул кадәрлесе үк илнең икътисадын җимерүче, дип санады. Ниһаять, әлеге сайлауларда Б.Ельцинның җиңмәвен Д.Медведев та танырга мәҗбүр булды.

Халык арасында: «Нигә акча туздырып сайлаулар үткәреп торырга, барысы да билгеле бит инде!» – дигән сүзләр дә йөри. Дөрестән дә, инде ничәнче тапкыр бер үк кешеләр депутат кәнәфиенә менеп утыра, әйтерсең, ул – әтисеннән мирас булып калган урын.

Бу урында М.Шәймиев истәлекләренә тукталырга кирәк: «Кызганычка каршы (тарих бу хакта да белергә тиеш), республика исеменә гаепләүләр күтәрелә башлагач, Рәсәй Югары Советына Татарстаннан сайланган бер генә депутат та ачыктан-ачык аны (Республиканы) яклап чыгыш ясамады. Әйе, якламадылар – гәрчә шул ук залда анда сөйләгәннәрнең барысын да күреп, ишетеп утырсалар да. Алай гына да түгел, федераль карашлы депутатлар республикага яла ягарга тырышты. Белүемчә, анда бит суверенитет яклылар да бар иде, алар яклау сүзе белән чыгыш ясарга, көрәшергә тиеш иде. Уйлыйм, Рәсәйнең Югары Советына Татарстаннан сайланган депутатларның эшчәнлеге махсус өйрәнелергә тиеш» («Звезда Поволжья», 2012, 22 марта).

Сүзебезне дәвам итеп, Дәүләт думасының 2007 ел, 15 ноябрьдә дәүләт белем бирү стандартында милли-төбәк һәм мәктәп компонентларын алып ташлау мәсьәләсен тикшергән вакытта, күп милләтле республикабыз вәкилләре һәм милләтләре «татар» дип язылган бүтән төбәк депутатлары арасыннан бер И.Гыйльметдинов кына каршы тавыш бирде. Әлеге мәсьәлә каралганда, Думаның пленар утырышын Татарстан вәкиле О.Морозов алып баруын да ассызыклыйк.

Яңадан Совет чорына әйләнеп кайтсак, ул вакытта депутатлар сайлаучылар алдында үзләренең вазыйфаларын үтәүләре турында даими рәвештә хисап тота иде. Хәзер бу турыда ишеткәнем дә юк. Дөрес, ул чактагылар халык депутатлары дип атала иде, хәзер Дәүләт Думасыныкы...

Бер үк вакытта алар арасында Ф.Сафиуллин, Т.Миңнуллин, Р.Вәлиев кебек Татарстан, татар халкының мәнфәгатен чын-чынлап яклаучы милләтпәрвәрләр дә бар иде әле.

Маркиз Астольф де Кюстинның тагын бер фикеренә тукталасы килә: «И не пройдет 50 лет, как либо цивилизованный мир вновь подпадет под иго варваров, либо в России вспыхнет революция, гораздо более страшная, чем та, последствия коей Западная Европа чувствует до сих пор. Каждое государство имеет свой удел, что участь России – завоевать Восток и затем распаться на части». Безнең карашка, Нострадамустан бер дә ким әйтмәгән.

Депутатлардан ике процент

Дәүләт Думасының Мәгариф комитеты рәисенең беренче урынбасары Яна Лантратова («Гадел Россия – хакыйкать өчен» партиясеннән) РФ премьер-министры Михаил Мишустинга дәүләт хезмәткәрләре, депутатлар һәм дәүләт корпорацияләре җитәкчеләре өчен аларның кеременең 2 процентын махсус операция ихтыяҗларына күчерү өчен хәйрия подпискасы кертергә тәкъдим итте. Мишустин исеменә хат ТАСС карамагында бар, дип яза агентлык.

«Җиңүгә өлеш кертү» дигән ирекле хәйрия подпискасы булдыру мөмкинлеген карарга тәкъдим ителә. Аның кысаларында Дәүләт Думасы депутатларының, төбәк һәм муниципаль дәрәҗәдәге депутатларның, җитәкчеләр категориясенә кертелгән вазыйфаларны биләүче дәүләт хезмәткәрләренең, шулай ук федераль бюджет учреждениеләре һәм дәүләт корпорацияләре җитәкчеләренең айлык кеременең 2 проценты «Ватанны саклаучылар» фондына күчереләчәк», – дип язган Лантратова.

РФ Президенты Владимир Путин, махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү өчен, апрель аенда «Ватанны саклаучылар» дәүләт фондын булдыру турында указ имзалады. Аның филиаллары илнең барлык төбәкләрендә ачылды. Фондның төп максаты – махсус хәрби операция ветераннарына шәхси социаль ярдәм күрсәтү, медицина һәм социаль реабилитация, дарулар белән тәэмин итү, психологик ярдәм, техник реабилитация чаралары һәм шифаханә-курортларда дәвалауны үз эченә алган барлык тиешле ярдәм чараларын алуда ярдәм итү.

intertat.tatar/news.

● Bloomberg мәгълүматлары буенча, иң бай россиялеләрнең мөлкәте ел башыннан бирле барлыгы 21,13 миллиард долларга арткан: «Лукойл» президенты, нефть магнаты Вахит Алекперовның байлыгы 21,8 миллиард долларга, Новолипецк металлургия комбинаты хуҗасы Владимир Лисинныкы 23,3 миллиард долларга, ЕвроХим һәм Себер ташкүмер энергетика компанияләре хуҗасы Андрей Мельниченконыкы 16,2 миллиард долларга җиткән. Эшкуар Сөләйман Кәримов исә иң күп зыян күргән – быел мөлкәте 1,48 миллиард долларга кимеп, «нибары» 7,52 миллиард долларга гына калган.

● Россиянең иң яхшы 200 мәктәбе исемлегенә Казанның 8 уку йорты да кергән: 131 нче лицей, 2 нче лицей-интернат, КФУның IT-лицее, Лобачевский исемендәге лицей, 7 нче лицей-интернат, 7 нче гимназия, лицей-инженерлык үзәге, 19 нчы гимназия. Укучылары РФнең иң яхшы югары уку йортларына керүчеләр саны буенча Россиянең иң көчле 300 мәктәбе исемлегенә исә Казанның 6 мәктәбе кертелгән: 131 нче лицей, КФУның IT-лицее, Лобачевский исемендәге лицей, 177 нче лицей, 19нчы гимназия, 121 нче лицей.

Бер картлыкта, бер яшьлектә

К.Тинчурин театры үзенең 90 нчы юбилей сезонын өлкән буын артистларга багышланган «Ай, былбылым!» спектакле белән ачты.

Заманалар бик тиз үзгәрә. Өлкән буын аңа яраклашырга өлгермичә, тормыш арбасыннан төшеп кала кебек. Элек яшьләрдә өлкәннәргә карата ихтирам тәрбияләгән булсалар, хәзер ул да бетте. Көчленеке замана. Ә кем көчле? Әлбәттә, яшьләр. Тормыш дилбегәсе алар кулында. Ни теләсәләр, шуны эшлиләр. Кызганыч ки, мондый тормыш тәртибе һәр өлкәдә урнашты. Әле кайчан гына Чаллы Татар дәүләт драма театрының баш режиссеры 34 яшьлек Олег Кинҗәголов өлкән яшьтәге берничә артистка ярты ставкага күчәргә тәкъдим итте. Ризалашмасалар, бөтенләй эштән колак кагулары ихтимал иде. Чөнки пенсияне индексацияләү өчен, эштән китү турында гаризалары бар. Яшь режиссер өлкәннәрнең борын төбендә шул хәерсез кәгазь кисәкләрен селки. Берничә дистә ел татар сәнгатенә тугрылыклы хезмәт иткән артистлар башта өнсез кала. Пенсияне индексацияләү өчен вакытлыча китү турында гаризалары майларына чыдаша алмаганнан язылмады ләбаса. Иле шундый булгач, гомер буе хезмәт иткән кеше үзенә тиешле пенсиясен ала алмагач, нишләсеннәр соң инде? Яшьлекләре хәерче тиеннәр санап үтте. Шуңа да карамастан милләтебезгә театр төзеделәр, утырып еларлык чакларында да сәхнәгә чыгып тамашачының күңелен күтәрделәр. Картлык көннәрендә булса да кешечә яшәргә хаклары юкмыни аларның? Инде бераз пенсиябезне арттырабыз, дип куанып торганда гына, яшь режиссерның шулай кылануы аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте аларга.

Режиссерны яклаучылар да булды. Чаллы театры көчкә очын-очка ялгый, янәсе. Акча экономияләү өчен шушы адымга барырга мәҗбүр булган, имеш. Театрга килеп арты да җылынмаган егетнең гомерләрен һәр тиенне санап яшәгән өлкәннәр хисабына хәл итәргә тиеш идемени акча кытлыгын? Режиссер иптәшнең килүенә театрга яңа матур бина бирделәр. Гомерләрен гастрольдә кеше почмагында, юлда үткәргән олы артистлар җылы матур бинаның рәхәтен дә татып өлгермәде түгелме соң?

Ни кызганыч, мондый күренешләр адым саен. Әмма бу җәһәттән матур үрнәкләрне дә телгә алырга мөмкин. Г.Камал театрында байтак еллар өлкән артистларны берләштергән «Инсаният» труппасы эшләп килде. Аны игелекле гамәлләре өчен зур хөрмәткә ия булган театрның элеккеге директоры Шамил Закиров башлап йөрде. Академия театрында бүген дә өлкән буын артистлар катнашында спектакльләр куела. «Исәнме, улым!» спектаклендә, мәсәлән, күренекле артисткабыз Наилә Гәрәева уйный. «Бабайлар чуагы» тамашасында яраткан аксакалларыбыз сәхнә тота. «Сөясеңме, сөймисеңме?» исемле моңсу комедия дә, камера жанрындарак булса да, катнашучы артистлары белән алдыра. Инсаният сүзе «инсан», ягъни кеше сүзеннән ясалган, кешелеклелек мәгънәсендә аңлашыла. Кешелеклелек исә - алга киткән җәмгыять билгесе. Картларга, балаларга, хатын-кызларга, ягъни ярдәмгә мохтаҗ катламнарга карата мөнәсәбәттән чыгып кына да теге яки бу җәмгыятнең үсеш дәрәҗәсен билгеләргә мөмкин. Картлыкны хөрмәт итмәү – кыргыйлык билгесе.

Өстәвенә, өлкән буын артистлар татлы матур туган телебезне җиткерүчеләр буларак кадерле. Яңа буыннар килгән саен, телебез гарипләнә барып, танымаслык дәрәҗәдә үзгәрде. Бу нинди тел, дип аптырап торасың кайчак...

Шуңа күрә күптән түгел К.Тинчурин театрында куелган «Ай, былбылым!» премьерасының әһәмияте зур булуы аңлашыла. 90 нчы юбилей сезонны махсус театрның корифейлары өчен иҗат ителгән спектакль белән башлаулары җитәкчелеккә карата хөрмәт хисе уята.

Пьесаны шушы ук театрда уйнаган, артистлар белән иңгә-иң бер үк спектакльләрдә сәхнәгә чыккан, нәтиҗә буларак драматургия өлкәсенә кереп шактый тәҗрибә туплаган Шамил Фәрхетдинов язган. Вакыйгалар картлар йортында тәрбияләнүче әби-бабайлар тирәсендә әйләнә. Өлкән яшьтә булса да, яшьләрне көнләштерерлек егәр бар үзләрендә. Әнә, Гөлҗәннәт белән Фикус туй итәргә әзерләнә. Өстәвенә, картлар йорты янындагы имәнлекне җыйнаулашып саклыйлар. Аны кисеп, урынында яшьләр өчен күңел ачу үзәге ачканны кул кушырып карап торсыннар мыни? Картларның бездә һәм чит илләрдә ничек яшәүләрен чагыштырып карарга мөмкин. Германиядә чал чәчле фрау-мадамнар бассейнда йөзә, бездә исә, ни кызганыч, күл суы кибеп киткән... Кавышу мизгеле якынлашканда гына сукыр карт Рәхимҗанның килеп чыгуы вакыйгаларны астын өскә әйләндерә. Кәләш Гөлҗәннәт ярдәмгә мохтаҗ беренче ире хакына яңа сөйгән яры Фикусны вакытлыча онытып торырга мәҗбүр. Ташлап китсә ни? Беренче ир – ходайдан. Бала сөясе килгәндер. Гөлҗәннәт исә аңа бу бәхетне бирә алмады. Ләкин Рәхимҗан бер хатын-кыз белән дә бала сөю бәхетенә ия булмый. Яшьлегендә гөлен, җәннәтен нахакка рәнҗеткәне өчен картлыгында матур дөньяны күрү бәхетеннән мәхрүм булмадымы икән ул?

Менә шундый көлдерә дә, уйландыра да торган моңсу комедия килеп чыккан. Татарстанның халык артистлары парады диярсең. Ләлә Миңнуллина, Зөләйха Хәкимҗанова, Сәлим Мифтахов, Зөфәр Харисов, Илгизәр Хәсәновны карт дияргә тел әйләнми. Алар янында Люция Галләмова, Миләүшә Нәҗмиева, Гүзәл Гарәпшина да кимен куймый. Гүзәл Гайнуллина һәм иң яшьләре – алмаш-тилмәш Әдилә ролен башкаручы Лилия Камалиева белән Әдилә Хәсәнова. Һәм тамашачыга яраткан артистларыбыз белән очрашу бәхете бүләк иткән режиссер Туфан Имаметдинов.

М.МӘХМҮТОВА.

Беренче альбом

Татарстан китап нәшриятендә күренекле галим, каллиграф Нәҗип Нәккашның иҗат әсәрләреннән китап-альбом басылып чыкты һәм «Ногай» кунакханәсенең Г.Тукай залында аны халыкка тәкъдим итү чарасы булып узды.

Нәҗип Нәккашны республикабызда белмәгән кеше юктыр. Һәр татар өендә йә ул эшләгән шәмаил, йә плакат, йә газета-журналларда басылган иҗат эшләре, йә татар мөселман календарендә чыккан Коръән аятьләре, хәдисләр бар. Ләкин алар аерым-аерым рәссамның иҗатын тулаем күз алдына китерергә мөмкинлек бирми. Хәер, язу үрнәкләрен һәрдаим күргәзмәләрдә күреп торабыз. Әмма экспозицияләр вакытлыча гына. Каллиграфия музее Казаныбызда әлегә юк. Андый музей яки галерея ачылса, язу остасы Н.Нәккашның иҗат әсәрләре, һичшиксез, анда түрдән урын алыр иде. Иң гаҗәбе шул – гарәп язулы мирасыбызны кайтаруга шулкадәр күп көч куйган шәхеснең әлегә кадәр бер шәхси альбомы да нәшер ителмәгән. Ниһаять, шундый китап-альбом чыкты һәм моны җитди вакыйга диярга кирәк. Хәер, альбом калынрак, күләмлерәк тә булырга мөмкин иде. Бу басма соңгысы булмас дип ышанасы килә.

Иҗат эшләре затлы кәгазьдә басылган. Кереш сүзен Идел буенда беренче сәнгать фәннәре докторы Фоат Вәлиевнең кызы, үзе дә фән докторы Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова язган. Альбомны караганда күңел күтәрелә, милли орнаментлар, бәйрәмчә ачык төсләр күзләрне иркәли. Һәр бит саен иҗат остасының күңел садәлеге тоемлана. Ниләр генә юк монда! 1990 нчы елларда «Мирас» журналы битләрендә беренчеләрдән булып нәшер ителгән Коръән аятьләре, пәйгамбәребез хәдисләре дә кергән. Олуг шагыйребез Габдулла Тукайга, аның иҗатына багышлап иҗат ителгән каллиграфик композицияләр гаять мәгънәле. Кол Галидән алып Җәлилгә кадәр язучы-шагыйрьләребезнең иҗат асылын ачкан сурәтләр дә матур. Бөек шәхесләребез шәлкеменнән тагын Мәрҗани хәзрәтләре, Ризаэддин Фәхреддинов, Каюм Насыйри һ.б. дин әһелләре, галим, мәгърифәтчеләргә багышланган иҗат эшләре дә бик бай, күп мәгълүматлы. Ул серия әле бүген дә дәвам итә. Яңа гына Һади Атласига багышланган шәмаил-плакат иҗат ителгән. Ул да кайчандыр бер затлы китапта урын алмый калмас. Каллиграф Н.Нәккаш төрек солтаннарында булган туграны татар мәдәниятенә күчереп алды һәм шагыйрь-язучыларыбыз, җырчы-музыкантларыбыз, дәүләт эшлеклеләребезнең меңнән артык туграсын иҗат итте. Аларның биш йөзләбе традицион шәмаил рухында пыялада буяулар белән иҗат ителде. Менә шул туграларның бер өлешен шулай ук альбомда күрергә мөмкин.

Бериш каллиграфлар шәмаилләрен бары тик гарәп телендә генә иҗат итсә, Нәҗип әфәнде һәрвакыт татар телен алга чыгарды, гарәп хәрефләре белән, әмма татарча язды. Ана телебезне зурлаган әсәрләр буларак Нәккаш шәмаилләренең кыйммәте әйтеп бетергесез зур.

Гадәттә рәссам халкы таркау була. Н.Нәккаш исә һәрвакыт төгәллеге, һәр нәрсәгә әһәмият, игътибар бирүе, җиренә җиткереп эшләве белән шаккатыра. Бу сыйфатлары китапта да чагыла. Шәмаилләрнең эчтәлеге шулкадәр тәфсилле язылган ки, укучыда бер сорау да, шик тә калмас, мөгаен. Бары галимнәргә хас була андый төгәллек. Нәҗип аганың исә Алтын Урда чоры әдәбияты белгече, кульязма һәм басма әдәбиятыбызны өйрәнүче һәм бастыру өчен әзерләүче икәне яхшы мәгълүм. Белемгә нигезләнгәнгә шәмаилләре шулкадәр камил, эчтәлекле булып чыгадыр да.

Менә шул байлыкны күпме вакыт туплап чыгармыйча яткыруыбызга хәйран калырлык. Гарәп язуын өйрәнергә теләгән, матур язырга омтылган һәркем өчен өстәл китабы бит бу. Нәҗип ага үзе дә Татар гуманитар институтында, Россия Ислам институтында ничә еллар дәресләр алып барды. Аның шәкертләреннән берсе Әлфия Исхакова Казан университетында гарәп язуын өйрәтте. Студентларга үрнәк итеп күрсәтергә кул астында моңа кадәр бер китап та булмасын инде!

Рәссамны тәүге альбомы чыгу уңаеннан дуслары җырчы Миңгол Галиев, сәнгать белгечләре Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова, Розалина Шаһиева, Сынлы сәнгать музее директоры Розалия Нургалиева, рәссам Мөдәррис Минһаҗев, язучылар Рафис Корбан, Галимҗан Гыйльманов, Мәдәният министрлыгының бүлек мөдире Айрат Фәйзрахманов һ.б. тәбрикләде. Котлауларга «Мәдәни җомга»лылар да кушыла.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Балтач яклары элек-электән үзенең тырыш, хезмәт сөючән кешеләре белән мәшһүр. Балтач төбәге шагыйрь Хәбра Рахман; репрессияләнгән язучы Ибраһим Салахов; Балтач энциклопедиясе авторы – татарның асыл заты Гарифҗан Мөхәммәтшин; Россия ислам институты һәм Казан ислам университеты ректоры, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы Рәфыйк Мөхәммәтшин; язучы һәм журналист Рәфыйк Шәрәфиев; татар халкы өчен җан атучы, депутат һәм галим Азат Зыятдинов; нефть-газ эшкәртү өлкәсендәге фәнни казанышлары белән дөньяга танылган академик Әхмәт Мазһаров; мәшһүр татар тарихчысы, археолог, академик һәм язучы Равил Фәхретдинов; мәгърифәтче, дин белгече Җәлил хәзрәт Фазлыев; Казан Федераль университеты профессорлары Ләйлә Минһаҗева һәм Нурфия Йосыпова һ.б. бик күпләр белән бәйле. Балтачның горурлыгы булырлык шәхесләрнең тагын берсе – затлысы, зыялысы – инде чирек гасырдан артык татар мәгарифе, мәгърифәте өлкәсендә нәтиҗәле эшләүче укытучы, үткен каләм остасы ***Рәҗәп Бәдретдинов***. *Ул – билгеле мөгаллим, байтак гыйльми, әдәби, публицистик, тәнкыйди язмалар авторы, филология фәннәре кандидаты, Казан шәһәре буенча 2002 елда үткәрелгән «Ел укытучысы» конкурсының җиңүчесе, ихлас шәхес, эчкерсез әңгәмәдәш, тугры дус, таянырлык коллега.*

Халкыбызның лаек зыялысы

Рәҗәп Бәдретдинов 1971 елда Балтач районының кечерәк кенә Пүскән дигән авылында туа. Башлангыч белемне туган төбәгендә ала. Алга таба ул – хәзер Җәлил хәзрәт Фазлыев гомер кичерә торган бай тарихлы Бөрбаш авылындагы урта мәктәп укучысы. 8 нче сыйныфны тәмамлагач, мәшһүр Арча педучилищесында укый. Үсмер егет биредә алдынгы студентларның берсе хисаплана. Җиңел атлетика буенча да җиңүләр яулый. Күп төрле иҗади бәйгеләрдә, конкурсларда, әдәби чараларда катнаша, сценарийлар яза. Сабакташы, хәзер Татарстанның халык артисты Фәнис Җиһанша; үзләреннән бераз гына алдарак укыган «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе башкарма директоры урынбасары, «Ком сәгате» тапшыруының алып баручысы Данил Гыйниятов һ.б. белән концертлар, спектакльләр куя, спорт ярышларында катнаша. Арча педучилищесын тәмамлагач, 1990 елда туган төбәгендәге Нормабаш мәктәбендә башлангыч мәктәп мөдире һәм мөгаллим булып эшли башлый. Бер елдан соң инде Рәҗәп – Казан дәүләт университетының татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты студенты. Бу – милли хәрәкәтнең, татар халкының шаулап, кайнап торган еллары. Чын милләтпәрвәр егет бу чор вакыйгаларының үзәгендә кайный. Университетның бай китапханәсендәге рухи хәзинәләр белән дә ныклап таныша. Моңа кадәр дә инглиз, алман телләрен шактый үзләштергән егет, ныклап төрекчә, гарәпчә өйрәнә башлый, гарәп язулы китаплар, кулъязмалар белән дә иркен эш итә. Өченче курстан соң, укуына параллель рәвештә, төрек теленнән дәресләр бирә һәм Казандагы Ш.Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясендә татар теле һәм әдәбиятын укыта.

1996 елда университет дипломы алган Р.Бәдретдинов, аспирантурага тәкъдим итсәләр дә, туган якларына кайтып, Алан урта мәктәбендә директор урынбасары һәм укытучы булып эшли башлый. Әмма тиз арада Ш.Мәрҗани исемендәге гимназия директоры, халык укытучысы Камәрия ханым Хәмидуллина аны кабат үзенә чакыртып ала. Биредә яшь белгеч директор урынбасары һәм мөгаллим вазыйфаларын башкара. Р.Бәдретдинов ачык дәресләр уздыра, практика үтүче студентлар белән дә җитәкчелек итә, җәмәгать эшләрендә дә башлап йөри. Казан шәһәренең Мәскәү районы Сабан туйларын да алып бара.

Әмма якташлары аннан Балтач якларына кайтуын үтенә. Рәҗәп 2002 елда Алан мәктәбендә элеккеге вазыйфаларын үтәүне дәвам итә. Республика, район күләмендә күптөрле чаралар уздыра. Татарстанда үткәрелгән конференция-семинарларда чыгышлар ясый, төрле басмаларда язмаларын бастырып, үз тәҗрибәсе белән уртаклаша. Тик Балтач егетен Казан даими үзенә тартып тора шул. Ул янә башкалада, Татарстан Фәннәр академиясе каршындагы атаклы «Мирасханә»дә эшли башлый. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин да Р.Бәдретдинов эшчәнлеген яклап һәм хуплап тора. Рухи мирасыбызның олуг белгече Марсель Әхмәтҗанов ярдәмендә ул кулъязмалар, сирәк китаплар дөньясына чума. Шушы ук елларда аспирантурада да укый. Без фәкыйрегез җитәкчелегендә күренекле язучы һәм дәүләт эшлеклесе Афзал Таһировның (1890–1937) тормышын һәм иҗатын ныклап өйрәнүгә керешә. Бу эшендә аңа әдипнең «Сайланма әсәрләре»н туплап бастырган (К., 2008. – 471 б.) Марсель абыйсы да ярдәм итә. Рәҗәп Мәскәү, Казан, Уфа, Әлмәт, Киров, Малмыж архивларында ныклап эшли, төрле чыганаклардан материаллар туплый, шушы тема буенча мәкаләләр бастыра. Ул 2008 елда Г.Ибраһимов исемендәге институт Советында «Афзал Таһировның иҗат мирасы: идея эчтәлеге һәм сәнгати үзенчәлекләре» дигән темага диссертация яклады, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ия булды. Аның бу диссертациясе безнең «Киң колачлы әдип һәм дәүләт эшлеклесе» дигән кереш мәкалә белән 2010 елда «Каһәрле еллар корбаны» исеме астында аерым китап рәвешендә дә басылып чыкты (Казан: Ихлас. – 175 б.).

Әтисенең вафаты, әнисенең кинәт авырып китүе, фатирсызлык аркасында фәндә уңышлы гына эшләп киткән фән кандидатына янә туган якларына кайтырга туры килә. Ул чактагы Алан мәктәбе директоры Гүзәл Бариева шәкертенең эш-гамәлләренә һәрчак хәерхаһлы мөнәсәбәттә була. Үзен Бөрбашка күчергәч тә, Алан мәктәбен Р.Бәдретдиновка тапшырып китә. Егет Алан мәктәбе директоры һәм укытучысы сыйфатында нәтиҗәле һәм игелекле гамәлләр кыла. Аның җитәкчелегендә дини-әхлакый тәрбия бирү юнәлешендә ачык дәресләр, семинар-конференцияләр, язучылар, галимнәр, артистлар, җәмәгать эшлеклеләре белән очрашулар үткәрелә. Алларда миңа да берничә мәртәбә катнашырга туры килде. Шәкертемнең матур әдәби телдә аралашуын, максатчан эш итүен, ихтирамын күреп куандым.

Соңгы елларда Рәҗәп Бәдретдинов Балтач районы мәгариф идарәсенең мәгълүмати үзәге директоры, мәгариф идарәсе җитәкчесе урынбасары булып та эшләде. Күп кенә конференция-семинарларда заманча белем һәм тәрбия бирүнең алшартлары хакында докладлар ясады, матбугатта язмалары басылып торды. Әдәбиятны да һич онытмады. Мәктәп тормышы, яшәеш, укытучылар турындагы хикәяләрен дә нәшер итте. Моңа кадәр дә гарәп телен, ислам әдәбиятын, гарәп язулы рухи мирасны яхшы белгән Р.Бәдретдинов «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге Казан мәдрәсәсендә укыды, аны 2023 елда уңышлы тәмамлап, ислам дине нигезләре мөгаллиме һәм гарәп теле белгечлеге алды.

Укытучы-галимнең методик, гыйльми, әдәби, публицистик язмалары «Казан утлары», «Безнең мирас», «Идел», «Мәгариф», «Гасырлар авазы», «Мәдәни җомга», «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан», «Дин вә мәгыйшәт» һ.б. газета-журналларда, фәнни җыентыкларда басылып килә. Аның һәр мәкаләсе – тәнкыйди язмалары, чыгышлары, бәяннары шактый ук җитлеккән, калыплашкан. Публицистик мәкаләләре факт-мәгълүматларга, вакыйга-хәлләргә бай. Әдәби әсәрләре камил-йөгерек тел, бай сурәтләү чаралары, төгәл сюжет белән язылган. Бу авторның күпкырлы эшчәнлеген һәм рухи тормышыбызның үзенчәлекле якларын, милләтебезнең шатлык-борчылуларын күзалларга да ярдәм итә.

Рәҗәп Фәтхетдин улының әзерлеге ифрат дәрәҗәдә зур, язу куәсе саллы, сыйфатлы. Әдәбият мәйданында юл алган кыйбласы туры, кабатланмас, ихлас һәм риясыз. Рәҗәп Бәдретдинов яңадан-яңа әсәрләре белән безне тагын да куандырыр, әдәби манзарада үз урынын алыр һәм мәдәни-гамәли мәйданнарда үз уен уйдырып салыр әле.

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,
филология фәннәре докторы,
Казан университетының
атказанган профессоры.

● **Рәҗәп Бәдретдиновның «Төнге яктылык» дип исемләнгән китабы дөнья күрде. Китапта хикәяләр, фәнни һәм публицистик мәкаләләр, әдәби тәнкыйть мәкаләләре, чыгышлар, хатлар, истәлекләр урын алган.**

Илһам НОГМАН

Күргән саен шушы курганнарны Кан хәтере җанны бимазалар...

ИЗГЕ КИТАП

Тәүге Китап Күкләрдән ул
Иңгән җиргә, бәхәссез.
Аллаһ сүзе гомер бакый
Булган бөек, бәһасез.

Бихисап хикмәт тупланган
Бу мөкатдәс китапка.
Һәр тәкъва җан мөкиббәндер
Чын, илаһи хитапка.

Могҗизага тиңдер аның
Һәрбер сүрә, аяте.
Чагылган монда җиһанның
Бар мәхлукат хәяте.

Иманлы инсаннарның ул
Төшмәгән бер кулыннан.
Бары Китап яздырмаган
Бәндәне хак юлыннан.

Күңелгә илһам биргән ул
Төшенкелек басканда,
Тәүбә кылырга күндергән
Гөнаһларга батканда.

Изге Китап булгангадыр
Урыны һәрчак түрдә.
Шуннан да асыл хәзинә
Юктыр тагын бу җирдә!

Илаһи нур бөрки аннан
Җир йөзенә, Галәмгә.
Рәхмәт, безнең күзне ачкан
Бу кодрәтле Кәлямгә!

ДАЛА ХАТИРӘСЕ

Үткәннәрдән тик курганнар калган
Һәйкәл булып бөек бабамнарга.
Каракошлар бары шомландырып,
Килеп куна сынташ-балбалларга...

Козгын, карчыгалар хаким монда,
Алар беләмәсе бу мазарлар.
Күргән саен шушы курганнарны
Кан хәтере җанны бимазалар...

Ерак тарихларга алып китә
Уйлар, сискәндереп искәрмәстән...
Курганнарның эргәсенә ятып,
Җилләр елый, гүя исәрләнгән...

ТАУЛАР

Көрднең иң якын дусты
бер генә – ул таулар.
Көрд халык мәкале

Җил-давылдан ышыклар гел алар,
Иңен куеп, мохтаҗ чагында,
Мәгърур таулар калкан булып басар,
Һәрчак торыр синең сагыңда.

Таулар, таулар...
Горур бөркетләрнең
Туган җире, кунар кыясы.
Бу дөньяда, әйе, һәркемнең дә
Тик бертөрле булмый оясы...

Таулар иле нинди сокландыргыч! –
Биеклеккә күңел омтыла...
Монда хөрлек, монда бу дөньяның
Барлык ваклыклары онытыла!

ТАТАР ҖЫРЫ

Алып китә әллә кайларга ул,
Үткәннәргә гүя кайтасың...
Татлы уйларыңнан хозурланып,
Онытылып тыңлап ятасың...

Юксындырта ерак бабамнарның
Дәүләт токкан газиз җирләрен...
Нинди кодрәт синдә, татар җыры! –
Бик тирәндә бугай серләрең...

Алтын Урда, Казан ханлыгына
Хыялымда кабат кайтамын,
Бөек Болгар җирләрендә йөреп,
Горурланып шаклар катамын.

Татар җыры – халкымның язмышы,
Чал тарихы затлы токымның;
Шатлыклары, кайгы-сагышлары,
Моң-зарлары Идел-йортымның.

ТАҢ СУЫ

Иртә таңнан изге чишмәләрдән
Им-томчылар алган таң суы.
Шифа булган ул күп сырхауларга,
Сихәт биргән һәрбер тамчысы.

Хасталарны аякка бастырган
Чир-зәхмәтне җиңеп, ошбу им.
Тәнне генә түгел, рухыбызны
Саклап калган икән ич бу дим.

Сабый чактан, шөкер, иман иңгән
Таң сулары белән җаннарга.
Рәхмәт укыйм имче әбиләргә
Ходай бирмеш һәрбер таңнарда.

Заман зәхмәтләренә дә, бәлки,
Шифа булыр әле таң суы,
Мохтаҗ җаннар көткән ярдәмнәрнең
Барсыннан да, шәт, иң тансыгы.

Күпме имансыз зат бу дөньяда
Хәрәм кылып яши һәрдаим.
Дөньяларын имгә китерерлек
Кодрәтеңне индер, Ходаем!

КҮЛКӘЕМ

Киек казлар төшмәс инде бүтән,
Кибеп бара суың, күлкәем!
Сагынсам да күрә алмам инде,
Еракларда китте гөлкәем.

Язларын да суың ташып акмый,
Кар сулары әллә коймыймы?
Сагышларың йөзләреңә чыккан,
Эчләреңә генә сыймыймы?

Су буйларың гел үзенә тарта,
Балачаклар шунда калганга.
Син булмасаң кемгә сөйләр идем
Моң-зарымны күңлем тулганда?

ИЗГЕ СӘГАТЬТӘ

Уемда ашам мин күкләргә,
Онытып бу дөнья гамьнәрен.
Күңелем нечкәрә, тоямын
Хәятның илаһи ямьнәрен.

Йа Раббым, мин дә дим, бер бәндәң,
Хатадан түгелмен һич хали.
Шәфкать ит, ярлыка, ташлама,
Галәмдә бер үзең ич Гали.

Догамны кабул ит, Илаһым,
Сәҗдәләр кыламын каршыңда.
Иманнан яздырма нәселем,
Түреңне насыйп ит гаршеңдә.

Син рухи сердәшем тиңдәшсез
Һәм чиксез мәрхәмәт иясе.
Яд итеп һәрдаим үзеңне,
Килә мең шөкерләр диясе.

Биектән иңә күк бу вакыт
Сихри көч дәрт өстәп җаныма,
Коелган шикелле хис итәм
Тамчылар сабырлык җамыма.

Күңелне били бер хозурлык,
Кальбем нурлана тагын да,
Ходаем, бу изге сәгатең –
Намазга оеган чагымда.

ЕГЕТ ҖЫРЫ

Су буйларында йөримен,
Уем гел синең хакта шул,
Уем гел синең хакта.
Нигә соң бергә булмадык
Сөеп туялмас чакта ла,
Сөеп туялмас чакта?!

Бер генә дә уйламадым
Ялгыз калырмын диеп шул,
Ялгыз калырмын диеп.
Гомерләрем үтәр микән
Кайгы-сагышта көеп лә,
Кайгы-сагышта көеп?!

Кульяулыгыңны саклыймын
Һаман да төсең итеп шул,
Һаман да төсең итеп.
Кавышырбыз бер дип уйлыйм
Ходайдан вакыт җитеп лә,
Ходайдан вакыт җитеп.

ЯРАТАСЫ КИЛӘ КӨЗДӘ ДӘ

Яшьлек үтеп киткән
Сизелми дә күптән.
Күңел генә бер дә картаймый.
Яратасы килә
Шашып елый-көлә,
Чәчләр агарганга карамый.

Бер сүрелми икән
Бу хис сөю дигән,
Картаясың һич тә килмәсә;
Язлар үткәненә,
Көзләр җиткәненә
Күңелләрең әгәр күнмәсә.

Гомер буе сөеп
Яшик янып-көеп,
Тормышның бер ямен җуймыйча.
Яшьлектәге төсле
Типсен йөрәк көчле
Сөеп-сөелепләр туймыйча!

МИЛӘҮШӘЛӘР

Тәрәз төбебездә миләүшәләр –
Иң яраткан синең гөлләрең.
Серләшәсең алар белән кайчак,
Беләсеңме әллә телләрен?

Ямь өстиләр алар өебезгә,
Күтәрәләр һәрчак күңелне.
Шуңа безнең өйдә һәрвакыт җәй,
Менә шуңа бездә күңелле.

Миләүшәләр, безне сөендереп,
Ел буена чәчәк аталар.
Өебезгә күзләр кермәсен дип
Тырышалар бугай бит алар...

СӨЮ ҖИМЕШЕ

(Бер гүзәл зат монологы)

Гомерем буе каңгырып йөрдем,
Көйли алмадым тормышларымны.
Язмаган, ахры, бу дөньяларда
Насыйбым белән кавышуларны.

Минем дә бит бер татыйсым килә,
Сөю җимеше ул нинди була?
Яшәүмени бу, тик газап кына,
Күзләрем ачы яшь белән тула.

Сөю җимеше бармы икән соң,
Эзләп-эзләп тә табылмагачтын?!
Бардыр ул, бәлки, юктыр да, бәлки,
Каян белим соң татымагачтын.

Ул парлы тормыш, бәхетле язмыш,
Табыным тулы гел татлы җимеш, –
Төшләргә керә ымсытып көн дә, –
Көтәдер мине күзләрдә, имеш.

ШӘРЫК ГҮЗӘЛЕНӘ

(Шаярту катыш)

Шомырт кара күзләреңнең нуры
Эретте дә салды җанымны.
Ширбәт саркып торган иреннәрең
Сәрхушләтте тәмам аңымны...

Ходай һәдиясе булгансыңдыр
Минем бәхетемә бу җирдә.
Мондый шәрык гүзәлене назын
Онытырлык түгел гомергә.

Сине төшләремдә күрә-күрә,
мин Мәҗнүнгә бугай әйләндем.
Ләйлә җаным, синең толымнарга
Гомерлеккә, ахры, бәйләндем.

Михаил Худяков

М. ХУДЯКОВ КИТАБЫ ТУРЫНДА

Казан ханлыгының тарихы беркайчан да җентекләп өйрәнелмәде. Борынгы заманда да, хәзер дә.

Элек бу дәүләтнең тарихы урыс телле әдәбиятта юл уңаеннан гына – Русьның, Россиянең тарихын тасвирлаганда теге яки бу сюжетка бәйләп кенә яктыртылды. Күпсанлы «СССР тарихлары»нда да әлеге мөнәсәбәт үзгәрмәде. Аларда да безнең күп милләтле илебездә яшәгән барлык халыкларның үткәнен төрле яклап тикшерү урынына бары тик бер генә патшалыкның барлыкка килүе һәм үсеше тарихы өйрәнелде.

Яңа заманда исә, шактый гына халыкларның язмышы белән бәйле Казан ханлыгының тарихына кагылганда, белгечләр Татар АССРның рәсми тарихындагы аерым бүлекләр чигеннән чыкмаска тиеш иде һәм төп концепция нигезендә халыкларның «чын тарихы»... 1917 елдан гына башлана дип күрсәтелде. Әлеге бүлекләрдә йөз елдан артык мәйдан тоткан һәм күп халыкларның язмышында җуелмас эз калдырган бөтен бер дәүләтнең тарихы телгә алынганда реаль фактларны һәм катлаулы вакыйгаларны фәнни яктан җентекләп тикшерү урынына сүгеп язылган бәяләмәләр өстенлек алды.

Шулай итеп гаҗәеп бер парадоксаль күренеш пәйда булды. Мәгълүм ки, инкыйлабка кадәрге тарих белеме, сирәк очракларны санамаганда, чикләрен киңәйтер өчен һәрвакыт сугышып торучы феодал-алпавытлар империясенең социаль-сәяси омтылышларына хезмәт итте. Ләкин иң гыйбрәтлесе шул, нәкъ менә социалистик дәүләттә тарих белемендәге әлеге концепция, шәхес культы елларында яңа көч алып, яңа биеклеккә күтәрелде.

СССР халыклары тарихындагы күп санлы фактларны өйрәнелмәве шикелле үк, Казан ханлыгы тарихының мөһим якларын күз уңыннан читтә калдыру астында да катлаулы сәбәпләр ята.

Тик бер тапкыр гына бу мәсьәләдә бераз яктылык пәйда була – әлеге дәүләтнең тарихын фәнни яктан, ягъни тикшеренүче тарафыннан, берьяклы бәяләмәләрне читкә куеп, үткәннәрнең катлаулы дөреслеген ачып бирү омтылышы мәйданга чыга.

Михаил Худяков тарафыннан Совет хакимиятенең беренче елларында язылган һәм нәшер ителгән «Казан ханлыгы та-

рихыннан очерклар» китабы шул омтылышның нәтиҗәсе. Бу вакытта әле намуслы кешеләрдә гаделлекнең – һәм социаль, һәм мораль-этик яктан – тантана итүенә ышаныч зур һәм аларның акылына, аңына партия җитәкчеләренең үзара ызгышы нәтиҗәсендә тутык үтеп кермәгән була. Әйе, ул елларда фән кешеләренең иманы һәм омтылышлары демагогик шигарьләргә төренгән коммунистик тәкәбберлек, кешелеклелеккә каршы мессианлык, империячел амбицияләр вирусы белән агуланмаган була әле. Кешеләр «халыклар төрмәсе»н җимереп, тигез хокуклы – «иң гадел, иң гуманлы, иң бәхетле», димәк, намуслы җәмгыять төзү турында хыялланa. Алар әле социалистик революция җиңүенә чын күңелдән ышана һәм «халыклар төрмәсе»ндәге тәртипләрдән йөз мәртәбә әшәкерәк ГУЛАГ дәһшәтен, 20-30 еллардагы канлы репрессияләр мөмкинлеген күз алдына да китерә алмый. Шул еллардагы «милләтләрнең чәчәк атуы» дистәләрчә халыкларга карата кулланылган геноцидка әверелде, шул исәптән урыс халкы да мәдәни-рухи һәлакәт алдында калды. Ә бит әлеге «эксперимент»ны оештыручылар нәкъ менә аның исеменнән лаф орырга яратты...

«Чын күңелдән ышанучылар» исәбенә, әлбәттә, М.Г. Худяков та керә. Ул 1894 елның 3 сентябрендә Нократ буендагы Малмыж шәһәрендә туа. Нык токымлы һәм җитеш сәүдәгәр гаиләсендә тәрбияләнә. Беренче Казан гимназиясен тәмамлагач, Казан университетының тарих-филология факультетында белем ала (1813-1918). Ә фәнни эшчәнлеген исә Көнчыгыш педагогия институтында башлый. Егерменче елларда ул безнең төбәктә яшәгән төрк һәм фин-угыр халыкларының тарихына кагылышлы берничә тарихи-этнографик хезмәт дөньяга чыгара. Әлеге хезмәтләр арасында без телгә алган «...очерклар» аерым урын тота. Әсәр 1923 елда нәшер ителә.

Шул ук елларда М.Г.Худяков Казанда һәм туган шәһәре Малмыжда музейлар оештыруда башлап йөри, Казан университетына бәглы археология, этнография һәм тарих җәмгыятендә, татарларны өйрәнү буенча фәнни җәмгыятьтә тырышып эшли. 1926-1929 елларда ул Ленинградта аспирантурада укый. Аны тәмамлагач, яшь галимне Академиядә – матди мәдәният тарихы институтында эшкә калдыралар. Анда да ул Урта Идел буенда яшәгән халыкларның тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүне дәвам итә. 1936 елда М.Г.Худяковка тарих фәннәре докторы дигән дәрәҗәле исем бирелә. Ләкин шул ук елның 9 сентябрендә, «троцкизм»да гаепләнгән «халык дошманы» буларак, ул кулга алына. Ә 19 декабрьдә атарга хөкем ителә. Хөкем карарын шул ук көнне тормышка ашыралар...

Шуннан соң галимнең исеме онытылуга дучар ителә; хезмәтләрен телгә алырга ярамый, аларны юк итәләр (дөрес, Казан ханлыгы тарихы турында язучы кайбер тарихчылар алардан шыпырт кына күчереп үз исемнәреннән дөньяга чыгара, үзләре, җае чыкканда, галимне рәхәтләнеп хәкарәтли...). Сәяси яктан 1957 елда ул аклана да, аның әсәрләре безнең көннәргә кадәр нәшер ителмәде. Бу юнәлештә эшне, аның кайбер хезмәтләрен татарча дөньяга чыгарып («очерклар»дан өзекләрне һәм аерым мәкаләләрне), «Идел»-журналы (1989, № 1, 1990, № 2 һ.б. саннар) башлап җибәрде.

Билгеле, Казан ханлыгы һәм анда яшәүче халыкларның тарихын тикшергәндә, М.Худяков бар мәсьәләләрне дә бер үк дәрәҗәдә чишә алмады. Күп нәрсәләргә ачыклык кертергә кирәклеге турында ул үзе дә кат-кат язды. Моңа ул вакыттагы тарих белеменең тиешле кимәлдә булмавы, хосусән, чыганакларның канәгатьләнерлек хәлдә эшкәртелмәве сәбәпче иде. Кайбер катлаулы мәсьәләләрне шәрехләргәндә галимнең наивлыгы да күзгә ташлана. Катмарлы иҗтимагый проблемаларга кагылганда, егерменче елларга хас гадиләштерелгән социализм идеяләре дә үзен сиздерә. Моны М.Н. Покровский йогынтысы белән аңлатырга кирәктер. «... очерклар» урыны-урыны белән кайбер хаталардан, ялгышлардан да хали түгел. Аларны төзәтеп шәрехләү һәм, билгеле, тулаем алганда галимнең күзәтүләренә, нәтиҗәләренә дөрес бәя бирү, «... очерк»ларның академик басмасын булдыру – киләчәк эше.

Ләкин игътибарлы укучы М.Г.Худяковның тарихи ялганнан, максатчан фальсификациядән азат булырга омтылуын күрер. Ул, чын гуманист буларак, әлгәреге эшлеклеләрнең, шәхесләрнең үз мәнфәгатен, үз фикерен, үз азатлыгын якларга хокукы булган гадәти кешеләр икәнлеген таный. Ул, чын мәдәниятка ия кеше буларак, халыкларны «сортларга» бүлми. Ул, үз халкының патриоты буларак, кардәшләренең бүтәннәргә шәфкатьле, хәерхаһ булуын тели. Мөгаен, шушы изге нияте аңа кайчагында чынбарлыкны дөрес күрсәтергә, ул заманнардагы кешеләрнең яшәү рәвешен һәм мәдәни кимәлен фәнни кырыслык белән тасвирларга комачаулык та иткәндер. Әйе, империянең элеккеге тәкәббер тарих белеме традицияләреннән арынырга, хәтта аларны җимерергә теләп, М.Г.Худяков җитәрлек нигезләнмәгән нәтиҗәләр дә чыгарды. Әле 1924 елда ук моңа урыс академик культурасының тагын бер намуслы вәкиле В.В. Бартольд та игътибар иткән иде. Ул, мәсәлән, «... очерклар»ны Ф.В. Баллодның шау-шу кузгаткан «Идел буе «Помпейлары» дигән китабы белән чагыштырып болай язган иде: «Элек, мәгълүм ки, һәрнинди мәдәниятләрен инкяр итеп, татарларга дошманый мөнәсәбәттә булдылар... Хәзер киресен күрәбез... Элеккесе кебек үк, монысы да хата, һәм ул, элеккесе кебек үк, фәнни белемгә хилафлык китерә». (Соч., Т II, ч I, М., 1963, с. 712).

Шулай итеп, татарга каршы традицион концепциянең борынгы дошманлык фактларын бүгенгезә һәм киләчәккә күчерергә теләгән голәмәдән аермалы буларак, М.Г. Худяков тарихи гаделлеккә омтылды, татар халкын төрле нахак ялалардан акларга теләде. Бу җәһәттән, әлбәттә, тикшеренүченең игелекле кеше булуын әйтмичә ярамый. Әйдәгез, без дә аңа игелек белән җавап бирик: мирасында уңай якларны күбрәк күрик. Чөнки ниятләре һәм гамәлдәге уңай сыйфатлар гына мәгънә хасил итә ала. Ә инде борынгы заманда яшәгән теге яки бу халыкның «мәдәни» булу-булмавы хакындагы бәхәсләр соңгы исәптә варисларының әхлакый сыйфатларына нигезләнеп хәл ителә. Мәдәният ул һәрвакыт чагыштырмача һәм тарихи яктан шартлы төшенчә.

Миркасыйм Госманов,
Тарих фәннәре докторы.
1990 ел, август.

ШӘҺРИ КАЗАН
Казанга нигез салыну

Казан урнашкан төштә борынгы заманнарда ук кешеләр яшәгән. Казаннан ерак түгел Казансу һәм Идел үзәннәрендә таш гасырдан калган торакларның эзләре табылды. Неолит чорына караган әлеге торакларда кешеләр б.э.к. 15-20 йөзьеллыкларда яшәгән. Бу чордан калган эзләр Идел үзәненең сул (төньяк һәм көнчыгыш) калкулыгы буйлап шактый еракка сузыла. Тораклар гадәттә үзәннең язгы ташулар капламаган урта террасасына урнашкан була. Аларны күбрәк үзәннең сул ягында, Идел агымы уңаена аккан кушылдыкларның ярларында табалар. Идел буйлап Казаннан югарырак төшләрдә – Васильев һәм Займище авыллары тирәсендә, түбәнрәк – Поповка, Кукушкино, Кече Отар, Победилов, Зур Отар һ.б. авыллар янында шул торакларның эзләре билгеле. Казан үзәнендә исә шәһәрдән җиде чакрым ераклыктагы Савин авылы янында бу эзләргә юлыктылар. Казанга иң якын борынгы торак урыны Поповка авылы тирәсендә (Плотән бистәсенә якын), аннары язгы ташу баса торган Идел үзәнендә, Идел белән шәһәр арасында (Бакалтайдан Яңа татар бистәсенә таба юлда) борынгы җәйләү урыны билгеле. Идел үзәненең икенче террасасында, шәһәргә якын урыннарда, әлеге су буе комлыгындагы тораклар дип аталучы борынгы яшәү урыннарының табылуы шәһәрнең түбәнге өлешендә дә, Кабан күле һәм Болак буйларында, неолит чоры тораклары булуын фаразларга мөмкинлек бирә, тик аларның әлегә кадәр табылганнары юк.

Бронза гасырыннан безнең көннәргә Казаннан җиде чакрымда булган 40 нчы заводның бистәсендә табылган кайбер әйберләр килеп җиткән. Алар Казан тирәсендә ул заманнарда ук кешеләр яшәвен дәлилли. Ә 1982 елда В.И.Заусайлов тарафыннан Казан эчендә тимер гасырдан калган бөтен бер мазарлык табыла. Ул хәзерге тимер юл вокзалы белән Идел тамагы арасында урнашкан була. Әлеге урынны Пыяла заводы дип тә йөртәләр, аның бинасы биредәге бөтен яр буен алып тора. Монда табылган әйберләр хәзер Финляндиянең Һельсингфорс (Һельсинки) музеенда саклана (В.И.Заусайлов коллекциясе 1909 елда шул музейга сатылган иде). Бу табылдыклар Казан илендә шактый мазарлыклары билгеле «Пьянобор культурасы»на нисбәтле. Казан мазарлыгындагы табылдыклар Әйшә (Казансуның өске агымындагы

китабыннан өзекләр

Түбән Әйшә янында), Атаман (Вятка губернасы Малмыж өязендә, Нократ буендагы Таршы авылы янында) мазарлыкларында, Чумбар авылы (Вятка губ. Уржум өязендә) һәм Безводный пүчинкәсе (Вятка губ. Яран өязендәге Пижма елгасы буенда) тирәсендә табылган әйберләргә тәңгәл. Боларның барысы да безнең эра башларына нисбәтле.

Болгар чорына килсәк, хәзерге Казаннан алты чакрым ераклыкта, Югары Кабан ярында утрак урын билгеле. Анда күптән түгел Воскресенье монастыре биләмәләре иде (Әрхәрәй дачасы). Монастырьда болгар чорыннан калган зират эзләре бар. Монастырьны салганда (1780 елда) исән калган кабер ташларын биналарның нигезенә салалар. Мәрҗани яза: «Казанда күл башында әскаф (епископ) чиркәве янында икегә сынган бер таш бар. Ул урында моннан башка да ташлар булган. Төзелеш вакытында эшчеләрнең шул ташларны юнып, тигезләп, биналар астына салганнарын күреп, ул вакытта Казанда әскаф, соңыннан мәтран (митрополит) булган Григорий исемле кеше бу эшне тыйган. Шуңа күрә бер таш сакланып калган». («Мостафадел-Әхбәр»). Хәзерге вакытта Воскресенье монастыренда гарәп язулы ике таш саклана. Берсе монастырь капкасыннан кергәндә уң якта, икенчесе – әрхәрәй йорты каршындагы нәни бакчада чаң машы янында; бу таш янында шуңа охшаш өченче ташның кыйпылчыгы ята; тәкъва мөселманнар бу кабердекне зиярәт итә һәм дога укырга килә (Шпилевский. «Древние города», с.476).

Ташлардагы язуларны хәзергә кадәр төгәл укыган кеше юк әле. Мәрҗани беренче таш астына Мир Мәхмүд улы Хәсән бәк җирләнгәнен ачыклаган. Икенче ядкярдәге язуны уку мәсьәләсендә Мәрҗани белән Н.И.Ашмаринның фикерләре аерыла. Мәрҗани анда Әхмәд исемен укыса, Ашмарин ташта Ылтын Бюрды (?) дигән хатын-кыз исемен күрә (ягъни Алтын Бөртеге – тәрҗ.) Әлеге кешенең үлгән вакыты төгәл укыла: 616 ел, зөлхиҗә аеның 8 көне, ягъни 1297 елның 27 сентябре (Н.И.Ашмарин «Об одном мусульманском могильном камне на Архиерейской даче в Казани», с.19).

Татар риваятьләре Казанга нигез салыну вакытын да Болгар чорына, Казансуның өске агымында хәзерге Казаннан 45 чакрымда булган Иске (Эчке – тәрҗ.) Казан шәһәрлеге белән бәйли.

Ул риваятьләр буенча хәзерге Казанга Иске Казаннан күчеп килүчеләр нигез салган. Ә Иске Казанның барлыкка килүен татар чыганаклары Болгарның Булат Тимер тарафыннан җимерелүенә тоташтыра.

«Фәрһәгнамә» китабында, Болгарны Тимер хан җимергәч, соңгы болгар ханы Габдулланың уллары Алтынбәк белән Галимбәк качып котылган һәм Иске Казан урынына килеп төпләнгән, диелә. (Кафтанников «Древние болгары» (Библиотека для чтения, 1847 г., т.82, с.57; Шпилевский, с.70). Бу хәбәр «Бәян Дастан әт-тарих» дигән китапта да кабатлана. Анда ике бертуган егетнең Казан суы буйларына килеп чыгуы һәм хәзер Иске Казан исеме белән билгеле урында Казан шәһәренә нигез салулары сөйләнә (шунда ук). «Аксак Тимер дастаны»нда Болгарны Тимер бәк яулап алгач, Болгарның соңгы ханы Габдулланың ике улын кемнәрнеңдер урманга яшерүләре бәян ителә, ул вакытта Галимбәккә – 9, ә Алтынбәккә 7 яшь була. Сугыш дәвамында аларны шулай урманда тәрбиялиләр. Сугыштан соң әлеге бәкләр Казан суы буенда Казан шәһәренә нигез сала (Рыбушкин «Поездка в Ст.Казань» (Заволжский муравей, 1833, т.III, Шпилевский, с.36). Әлеге риваятьнең өзекләре XVIII гасырда Георги һәм Рычков тарафыннан нәшер ителә (шунда ук). Соңрак аны Кафтанников, Рыбушкин, Фукс, Малов һ.б. кабатлый, шулай ук Казан тарихы турындагы барлык язмаларда да, һәм татар, һәм урыс телләрендә, бу риваять күз уңыннан төшеп калмый.

Иске Казан шәһәрлеге Рычков, Георги, Рыбушкин, Малов һәм П.А.Понамаревлар тарафыннан тасвирланган. Әлеге тасвирлардан күренгәнчә, шәһәрлектә зират булуы билгеле. Анда гарәп язулы өч кабер ташы сакланган. Берсенең язуын укып булмый, икенчесе – 1486 елга, өченчесе 1494 елга нисбәтле.

Икенче зират шәһәрлектән ярты чакрым ераклыкта, Иске Урмат авылы кырында; риваять буенча, монда Мулла Хаҗи җирләнгән; зират читеннән аккан инешне ханныкы дип атыйлар. Иске Казаннан 1,5 чакрымда, Түбән Әйшә авылы янында Гайшә бикә кабере бар. Ул Мулла Хаҗиның сеңлесе булган. Татар риваятьләре Гайшә бикә белән Мулла Хаҗины, шулай ук Болгарның соңгы ханы Габдулланың уллары Алтын һәм Галим бәкләрне Болгар чоры белән бәйли. Булат Тимер тарафыннан тар-мар ителгәч, Болгар шәһәре халкының бер өлеше Иске Казанга качарга бик мөмкин, алар арасында хан нәселеннән дә кешеләр булуы ихтимал.

Татар чыганакларында Иске Казанга нигез салу вакыты да күрсәтелгән: «Бәян Дастан әт-тарих»та һәм «Дастане Аксак Тимер»дә (Яковкин кульязмасында) шәһәргә һиҗри белән 805 елда, ягъни 1401-1402 елларда нигез салына, диелә. «Бәян Дастан әт-тарих»та Иске Казан барлыкка килгәннән соң 104 ел үткәч, әлеге шәһәр кешеләре Яңа Казанга нигез салган, дип язылa. Әлеге сан «Дастане Аксак Тимер» китабындагы мәгълүмат белән дә раслана, әмма анда Иске Казанга һиҗри белән 700 елда, ягъни 1300-1301 елларда, нигез салынуы әйтелә. Бу санга ышануы кыен, чөнки Булат Тимер Болгарны соңрак, 1361 елда, тар-мар итә. Иске Казанда 1486 һәм 1494 еллар теркәлгән ядкярләр бар, димәк, Яңа Казан салыну белән кешеләр бу урынны бөтенләй ташлап китмәгән. Шулай булгач, кайберәүләр уйлаганча, Иске Казан 104 ел гына яшәп калмаган.

Яңа Казанның Иске Казаннан чыккан кешеләр тарафыннан нигез салынуы хакында безнең кулда дәлилләр юк, әмма без бу мәгълүматны кире дә кага алмыйбыз. Татар чыганакларының Яңа Казанга нигез салынуы һиҗри белән 805 елга, ягъни милади 1401-1402 елларга нисбәтләвен без әйткән идек инде. Бу сан дөрес булса кирәк: Болгарны алмаштырган зур сәүдә үзәге буларак, Казанның 1361 (Болгарның җимерелүе) һәм 1438 (Казан ханлыгына нигез салыну) еллар арасында пәйда булуы табигый. Урыс чыганакларында Казан беренче мәртәбә Никон елъязмасында 1376 елга нисбәтле телгә алына: шушы елда урыслар «Казанга килделәр, Казаннар исә шәһәрдән чыктылар, Казан бәкләре баш орды, Казанга даруга һәм тамгачыларны билгеләделәр». Ләкин елъязмадагы Казан турындагы әлеге хәбәрне С.М.Шпилевский шик астына ала, аныңча, «Казан» һәм «казаннар» сүзләре соңыннан гына «Болгар» һәм «болгарлар» урынына теркәлгән, чөнки Воскресенски елъязмасында 1376 елда булган урыс явы турында бик тәфсилләп язылган, әмма ул аның Казанга түгел, Болгарга каршы булуы бәян ителгән (Шпилевский, с.178-180). Аннары Казан 1382 елга нисбәтле рәвештә Архангел елъязмасында телгә алына: Туктамыш «Болгарга, Казан шәһәрендәге бәкка» урыс сәүдәгәрләрен таларга дигән әмер җибәрә. Проф. С.М.Шпилевский бу хәбәрнең дә дөреслегенә ышанмый, чөнки Воскресенски елъязмасында Казан шулай ук телгә алынмый, анда болай диелә: «Туктамыш үз татарларын Иделдәге Болгар шәһәренә җибәрде». Ә Никон елъязмасында бу ике атама тәңгәлләштерелә: «Болгар дип аталган кала, ул ук Иделдәге Казан». 1389 елга бәйле рәвештә Казан янә Воскресение, София 1 һәм Новгород lV елъязмаларында телгә алына: шушы елда «кенәз Василий Дмитриевич үзенең берадәре кенәз Юрийны Казанга җибәрде». Воскресение, Никон, Кострома l, София ll, Новгород lV һәм Львов елъязмаларында 1399 елга бәйле рәвештә бөек кенәз Василий Дмитриевичның воеводалар, өлкән баярлар һәм күп көч белән берадәре кенәз Юрий Дмитриевичны яуга юллавы теркәлгән: «алар барып Олуг Болгар каласын, Җүкәтау каласын, Казан каласын һәм Кирмәнчек каласын алды, һәм барлык җирләрен яу белән үттеләр». (Воскрес. лет., с.72. Никон lV, с.267. Костр. l, с.247-248, Соф. ll, с. 130. Новг. lV, с.101-102, Львов ll, с.226.) Проф. С.М.Шпилевский Казан хакындагы бу хәбәрне дә шик астына ала. Аның фаразынча, елъязмачылар Кама буена урнашкан болгар каласы Кашанны ялгыш Казан дип язган. Ул әлеге фаразын мондый дәлилләр белән ныгыта: «Әгәр дә бу хәбәрдә чыннан да Казан турында сүз барса, ул чакта ни өчен Кашан телгә алынмый? Югыйсә көнчыгыштарак урнашкан, димәк мәскәүләрнең яу юлында арырак булган күрше Җүкәтау исемлектә бар. Казанның алардан әһәмиятлерәк шәһәр буларак телгә алынуы ышандырмый, ул заманда әле Казан, болгар җиренең үзгеннән читтә урнашкан яңа шәһәр буларак, мөһим урын тотмаган...

● Казан кирмәненең XII гасырдагы күренеше. Фиринат Халиков эше.

(Дәвамы киләсе санда).

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА тәрҗемәсе

ТЕЛӘКӘЙ ЧИШМӘСЕ

(Дәвамы. Башы 42, 43, 44 нче саннарда).

* * *

Өч көннән соң укчы полкларның башлыклары «падишаһ» Петр галиҗәнапларына, стрелецларның бирән боярлар тарафыннан йотып бетерелгән жалованиесе күләмен язып, «үтенеч» кәгазе илтеп бирде.

– Федор патша түләмичә килгән жалование бурычы өч ел эчендә ике йөз кырык мең тәңкә күләмендә җыелган. Әгәр шуны бер ай эчендә кайтарып бирмәсәгез, стрелецлар Мәскәүдәге барча байбәтчәләр йортын талап чыга!

Наталия Кирилловна белән Петр гына түгел, Кремль тирәсендә чуалган барча бояр һәм кенәзләр дә таракан капкандай тоташ кара көйдә.

– Казнада стрелецлар өчен каралган сыңар тиен дә юк бит!

Менә шул көннәрдә фәрманнар чыгарырга бер хокукы да булмаган Софья – патша кызы көтелмәгән карар игълан итте:

– Ашыгыч рәвештә бөтен ил буенча көмеш һәм алтын савыт-сабаларны җыярга да, аларны эретеп, стрелецлар алдындагы бурычны кайтарырга!

Мондый карар, билгеле ки, укчыларның йөрәгенә сары майдай ятты, ике-өч көннән соң ук Кремльгә яңа петиция язып китерделәр:

– Стрелецлар авырыбрак торган Иванны да – патша итеп, ә ул тулысынча савыкканчы патшабикә Софьяны ике хакимнең дә регенты итеп билгеләвегезне, ә Петрның тавыш-гаугага чыгаруга юл куйган анасы Наталия Кирилловнаны Кремльдән читләштерүегезне үтенәбез. Янә дә бер гозер: стрелецлар гаскәре өстенә күләгә төшмәү өчен, хөкүмәт май ае уртасында юк ителгән боярларны җинаятьче һәм карак дип танырга, шул карарны аерым хәтер тактасына язып, Кремль каршындагы җәза мәйданына урнаштырырга тиеш...

Хөкүмәт капкынга эләккән, аның тыпырчынырлык та егәре юк иде. Егерме бишенче июнь көнне Успения соборында, асылда да, Иван белән Петрның икесенә дә таҗ кидереп, халыкны алар алдында ант иттерделәр. Патшабикә Софья ике таҗдар туганының да регенты булып игълан ителде. Хәзер аңа Голицын гына түгел, соңгы атнада стрелецлар гаскәре башлыгы итеп үзе үк билгеләгән кенәз Хованскийның да кочагында, берсеннән-берсенә күчеп назлану өчен, күк капусы ачылган иде инде...

* * *

Кремльдәге шушы мәхшәрне нинди элемтә аша чамалап алганнардыр, август уртасында Мәскәү каласы әллә каян гына әйләнеп кайткан динне искечә тотучы кавем белән тулды. Аларның башлыгы Никита Пустосвят атлы кеше икән, шуның котыртып торуы нәтиҗәсендә әллә ничаклы чиркәү эчендә искечә динне яклап кычкыручы мөнәдиләр (глашатай) акырышып йөрде.

– Өч бармак белән чукыну – ул иблисләр эше! Успения соборыннан куып чыгарылган Никон атакайны һәм дә ике бармак белән чукынуны кире кайтарыгыз!

Кремль эчендәгеләр күпчелеге әлеге мәхшәр уены белән ниндидер сихерле кул идарә итүен дә ник чамалый, әмма өзеп кенә беркем өстенә дә гаеп ташларга һич тә кыймый иде. Шул вакытта янә, һәркемне шаккатырып, патшабикә Софья аваз салды:

– Хөкүмәт эчендәге кайбер бояр дворяннар ополчениесен төзү яклы, ә дворяннар сәхнә түренә менсә, алар стрелецларны куып таратачак!

Шул сүздән күкерттәй кабынган укчылар Пустосвят атлы иске динчене эләктереп, аның башын кыеп төшерде. Яңадан кан түгелүне сәбәп итеп, Софья үзе, барча кыз туганнарын җыеп, Мәскәүдән Ярославль ягындагы Коломенское авылына чыгып качты, ахыр чиктә Троице-Сергиев монастыреның таш диварлары артына кереп томаланды. Ул моннан укчылар башлыгы кенәз Хованскийны очрашуга чакырып хат юллаган иде, тегесенең пырдымсыз җавабы регент галиҗәнапларын тораташтай итте.

– Син кабат кенәз Голицын кочагына кергәнсең бит инде, азгын айгыр кирәксә, тот та шуны чакыр.

Ике тәүлек вакыт үтүгә инде яңа хәбәр: Софья үз сеңелләре белән качып йөргән чакта иске динчеләр дә тик ятмаган, алар

кенәз Хованский белән аның улы Андрейның башын кыеп аткан...

Софья качкач, бераз атнадан соң, аның янына боярлар думасындагы бөтән башлыклар да килеп җитте. Сергиев монастырена бикләнгән килеш кенә Софья Мәскәүгә көтелмәгән яңа фәрманын юллады.

– Мәскәүдәге бунт мәхшәрен туктатырдай бөтән көч юк, дворяннар ополчениесен чакырырга кирәк. Шунсыз стрелецлар гаскәрен хөкүмәткә буйсындырып булмый...

Сергиев монастыре белән Мәскәү арасында чабулап йөрүче олаулар стрелецларның үз гомере һәм ата-анасы белән ант иткән хат вә үтенечләр белән тулды. Алар, чыннан да, баш бирмичә маташкан булып ялгышуларын өстәмә аңлатмаларсыз да сизенә бит. Ирләрне гаскәрдән куып чыгардылармы – аларга хөкүмәт тарафыннан аккан акча елгасы шундук туктаячак. Ә аларның күпчелеге хуҗалык алып барырдай йә сәүдә белән мантырдай эшем иясе түгел. Ниндидер чит илләр өстенә яу белән барасы, гомереңне балта астына куеп, үлем белән алыш-биреш уйныйсы юк. Мәскәүдә яткан өчен, тиктомалдан дигәндәй, акча килеп тора. Ят мич башында иплән, тыныч кына...

Үкенү тулы хатлар капчык-капчык җыелгач кына, Софья монастырьның үтә яшерен бер бүлмәсендә барча укчылар исеменнән баш иеп килгән кенәз Федор Шакловитыйны кабул итте. Боларның яшерен сер алышуы таңга кадәр сузылды, аның каравы, күндәм кунак үз кулына бик кадерле фәрман тотып чыкты.

– Кенәз Федор Леонтий улы Шакловитый галиҗәнаплары стрелецлар приказының башлыгы итеп билгеләнә, моннан ары ул – хөкүмәт таянычы.

Вахит ИМАМОВ

* * *

Теләкәй морза Федорны үз яныннан аткару турында уйлап та карамады. Тәүге көннәрдә, кырыкмаса-кырык яктан сораштырып, ул аның үзгенә үткән иде инде.

– Син Мәскәүдән Агыйделгә тикле араны ничек исән-сау көе үтә алдың да, ничек бер генә урыс сатлыгы да сине үзеңдәй стрелислар кулына илтеп тапшырмады?

– Мин Мәскәүдән чыгып качкан чакта ук бояр ялчылары, төрле калалар янында төнге каравылга чыга торган атлы дозорлар кулына эләгергә һич тә ярамауны чамаладым инде. Урыс авыллары яныннан узып барышлый түтәлләрдән кәбестә белән кыяр, бер-ике йорт абзарыннан тавык белән каз чәлдереп тә тамак ялгадым. Безнең кавемдә койма коею дигән тәртип юк бит, аларыннан чәлдерү күп тир сорамады. Ә менә Малмыж белән Кукмара, алардан соң Мамадыш шикелле сезнең татар авылларыннан, дөресе көтүләреннән сарык чәлгән чакта ике-өч урында тотып та кыйнадылар. «Мин стрелец бит, стрелецлар башлыгы Васька Голицын фәрманы буенча Уфа каласы ягына хезмәткә барып ятам», дип аклангач кына, бик яман ярсалар да, ахыр чиктә барыбер җибәрделәр. Сезнең халык гаҗәп: патша эше белән йөргән кешеләргә изгеләштереп, фәрештәдәй карый...

Уйланып йөри-йөри дә Теләкәй морза бу качактан Мәскәү хәлләренә әйләнеп кайтмыйча да калмый.

– Менә син Суфия патшабикәгез стрелисларга акча түләү өчен көмеш сабса җыярга фәрман бирде, дидең. Ул алтын-көмешләрне кара халыктан гына җыйдыларммы, әллә боярлар да өлеш чыгардымы?

– Җыйды, пычагым! – дип Федор ярып салды. – Кайсы бояр гына үзен талаттыра инде? Аларның берсе дә кул-аякларын арканнар белән бәйләп, суярга егып салган сыер яисә сарык түгел ләбаса. Алар Софья фәрманын ишетеп алуга ук барча алтын-көмешләрен йә базларына төшереп яшерде, йә сандыкларга бикләп, урманнарның иң чытырман җиренә илтеп күмде. Җыйсалар да, шул вак-төяз кенәзләрдән, дворяннар ихатасыннан гына талап чыга алдылар. Софья вәгъдә иткән ике йөз кырык мең урынына йөз мең тирәсе генә түләү тараттылар.

Шушы сүзләрне ишеткәч, хәзер инде Теләкәй ярсып купты.

– Тукта, тукта! Ул явыз патшабикә боярлардан акча җыя алмагач, хөкүмәт бурычын бездәй мөселманнар, беренче чиратта татар сыртына күчереп салган була түгелме соң? Әнә, ул тоткан да татар авылларының биләмәләрен чиркәү илә монастырьларга өләшә башлаган. Шул юл белән казна өчен акча туплый, имеш. Ә чиркәү сала йә монастыр калкыта башлаган авыллардагы татар игенчеләре кая гына барып сугылсын да, кайда төпләнсен ди? Безнең авылны чиркәүгә биргәннәр дип, алар кайсы гына күршесенең ихатасына йә биләмәсенә кереп сыена ала? Һәрбер адәм баласына, иң беренче чиратта, үз күлмәге, үз милке кадерле. Шуңа күрә бер үк яланлыкны икегә бүлеп чабарга, бер күлдән биш-алты, хәтта ун гаилә балык тотуларга, йомгаклап әйткәндә, бер бозау тиресен җиде кешегә бүлеп таратырга бер генә татар гаиләсе дә риза булмаячак.

– Әйе, әфәндем, син дөрес сукалыйсың. Софья боярлар сыртыннан затлы тунын салдырып алу урынына, ул тун хакын сездән түләтергә җыена булып чыга. Мәгәр, мәгәр...

Федор тынды, ә Теләкәй аңа текәлде дә ник сагаеп калды.

– Нәрсә «мәгәр»? Сөйлә, сөйлә, әйдә.

– Мин бу елан кеби явыз Софья сезнең авылларга чиркәү йә монастырь салу белән генә туктамас, дип уйлыйм. Әгәр сезнең халыкны да шул чаңлы чиркәүләр һәм кирмәндәй монастырьлар эченә тартып кертә алмаса, ул аларны шып-шыр далада яисә иксез-чиксез ком чүлендә тәзәгән кебек була. Чиркәү дә, монастырь да меңәрләгән адәм баласын үз эченә йөту, каршы торганнарны көчләп чукындыру, ахыр чиктә хөкүмәт кубызына биетү өчен кирәк. Чиркәү калыктымы, аның поп вә игуменнары сезнең халыкны мәҗбүриләп чукындырмый калмаячак.

– Ничек итеп, ничек?

– Ысулларын тиз уйлап табарлар. Кемдер менә минем шикелле караклык өстендә тотылыр. Кемдер үзе дә белми-чамаламыйча хатынын яки күршесен сугып үтерер. Сезнекеләр турында «атларны бик оста, аякларына киез урап йә бүрек кидереп тә урлыйлар», дигән дан чыккан бит.

(Дәвамы 15 нче биттә).

(Дәвамы. Башы 44 нче санда).

Даннан мәхрүм татарлар

ГАТАУЛЛИН МӘГЪСҮМ ХӨББӘТ УЛЫ

Гатауллин Мәгъсүм Хөббәт улы 1924 елда Баулы районының Исергәп авылында дөньяга килә, 1942 елның августында сугышка озатыла. 1943 елның июненнән соң Брянск һәм 1 нче Белоруссия фронтларында, 136 нчы аерым пантон-күпер төзү батальонында отделение командиры, сержант булып яу йөри.

1944 елның августында Друть, Көнбатыш Буг, Нарев елгаларын кичкән чакта дошманның туктаусыз утка тотуына карамастан, пантон күперләр төзүгә һәм совет гаскәрен каршы ярга чыгаруга ирешә. 6 сентябрьдә Нарев елгасын кичкәндә аның расчет сугышчылары үзйөрешле тупларны күчерү өчен пантон күперләр төзеп өлгертә. Немец артиллериясе 800 метр ераклыктан ут ача. Гатауллин снаряд кыйпылчыгы белән яралана, ләкин сугышчан постны ташламый. Күперне кабат сафка бастыруга ирешәләр һәм дошман һөҗүмен кире кагалар.

1944 елның 12 сентябрендә Гатауллин Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, ләкин әлеге каһарман татар да фәкать Кызыл Байрак ордены белән генә бүләкләнә.

Сугыштан соң нефть-газ чыгару идарәсендә механик булып эшли, 1991 елда вафат була.

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

ГАТИН АЛЕКСАНДР ГРИГОРЬЕВИЧ

Гатин Александр Григорьевич 1915 елда Минзәлә районында туган һәм 1937 елның октябрендә шул ук район комиссариаты тарафыннан Кызыл армияга чакырылган. Бөек Ватан сугышы яуларында 1941 елның августында ук катнаша башлый. Калинин, Брянск, 1 нче Украина фронтларында яу йөри. 29 нчы гвардия мотоукчылар бригадасында батареялар белән идарә итүче взвод командиры була, гвардия лейтенанты. Ике тапкыр яралана. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнарына лаек була.

1945 елның 26 гыйнварында Одер елгасын кичкәндә дошманның 2 тубын, 2 дзотын, 8 пулеметын һәм байтак пехотасын юк итүгә ирешә, 5 гитлерчыны әсирлеккә ала.

1945 елның 29 гыйнварында Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, аны Ленин ордены белән бүләклиләр.





ГОБӘЙДУЛИН ГАБСӘЛАМ ГАЛИЛ УЛЫ

Гобәйдуллин Габсәлам Галил (дөресе Хәлилдер) улы Кукмара районында 1926 елда туган, 1943 елның 11 ноябрендә шул район комиссариаты аша сугышка озатылган. 5 нче гвардия укчылар дивизиясенең 17 нче полкында станоклы пулемет төзәүчесе була.

1945 елның 7-8 апрелендә Кенигсберг каласын штурмлаган чакта үзенең пулемет расчеты белән уңайлы плацдарм эләктерә һәм дошманның 30 дан артык сугышчысын юк итә. 26 апрельдә үз пулеметы белән иң беренчеләрдән булып Балтыйк диңгезендәге бер култыксаны кичеп чыга һәм Фрил-Нерунг борынындагы траншеяларны гитлерчылардан азат итә. Дошман контрһөҗүмгә күтәрелгән чагында да чигенми, полкның башка подразделениеләре югалтуларсыз рәвештә диңгез култыгын кичсен өчен уңай форсат тудыра.

1945 елның 28 апрелендә Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, ләкин сугыш ахырына якынайган бит инде, татар каһарманы батырлыгы Кызыл Байрак ордены белән бәяләнә.


НАГРАДНОЙ ЛИСТ


II. Заключение вышестоящих начальников
Командир начальник
III. Заключение Военного Совета Армии
Наградить орденом Красного Знамени
Командующий 11 Гв. Армии
Член Военного Совета 11 Гв. Армии
IV. Заключение Военного Совета фронта (округа)

(Дәвамы киләсе санда).

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.

«Миллиард татар» челтәреннән. **Вахит ИМАМОВ** тәрҗемәсе.



Марат Мингалиев – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, танылган рәссам-график, сәнгать белгечләре ассоциациясе, ТР Рәссамнар берлеге, Россия рәссамнарының иҗат берлеге әгъзасы.

РӘСЕМ ДӘ –

Ул менә инде 27 ел дәвамында Г.М.Хәкимова исемендәге Яр Чаллы картина галереясында эшли, бүлек мөдире вазыйфаларын башкара. Аның шәхси күргәзмәләренә халык теләп йөри, чөнки Марат Искәндәр улы һәр күргәзмәсен ачканда нинди дә булса яңача башкарылган хезмәтләре белән сокландырмыйча калмый. Бу үзенчәлек аның 2023 елда А.Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар драма театры бинасында ачылган, Идел Болгарстанында ислам динен кабул ителүнең 1100 еллыгына багышланган «Көнчыгыш акыл ияләре юлы буйлап» шәхси күргәзмәсенә дә хас булды.

Аның әсәрләре ТР дәүләт сынлы сәнгать музее, Болгар дәүләт музей-тыюлыгы, Мәскәүнең «Мәрҗани фонды», Алабуга дәүләт тарих-мәдәният тыюлыгы, Яр Чаллы һәм Әлмәт картина галереялары фондларында саклана.

– Марат әфәнде, ни өчен сез нәкъ рәссам һөнәрен сайладыгыз?

– Дөресен әйткәндә, башта табиб буласым килгән иде. Миннән яхшы табиб чыгар иде дип тә уйлыйм. Тик язмыш башка юлдан алып китте. Гаиләдә без ике ир туган үстек. Әтиебез Искәндәр Гыйбадулла улы – инженер, әниебез Рушания Габделбәр кызы фельдшер һөнәрендә булса да, безнең сынлы сәнгатькә тартылуыбызны бик үз иттеләр. Абыем Рөстәм белән бергәләп балачактан ук рәсемнәр ясап үстек. Ул рәсемнәребез хәзер дә исән, әти-әниебез аларны кадерләп саклый.

Мин Яр Чаллының Балалар сынлы сәнгать мәктәбендә укыдым. Мәктәпне тәмамлагач та Казан дәүләт медицина институтына имтиханнар тапшырдым. Тик анда керү өчен бераз балл җитмәде. Ә менә абыем шушы һөнәргә укып чыкты. Һәм бүгенге көндә гастроэнтеролог, педиатр булып эшли.

Армия хезмәтем Мәскәү шәһәрендә узды. Үзгәртеп кору еллары иде. Ул чакта бар иҗатчылар да, шул исәптән рәссамнар да, бик активлашты. Башкала мине мәдәни чаралары белән хәйран гаҗәпләндерде, андагы яңа күргәзмәләр белән гел танышып бардым, күп музейларны карап чыктым. Һәм Яр Чаллыга кайткач, биредәге дәүләт педагогика институтының сынлы сәнгать-графика факультетына укырга кердем. 1995 елдагы диплом эшем өчен эквилибристика жанрын сайладым. Укытучым, рәссам А.Халдеев, аннары инде талантлы рәссам Х.Шәрипов иҗатыма зур йогынты ясады. 1996 елда калабызның картина галереясында теоретик һәм практик эшчәнлегем башланып киткәч, сәнгать белеменә тагын да яхшырак төшенә башладым, регионыбыз сәнгатендәге яңа тенденцияләрне барладым, Татарстанның XX-XXI гасыр сәнгате тарихына багышлап, лекция курсларын төзедем һәм бихисап



практик семинарларда чыгыш ясадым.

– Сез үз иҗатыгызда графика өлкәсенә күбрәк тартыласыз...

– Мин әлеге юнәлештә Россия, Италия, Аргентинада узган проектларда да катнаштым. Яшь рәссамнарыбызны бу жанрга төшендерү максатыннан аларны басма графика үзәкләренә: Казан, Зөя, Санкт-Петербург, Милан, Верчеллига алып бардым. График әсәрләрдән торучы күмәк күргәзмәләрне ТР дәүләт сынлы сәнгать музеенда, калабыздагы галереяда, Балалар сәнгать мәктәбендә һ.б. оештырдым. 2019 елда исә илебезнең һәм Италиянең яшь графикларын чакырып, Казан, Чаллы, Әлмәт шәһәрләрендә – «Интерграфика. Узнавание. «Riconocsimento», 2020 елда – Чаллыда, 2021 елда Әлмәттә «Югары басма. Графика» халыкара күргәзмәләрен үткәрдем. Соңгы күргәзмәгә, куратор буларак, Италия рәссамы Глория Вероника Лаваньини да килде. Нәтиҗәдә, бу проектка 25 дәүләттән 110 артык рәссам җәлеп ителде, ә галереябыз фонды 370 тән артык график әсәрләр белән тулыланды. Моңа кадәр үзем дә ТР рәссамнары төркеме составында Италиягә барып, андагы сәнгать үзенчәлекләренә төшенеп кайткан идем.

Соңгы күргәзмәләремдә исә график серияләремнән тыш,

ТАРИХИ САБАК

гарәп каллиграфиясе үрнәкләре кулланып иҗат ителгән Көнчыгышка карауч традицион киемнәр дә урын алды. Аларны XII-XIII гасырларның суфичылык поэзиясен укып чыгып иҗат иттем. XIX гасыр ахры – XX гасыр башындагы фотосурәтләргә карап, татар халкының образларыннан, киемнәребездән илһам алдым һәм шундый киемнәрне яңача күзаллладым.

Тагын бер уңышым бар, сынлы сәнгать белгече буларак, 2021 елда «Искусство графики Б.И.Урманче. Истоки, традиции и новаторство» дип аталган саллы фәнни монографиямне халыкка тәкъдим итә алдым. Бу хезмәтемдә останың график әсәрләре системалаштырылып бирелде. Олпат рәссамыбызның шундый төр әсәрләре катологы да төзелде. Хезмәтем ТР Фәннәр академиясе җитәкчелегендәге Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм гамәли бизәү сәнгатьләре бүлегендә әзерләнде. Б.Урманченың график битләре, портретлары саны гына да меңнән артык. Аның беренче график эшләре кырына 1919 ел дип тә язып куелган, ягъни аларның ясалганнарына инде быел 104 ел. Урманче графикасы кызыклы, аерым игътибарга лаек. Өстәвенә, аның татар рәсем сәнгатенә нигез салучы беренче профессиональ рәссамыбыз булуы хакында да гел истә тоттым. Б.Урманче – 1926 елда Казан Сәнгать техникумында уку-укыту бүлеге мөдире һәм укытучы булып эшли башлагач та техникумда литография остаханәсен ачкан зат. Аның иҗатын моңа кадәр дә өйрәнгән идем, фәнни-тикшеренү эшләрем 2005, 2007 елларда «Духовный мир Б. Урманче» һәм «Г.Тукай в творчестве Б.Урманче» китапларында да нәшер ителде.

– Марат әфәнде, сез бит үзегез дә укытучы-остаз.

– Шулай, минем эшчәнлегем укучыларга белем бирү белән дә бәйле. 2015 елда ук Татарстан Мәдәният министрлыгы грантына бер офорт станогын – картина галереябыз өчен, икенчесен – Балалар сынлы сәнгать мәктәбе өчен сатып алган идек.

Бүгенге көндә картина галереясының «Ступени» балалар студиясенә йөрүчеләргә шушы ысулдагы рәсемнәрне иҗат итәргә дә өйрәтәм. Бу студияне 2000 елдан алып җитәклим. Балалар өчен «Этнографика. Россия мәдәни кодын эзләгәндә» дип аталган сәнгати-мәгърифәти проект ачтык. Илебез төбәкләренә виртуаль этнографик сәяхәтләр ясап, иксез-чиксез Ватаныбыз халыкларының төрле традицияләрен һәм мәдәниятен өйрәнеп, бай этнографик материалларны төрле техникалар аша чагылдырабыз. 7-12 яшьлек балалар бу дәресләргә бик теләп йөри. Алар инде Удмурт, Мари Иле, Мордва, Чуаш Республикалары, Коми, Пермь төбәкләре табигате буенча да сәнгати объектлар иҗат итте. Соңгы дәресләребез Кырымга багышланды, коллаж ысулын кулланып, «Карлыгач оясы»н, Бакчасарайны рәсемнәргә төшердек. Аңа кадәр Татарстанны, Сөембикә образын, Казан ханлыгын, татар риваятендәге аждаһаны тасвирлаган идек. Сөембикә образын пластик өслеккә гравюра ясап, кәгазьгә һәм футболкаларга да төшердек. Чаллы балалары үз тарихларын яхшы белеп үсә! Моңа кадәр дә аларны Һиндстан, Мексика, Япония мәдәниятләре белән таныштырдым.

Каланың Балалар сәнгать мәктәбендә исә яшь рәссамнар белән «Сөлге – халык зирәклеге китабы» дигән сәнгати-мәгърифәти проектка алындык. Борынгы орнаментларны тукымаларга басма графика ысулы ярдәмендә төшердек. Галереяга шәхси балалар студиясенә йөрүчеләр дә, «Адымнар Чаллы» – 59 нчы гимназия укучылары, сынлы сәнгать мәктәпләрендә белем алучылар, укытучылар һәм студентлар да килә, алар линогравюра, катыргыга гравюра ясау алымнарына төшенде инде. Картина галереябызда 2015 елда оештырылган «Эстамп кабинеты» остаханәбез проекты кысаларында олылар өчен дә осталык дәресләре алып барам. Заманча графикага мөкибләннәр өчен экспериментал графика курсын ачтым, шулай итеп башкаларны үз иҗатларында үзгә, яңа сәнгати чишелешләргә килә белергә өйрәтәм. Иҗат өлкәсен тирәнтен өйрәнергә теләүчеләр саны көннән-көн күбәя баруы да сөендерә.

– Сезнең үз балаларыгыз да рәссамлык юлындадыр?

– Мин – күп балалы гаилә башлыгы. Гаилә коргач, бер-бер артлы дүрт балабыз туды. Камилла, Марат, Искәндәр һәм Әмирнең рәсем ясауга сәләтләре бар, әмма алар башка һөнәрләр сайлады.

Җәмәгатем Айсылу – гамәли-декоратив сәнгать остасы, ул төрле матур бизәнгечләр ясау, чигүләр чигү белән шөгыльләнә. Шуңа күрә минем сәнгать хакындагы әңгәмәләрем еш кына өйдә дә дәвам итә.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Бәйгеләрдә җиңүче

«Иң яхшы туган тел һәм әдәбияты укытучысы – 2023» Бөтенроссия һөнәри бәйгесеннән абсолют җиңү белән кайтып төшкәннән соң, Айсылу Лотфуллина җиңүен уртаклашырга Арча районы Яңа Кенәр авылына әти-әнисе янына туган йортка кайтты. Айсылуның әти-әнисе Газинур абый белән Равилә апа Лотфуллиннар кызларының җиңәсенә бөтенләй шикләнмәгән.

Узган атнада Казанның 41 нче мәктәбенең мәктәпкәчә төркемнәр тәрбиячесе Айсылу Лотфуллина Төньяк Осетиянең Владикавказ шәһәреннән «Иң яхшы туган тел һәм әдәбияты укытучысы – 2023» Бөтенроссия һөнәри бәйгесеннән абсолют җиңү белән Казанга әйләнеп кайтты. Тәрбиячене хезмәттәшләре, дуслары һәм Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин аэропортта каршылап тәбрикләде. Бит очыннан үбеп тә алды әле.

Елларда исә Айсылуны күрешүләрнең иң кадерлесе, котлауларның иң әһәмиятлесе көтә иде – Айсылу җиңүен уртаклашырга Арча районы Яңа Кенәр авылына әти-әнисе янына, туган йортка юл тотты.

Газинур абый белән Равилә апа Лотфуллиннар йортында бәйрәм иде – кызлары Рәсилә, Алсу һәм Айсылу кайтуны көтәләр. Җомга иртәсендә әниләре аш бүлмәсендә тыз-быз килә, эти кеше – мәчеттәге намаздан кайтып, ихатада мал-туар, кош-кортны карарга тотынмак булып йөри.

«Бүген балалар кайта. Тәмлене пешереп, мунчаны ягып каршы аласы килә инде. Атлаган саен кайта алмыйлар бит. Шуңа күрә кызлар кайтып өйдә җыелган көннәр – гел бәйрәм күк. Бу юлы исә чын мәгънәдә бәйрәм – Айсылу чит төбәктә торып, бәйгедә көч сынашып, җиңү белән Татарстанга әйләнеп кайтканнан соң менә, ниһаять, безнең янга да җиңүен уртаклашырга кайта», – ди Газинур абый.

Иң яхшы туган тел һәм әдәбият укытучысы һәм тәрбиячесе исеме өчен 104 катнашучы көрәште: 72 укытучы һәм 32 тәрбияче. Айсылу Лотфуллинаның Татарстанга 32 регион арасында абсолют җиңүне яулап кайтуы – бөтен республика өчен зур вакыйга, мәртәбәле күренеш булды. Әмма кешенең җиңү-отышлары өчен барыннан да ныграк сөенүче, горурланучы – ул әти-әни. Ихластан җан ату, куанудa әти-әни кеше белән беркем ярыша алмый. Айсылуның әтисе Газинур абый да, горурлыгын яшерә алмыйча, кызының җиңү тарихын сөйләде.

«Айсылуның бу җиңүе – гаҗәп тә, гаҗәп тә түгел. Бу, бер яктан, әйе, могҗизаи күренеш. Икенче яктан, Айсылуның җиңү белән кайтуы гаҗәп тә түгел. Ул тотынган эшен җиренә җиткереп, камил дәрәҗәдә башкаруга күнеккән. Айсылу – тырыш, максатчан, хезмәт ярата торган кыз. Эш эшләгәндә ару-талуны белмичә, тырмашып эшләп, теләгәненә ирешә торганнардан. Кыяфәткә йомшак, тыйнак, тыныч кебек ул үзе. Әмма асылда Айсылу – сер бирми торган, үткер, хәрәкәтчән. Кечкенәдән шундый булды.

Кызларыбыз өчәү: 1988 елда беренчебез Рәсилә, 11 ай үткәннән соң, 1989 елда, игез кызларыбыз Алсу белән Айсылу туды. Өчәү бергә тәгәрәшеп үстеләр. Мин аларны тезеп бастыра идем дә баян тарта идем. Боларны җырлатам. Шулай җырга-моңга хәвәс булып үстеләр. Хәзер уйнамыйм инде. Картайдым. Кызлар да үсте. Тезеп җырлатырга өйдә кеше юк», – дип көлә эти кеше.

«Биш рәтле, өч рәтле баяннарым, әнә, өйдә ята», – дип тә өстәде әле Газинур абый.

«Өчәү бергә беренче сыйныфка бардылар. Бергә утырып укыдылар. Өчесе дә гел яхшыга укыды. Монысына мин «гаепледер» инде – бик тәлапчән, кырыс эти булдым. Аларны бик үчтекиләп үстереп булмады. Эштән баш чыкмады. Авыл җирендә, эштән кайткач, тагын ихатага, абзарга чыгып чабасың. Кызлар мөстәкыйль булып, бер-берсен карап үсте.

Кызларның иң хәрәкәтчәне, иң чаясы, иң тапкыр сүзлесе, иң үткере – Айсылу булды. Дәресләрдә гел Айсылу кул күтәреп утыра торган булган. «Төшереп тә тормый иде кулын», – дип искә ала укытучылары. Игез балалар холыклары белән бер-берсенә охшамый, диләр, чыннан да шулай. Алсу тыйнаграк, тынычрак, басынкырак һәм төгәлрәк кеше – әнисенә тарткан. Ә Айсылу миңа охшаган инде: кызу, җитез, хәрәкәтчән, кызыксынучан.

Өлкән кызыбыз Рәсилә фармакология өлкәсендә эшләп йөри, Алсу белән Айсылу укытучылыкны сайлады. Безнең нәселдә гел педагоглар. Үзем дә, тормыш иптәшем дә 40 елга якын Яңа Кенәр интернат-мәктәбендә эшләдек. Бүген лаеклы ялда инде. Хатыным ягыннан да, минем яктан да укытучылар, тәрбиячеләр күп. Югары уку йортында Алсу – инглиз-гарәп теле, ә Айсылу – инглиз-татар теле юнәлешен тәмамлады. Алсу бүген инглиз телен укытса, Айсылу татар телен укыта», – ди Газинур абый Лотфуллин.

«Кияүдәме соң кызларыгыз?» – дип сорыйм. «Кызларга 34 яшь. Әле берсе дә кияүдә түгел», – ди эти кеше. «Читкә җибәрәсегез килми инде алайса, кыз бала шулай кадерле була шул», – диюемә Газинур абый: «Юк, бирәсебез килми, – дип әйтмим. Акыллы бәндәләр килеп сораса, без биреп җибәрербез. Әле сораучы юк. Бик әйбәт. Ашыкмасыннар әле», – ди бит һаман.

«Айсылуның 12 ел педагогик стажы бар. Ул арада инде нинди генә бәйгеләрдә катнашмады. Югары категорияле укытучы булып та өлгерде. Бу бәйгедә – «Иң яхшы туган тел һәм әдәбияты укытучысы – 2023»тә катнашу нияте барлыгы турында телефон аша гына сөйләде. «Азакка таба ук барыйм микән, катнашыйм микән», – дип икеләнгән төсле итте. «Катнаш, кызым», – дидек. «Бик авыр, катлаулы бәйге бит, эти, күп вакыт, көч һәм тырышлык кирәк, Владикавказга барасы булачак», – диде. Эшен, бакчадагы балаларын ташлап бәйгегә «чумасы» була, дигән сүзе иде инде ул аның. «Күңелеңдә калмасын, катнаш. Бу мөмкинлекнең башка булмавы да бар. Булган чакта катнашып кал» – дидек.

Шулай карар кылынды. Владикавказга юл тоттылар. Бик борчылып тордык. Ерак җирләргә, тау араларына китеп бардылар бит. Яман кешеләр

Айсылу Лотфуллина

очрамасын, бәла-казаларга юлыкмасын, изге кешеләр генә юлдаш булсын, дип берәзлексез теләп, укып тордык. Айсылу анда чакта гел аның өчен сорап догадан өзелмәдек. Бу җиңү – Аллаһтан бирелгән җиңү ул.

Сынау арты сынау үтә торгач, башта 35 катнашучыга калдылар. Аннары шуларның 15ен сайлап алганнар. Аннары 5 кешегә калдылар. Ул 5 кеше арасында кем генә юк иде... Мордовиядән, Якутиядән, әллә кайсы төбәкләрдән катнашучылар иде анда. Шуларның берсе – безнең Айсылу булды. Бишлеккә кергәч, җиңү ихтималы барлыгы аңлашыла иде. Берәзлексез Аллаһтан Айсылу өчен иң яхшысын, иң хәерлесен сорадык.

Кыз кешеләр әниләре белән күбрәк сөйләшә бит инде ул. Әнисенә шалтыратып торды гел. Әнисе миңа җиткерә. Бүген тегеләй иткәннәр икән, иртәгә болай эшләячәкләр икән, аннары шундый сынау була, бүген моңа әзерләнә икән, дип сөйләп торды әнисе.

Финалга 2 көн кала, Айсылу хәбәргә чыкмый башлады. Эшләре шулкадәр тыгыз, әзерләнүләре көчле иде. Бөтенләй сөйләшергә чара таба алмады. Борчылып, хәбәр көттек. Бүләкләү тантанасыннан соң Айсылу хәбәргә чыгар, дип, сабыр иттек.

Тик Айсылудан хәбәр килеп җитмәде. Кичкә таба бер мәлне иптәшем белән икебезнең телефоннар шартлый башлады. Трубканы алган саен «Котлыйбыз!» дигән сүзләр. Танышларыбыз да, бер белмәгән кешеләр дә шалтырата… Шаккаттык. Без бу яңалыктан бөтенләй телсез калдык. Бер-беребезгә карашып утырабыз. «Чын микән бу? Дөрес хәбәр микән?» – диешә башладык. Мәгәр Айсылу үзе шалтыратканчы, безгә сөенче хәбәр китереп җитештеләр. Куандык. Ул сөенеч хисе әле һаман өй эчендә эленеп тора. Чып-чын бәйрәм!» – дип искә ала Газинур абый.

«Горурлык хисен яшерә торган түгел. Бу – чыннан да бик зур җиңү. Минем үзем өчен бу – башка сыймаслык вакыйга: әллә кайда таулар арасына китеп бар да, фәлән кеше арасында көч сынаш һәм шунда җиңеп тә чык! Осетин балаларына татар теле дәресе биреп кара син... Горурланам. Ихластан горурланам Айсылу белән!» – ди эти кеше.

...Айсылу бәйгедәге сынауларның берсендә Владикавказ бакчасында осетин балаларына татар теле дәресе бирә.

«Осетин балаларына дәрес биргәндә, мин аларның татар сөйләмен кызыксынып тыңлауларына игътибар иттем. Әлбәттә, дәрес тулысы белән татар телендә бармады. Анда дәүләт телләре – осетин һәм рус теле. Дәресне рус телендә алып бардым. Татар телендәге сүзләрне кабатлап, җөмләләр төзеп карау балаларга кызык булды. Алар моны авырлык белән эшләде, әмма күзләре янып тора иде. Бу – уңышлы дәреснең төп ингридиенты. Балада кызыксыну уята алсаң, мәгълүматны җиткереп, аны нәрсәгәдер төшендереп була. Чит телнең яңгырашы аларга кызык тоелды. Күзләрен дә алмыйча тыңладылар. Шулай итеп дәрес бер тында үтеп китте», – дип искә алды тәрбияче.

Шуңа игътибар иттем – Айсылу әңгәмәдә дә җөмләләрен уйнатып, кызык итеп сөйли. Әйтерсең лә, ул һаман да дәрестә, без – бәләкәй балаларга бик кызык итеп дәрес аңлата сыман. Мөгаен, аның укучыларына дәресләрдә бик кызыктыр.

«Бәйге һәрберсе төпле әзерлек таләп иткән 4 этаптан торды. Этапларның һәрберсенә ныклап әзерләнергә кирәк иде. Берсен үтсәң, икенчесендә дә сынала аласың. Икенчесен үтсәң, өченчесенә дә узасы килә. Өченчедән дүртенчегә чыккач, җиңү теләге чиктән ашты. Беренче этапта без үзебезне визитка ярдәмендә тәкъдим итәргә тиеш булсак, икенче этапта балаларга дәрес биреп күрсәтергә тиеш идек. Өченче этап булып тәрбия дәресе бирү торды. Финалда без коллегаларыбызга мастер-класс күрсәттек», – ди Айсылу.

«Сынаулар программасы тыгыз булды. Төн йокыларыннан баш тартып, әзерләнеп чыктык. Эшләгәч, яхшы итеп эшлисе килде. Аннан-моннан гына катнашу өчен Владикавказга ук килмисең бит инде. Аннары мин бәйгедә зур җаваплылык хисе белән көч сынаштым. Мин Татарстаныбыз исемен яклавымны аңлый идем. Шул сәбәпле мин бәйгедә бик дулкынланып, зур җаваплылык тоеп, үземне күрсәттем. Татарстан данын күтәреп, исемебезне аклап, җиңүне үзебезнеке итеп кайта алуыбызга мин бик канәгать», – диде җиңүче.

Бу җиңүе Айсылуны татар телен, татар милләтен югарыга күтәрүче, аның дәрәҗәсен күрсәтүче, исемен аклаучы шәхес буларак тарихка керде. Айсылу татар тәрбиячесе булуы белән дә горурлана.

«Бәйгедә, иркенләп, үз телебездә – татар телендә сөйләшергә тырыштым. Безнең тел дә яңгырасын, безнең телне дә ишетсеннәр, дидем. Татарстаннан килүем әллә каян күренеп, күзгә ташланып торсын, дип тырыштым. Төрле тел укытучылары, тәрбиячеләр арасында татар тәрбиячесе булуымны горурлык белән күрсәттем. Мин мәктәбемә, Казаныма, Татарстаныма җиңү алып кайтуым белән бик бәхетле», – дип тәмамлады сүзен Айсылу.

Регина ГАБДРАХМАНОВА.

Айсылуның шәхси архивындагы һәм Абдул Фархан фотолары файдаланылды.

Теләкәй чишмәсе

(Ахыры. Башы 10 нчы биттә.)

Менә шул ат урлаган өчен дә каракларны каен ботагына асып куймаска мөмкиннәр. Кеше үтергән өчен тимерчыбыклар аралап үрелгән камчылар белән тотып яргannan соң чиркәүдәге атакай каршына китереп бастырырлар. «Йә үзеңне богаулап Себергә сөрәбез, йә син изге тәрене тагарга ризалашасың», дип бичара татарларны ике ут арасына кертеп газаплаганнар. Бәндәләр арасында эченә корт төшкәне, сыгылма биллесе, куркак җанлысы бар. Татарларның һәммәсе дә Теләкәй морзадай башын җуйса да ирегенвә рухын сатмый торган пәһлеваннар түгел. Начарлык юрагандай ялгышудан куркам, әмма синең туганнарың арасында да Коръән урынына тәре үбә башлаячак сатлык җаннар бик күп булыр әле.

Качак Федор нотыгын төгәлләгәндәй тып-тын утырды да янә кыяр-кыймас кына өстәп куйды:

– Сиңа әлегрәк әйтергә кыймаган идем дә, утлы күмерне куенда яшереп йөртүе дә кыен. Мин әле качып киткәнче, Мәскәүдә чагында ук стрелецлар башлыгы Васька Голицын бүлмәсендәге бер сөйләшүне ишетеп калдым. Башыннан азагына кадәр түгел, ярты-йорты гына. Уфада утырган воевода Коркодинов яшь патшалар исеменә атап хат юллаган. Аны әүвәл юха елан Софья эләктергән, аннары хатны Голицын кулына биргән. Коркодинов татар морзалары өстенә чиләк-чиләк дегет сибеп чыккан. «Морзалар волость старшиналарын да, тулаем халыкны да патша хакимиятенә буйсынмаска, кирәк була калса, корал белән каршы торырга чакыра». Мин бу сүзләрне мич артына кереп баскан җиремнән генә, чак ишетеп калдым. Бу як калалардагы воеводалар, Софья хөкүмәте белән сүз беркетеп, сезгә каршы тагын яңа этлек әзерләмәсә генә ярар иде инде.

– Алар соңгы елларда болай да чамасыз күп этлек кылып өлгерде, – дип Теләкәй бер учының бармакларын җәйде. – Юри санап карыйк. Чулман аръягында чик линиясен төзибез, дигән булып, Чаллыдан башлап Сәмәргә чаклы ничәмә-ничә кирмән корып куйдылар. Һәр кирмәндә даими гарнизоннар, стрелислар нөгәре тупланды. Барчасын берьюлы әйләндереп атарга кодрәтебез җитми. Патша бурзайлары татарларга тимерчелек алачыкларын булдыруны, корал ясауны тыйды. Без ат дагалатырга, арба тәгәрмәченә тимер кыршау кидерергә кирәк булса да йә башкорт, йә чирмеш тимерчеләре алдына барып тезләнәбез. Шул сәбәпле, ахры, һичбер авылда да корал базлары, корал келәте юк. Ә коры кул белән, чамалыйсың булыр, күк йөзен дә төртеп тишеп булмый...

Инде аягурә торып баскач кына, Теләкәй үз күңелендә туган иң зур хәвефне ярып салды.

– Татарлар иленә тагын көчләп чукындыру атлы афәтнең әйләнеп кайтуы бар...

2022 ел, Казан.

(Роман тулысынча «Казан утлары» журналының 2023 елгы октябрь санында басылды).

Мәдәни җомга
17 ноябрь
№45, 2023

Суслонгерда, бабам эзеннән...

«Суслонгер» дигән сүзне кечкенә вакытта Зәйтүнә әби авызыннан күп ишетергә туры килде. Ләкин бу сүз эченә күпме җан ачысы, әрнү-сыкрау һәм югалтулар яшеренгән булуы еллар үткәч кенә аңлашылды.

– Бабагыз иртә китте шул. Суслонгерда үпкәсенә салкын тидергән булган. Шуңа сугышта алган яра да өстәлгән иде, – дип сөйли иде безгә әнкәй.

Соңгы вакытта интернет челтәрләрендә Суслонгер хәрби лагерьлары турында язмалар күп чыкты. Илен саклау өчен кулына корал алган ир-егетләрне сугышка әзерләү өчен хәрби лагерьларга туплаганнар. Суслонгерда исә аларны ачтан интектергәннәр, бик күпләре сугыш кырына да барып җитә алмыйча, биредә һәлак булган.

Туганым, «Шәһри Казан» газетасы журналисты Гөлнур Шәрәфиева белән улларыбызны алдык та Марий иленә сәяхәткә кузгалдык. Суслонгер авылына барып кердек. Авыл уртасында заманча кибетләр, матур йортлар каршы алды. Мәчеткә аерым игътибар иттек. Димәк, биредә татарлар яши. Безнең әлеге лагерь урынына барасыбыз килә. Сораша торгач, юл күрсәтүче дә табылды. Бер ир кеше безне урман юлына кадәр озатып куйды да, аңлатып җибәрде.

Аллага тапшырып, 8 чакрым арага, Мари урманы эченә кереп киттек. Шомлы, сикәлтәле урман юлы... Артыбыздан бер эт тә ияргән.

– Ярый ла без машина белән барабыз. Сугыш елларында Суслонгер лагерена ирләренә ашарга алып баручы хатын-кызлар әлеге урман эченнән йөзләгән чакрым юлны җәяү узганнар. Аякларында чабата, җилкәләренә үзләренә дә чамалы гына булган ризык тутырган капчык асып барып та, ирләрен таба, ризыкларын тапшыра алмыйча кайтучылар да күп булган, – дип сөйләп бардым балаларга.

Озак баргач, һәйкәлләр янына килеп чыктык. Кызыл кирпечтән ясалганы тирәсендә лагерьда кулланган әйберләр, калай савыт-сабалар куелган. Шунда ук исемсез каберлекләр дә күренә. Тагын берничә һәйкәл барлыгына игътибар иттек. «Суслонгер хәрби өйрәтү үзәгендә газаплардан һәм йончыгулардан һәлак булган безнең якташларыбызга мәңгелек истәлек», – диелгән мәрмәр ташларны Югары Ослан, Саба, Теләче һәм Кукмара районнары урнаштырган.

Кире юлга борылганда авыл уртасындагы зәвык белән эшләнгән мәчеткә тукталдык. Сораша торгач, мәчет салдыручы Илгиз Кәримовның өен эзләп таптык. «Без Татарстаннан», – дип таныштырдык. Туганнары кебек, кочак җәеп каршы алдылар. Илгиз абый хәрби частьларда хезмәт итеп, отставкага чыгып, тормыш иптәшенең туган авылына кайтып урнаша. Улы Азат белән шәхси эшмәкәрләр.

– Суслонгер лагерьында һәлак булган солдатлар рухына мәчет салдыру теләгем барын әйткәч, авылыбызда яшәүче татарлар күтәреп алды. Бергә һәм бердәм булып башкардык бу эшне, – диде ул.

Суслонгер авылын эзләп табу барыбызда да горурлык хисе уятты. Балаларыбыз өчен дә патриотик тәрбия булды.

Гүзәл ХИЛАВИЕВА.

Пермьдәге

Пермьнән әллә ни ерак түгел тарихи бер татар авылы бар, ул Коян, дип атала. Дөрес, исеме бәхәсле, аның Тасим дигән икенче атамасы да бар, ул шушы авылга нигез салучыларның берсе Тасим Мәмәтов исеме белән бәйле, диләр. Авыл исемен Каян, Куян, дип тә, хәтта русчадагы «окаянный» сүзе белән дә бәйләүчеләр бар, әмма дөресен белүче юк. Тарихи документлардан күренгәнчә, Коян-Тасим авылына 1689 елда нигез салынган, әмма авыл тагын да борынгырак булырга мөмкин, чөнки урыны бик җайлы, җирләре тимер рудасына бай, тирә-якта татар авыллары да шактый. Иң мөһиме – узган гасырларда бу авыл Уралда ислам үзәкләренең берсе булган, анда ике мәчет, мәдрәсә эшләп торган, Кояннан шактый гына билгеле шәхесләр чыккан.

Пермьгә сәфәрем вакытында әлеге Коян авылына да бардым, борынгы мәчетен, халкын күрәсем килде. Интернетта Коянны башкорт авылы, дип, ә халкын – татарлар, рәсми тел – урыс теле, дип язганнар. Менә шундый киш-миш күрәгә килеп чыккан. Ә нәтиҗәдә, Коян менә дигән татар авылы булып чыкты, мәчеттә без халык белән бары тик татарча гына аралаштык. Алай да, башкорт темасы кутәрелмичә калмады, бу хакта кешеләр үзләре сорау бирде: «Без кем соң, татарлармы, башкортлармы», дип сорадылар. «Үзегезне кем дип хис итәсез соң?» – дим. «Үзебез дә татар, телебез дә татар, халык саны алганда да татар дип язылдык», – диләр.

Әйе, бу дөрес, Коян – борынгы татар авылы, ә нигә аларга башкорт атамасы да ябышкан соң? Моның да тарихи сәбәпләре бар. Билгеле ки, узган гасырларда халык исәбен алганда, кайбер урыннарда татарларны, сословие-катлам буенча, башкорт, дип язганнар. Чираттагы халык санын алганда алар яңадан татарга әйләнгән. Кыскасы, татарны башкорттан аермаган патша чиновниклары да бутаган яки татарны киметер өчен махсус шулай эшләгән, хөкүмәт башкортларга җирне күп биргәнгә, кайбер татарлар үзләре дә кызыгып, башкорт дип язылган. Бүгенге башкорт эмиссарлары, шушы халык исәбен алу документларына таянып, гасырлар буе татар булып яшәгән авылларны башкортныкы, дип игълан итә башлады. Нәтиҗәдә, халык икегә бүленде, шулай итеп, Уралда татарча сөйләшә торган «гайнә башкортлары» барлыкка килде. Алар кәгазьдә – башкорт, гамәлдә – татар. Бу «кәгазь башкортларның» татарча сөйләшүен муллалардан күрәләр, имеш, гасырлар буе мәчет-мәдрәсәләрдә татарча укытып, алар башкортларны бозган икән, телләрен онытырганнар. Ай-һай, мулла-абыстайлар татарча укытып кына, авыл хәтле авылның, халык хәтле халыкның телен тамырдан үзгәртеп буламы икән? Юк, әлбәттә, тел дә, милләт тә, холык-менталитет та кәгазьгә язганга карап кына үзгәрми ул, аның төп калып-матрицасы барыбер саклана, татар – татар булып, башкорт – башкорт булып кала.

Башкорт галимнәренең язуынча, имеш, Коян авылы халкы элек-электән башкортча сөйләшкән, бары тик XIX гасырда гына татарчага күчкән икән. Бу да дөреслеккә туры килми. Уфа өязе буенча беренче ревизияләрдә Коян һәм Култай авылы халкы мишәрләр, дип язылган. Коян авылында татарлар яшәвен А.Н.Радищев 1790 елда ук язып калдырган. Ул, «Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт» дип аталган китабы өчен Себергә сөрелгән каторжан буларак, Коян авылындагы этап төрмәсендә төн кунган. «Выехали из Перми. До Каянова, или Тасимки, 24 версты. Живут татары», дип язган ул. Әйе, Коян авылы Себер трактында, каторжаннар юлында урнашкан булган, ягъни, стратегик яктан зур әһәмияткә ия урын. Заманында ул волость үзәге дә булып торган. Җирле халык, игенчелек һәм терлекчелектән тыш, тирә-юньдә тимер рудасы казу белән дә шөгыльләнгән, аны металлургия заводларына тапшырганнар. 1735-1740 елгы халык күтәрелешләре вакытында җирле халык белән урыслар арасында каты бәрелешләр була, урыслар Коянга һөҗүм итә, татарлар Көнгер якларына качарга мәҗбүр була. Бәлки «окаянный» атамасы да авылга шул чакта ябышып калгандыр, аннан Коян-Куянга әйләнгәндер...

Каторжаннар юлындагы этап төрмәләренең кирәге калмагач, Коян авылында ул бинада хөкүмәтнең һөнәр мәктәбен ачалар, анда агач эшенә өйрәтәләр. Революциядән соң бу бинада детдом ачыла, аннары клуб, китапханә була. Ә 1943 елда элеккеге этап төрмәсе бинасына Пермьнән татар педучилищесын күчерәләр, анда төбәктәге 150 татар мәктәбе өчен башлангыч сыйныф укытучыларын әзерлиләр, педучилище Коянда 1955 елга хәтле эшли. Авыл бик зур була, 1926 елда биредә 2238 кеше яшәгәнлеге билгеле. Соңгы елларда авыл яртылаш кимегән, 1995 елда биредә 1180 кеше үзен татар, дип яздырган, 6 кеше – башкорт, дип. Хәзер анда меңгә якын кеше яши, әмма соңгы халык саны алу буенча нәтиҗәләрне белүче юк.

Әйткәнемчә, авылда ике мәчет һәм мәдрәсә булган, мәдрәсәдә 120 ир-ат, 53 хатын-кыз укыган. Мәчетләрнең берсе 1750, икенчесе 1885 елда төзелгән, соңгысы хәзер дә эшли, без шунда намазларыбызны укыдык, очрашуны да шунда уздырдык. Мәчетнең диварына 1898 ел, дип язылган истәлек тактасы куелса да, бу дөреслеккә туры килми. Бу мәчет урынында иске мәчет торуын да искә алсак, аның тарихы 200-250 еллар булырга тиеш. Коян авылы мәчете Пермь төбәгендә иң борынгы мәчетләрдән санала. Совет хакимияте урнашкач та, бу мәчеткә халык озак еллар кагылдырмый, бирми, бары тик сугыш еларында гына ул эшләвеннән туктап тора. 1948 елда Коян авылы татарлары Мәскәүгә барып, мәчетне яңадан ачтыруга ирешә, ул Пермь төбәгендә рәсми рәвештә эшләгән бердәнбер мәчет була. Әле Горбачев заманында да Коян авылы татарларының Мәскәүгә Горбачев янына, мәчет мәсьәләсендә барганлыгын сөйлиләр. Элек халык бу авылда динле нык тоткан, хәтта Коръәнне яттан белүче хафизлар һәм хаҗилар да булган.

Авылны репрессия золымы да әйләнеп үтми, монда да иң укымышлы, иң булдыклы, иманлы татарларны чүпләп юк итәләр. Коянда репрессияләргә 28 кеше эләгә, шуларның алтысын 1937 елның 20 сентябрендә атып үтерәләр. Мәчет нигезендә аларның исемнәре язылган истәлек ташы тора, менә алар:

Апкин Габделхәй – мәчет мөтәвәллияте рәисе;

Апкин Зәкәрия – мәчет-мөтәвәллият әгъзасы;

Апкин Габделгазиз – мәчет-мөтәвәллият әгъзасы;

Бактиков Зөфәр – 1931 елны кулга алынган мулланың улы;

Мингалиев Габдрахман – мәчет-мөтәвәллият әгъзасы;

Мурсалимов Габделхәй – мәчет-мөтәвәллият әгъзасы;

Тайсин Муллаҗан – мулла.

Бөек Ватан сугышына Кояннан 400 ир-егет китә, шуларның яртысы гына туган авылларына әйләнеп кайта, алар арасында гарип-горабалар күп була. Шуңа карамастан, авыл сугыштан соң да әле аякта кала, СССР җимерелгәндә дә юкка чыкмый, хәзер дә яшәргә тырышып ята. Коян авылында урта мәктәп, балалар бакчасы, мәдәният йорты, китапханә, фельдшер амбулаториясе, шәхси кибетләр, кафе, ашханә эшләп килә. Халык мал тота, фермерлык белән шөгыльләнә, нефтьтә эшли, Пермьгә йөреп хезмәт куя, ягъни, үз тамагын үзе туйдыра. Әмма кайчандыр волость үзәге булып торган авылда соңгы вакытта авыл советын да калдырмаганнар, аны Лобоново дип аталган урыс авылына күчергәннәр. Ни кызганыч, хәзер инде милли як та шактый аксый, мәктәптә

Коян авылы

укытулар нигездә рус телендә генә. Әйткәнемчә, мәчет бар, анда укытулар да алып барыла, әмма халыкны элеккечә үк диндар, дип булмый. Авыл мулласы Нурмөхәммәт хәзрәт Алапанов һәм Пермь крае мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Рәхмәтуллин белән болар хакында борчылып сөйләштек, халкыбызны элеккечә иманга кайтару өчен нишләргә икәнен киңәштек.

Мин мәчеткә җыелган халыкка бу төбәктә ислам диненең таралу тарихын сөйләдем, иң куркыныч заманнарда да динен ташламаган әби-бабаларыбыз турында, чукынмаган өчен утта яндырып үтерелгән Кисәнбикә Бәйрасова, Аллаһ дигән өчен теле кисеп алынган, гомерлек төрмәгә ябылган Батырша хәзрәтләр турында сөйләдем, алар барысы да шушы яклардан бит! Халык үз төбәгендә көчләп чукындырулар тарихын да, дин-ислам өчен шәһит киткән әби-бабаларын да белми. Димәк, аларның таш баса башлаган күңелләрен шушы фаҗигале һәм бөек тарих белән кузгатырга, уятырга кирәк булачак, чөнки милли үзаңы уянмаган халыкның киләчәге юк, ул телен дә, динен дә, үзен дә югалтачак...

Коян авылы үз тарихын үзе язган, бу авылдан күп кенә танылган шәхесләр дә чыккан. Шуларның иң билгелесе – Исмәгыйль Тасимов, ул 1773 елда Петербургтагы тау училищесына нигез салучы (хәзер институт), тимер рудасы буенча эре эшмәкәр, аның үз авылы янында да унбишләп тимер базы була. Дөрес, башкортлар бу шәхесне инде үзләренеке иткән, Башкортстанның Россия составына ирекле кушылуына 450 еллыкны сәбәп итеп, Уфадан килеп, 2007 елның 21 ноябрендә Коян авылы мәктәбе диварына истәлек тактасы элеп киткәннәр, әлбәттә инде, Исмәгыйль Тасимовны башкорт халкының каһарман улы, дип... Бүген Тасимовларның нәселе юк, дип баралар, әмма, миңа калса, бу нәселнең интеллектуаль дәвамчылары Тайсиннар булырга тиеш...

Бүгенге танылган Тайсиннар арасында Казанда яшәүче география фәннәре докторы Әнвәр Тайсин, философия фәннәре докторы Эмилия Тайсина, Германиядә яшәүче нәшер, тәрҗемәче Алия Тайсинаны атап үтәр идем. Алия – тел белгече, ул минем «Ядерный архипелаг или атомный геноцид против татар» китабын алман теленә тәрҗемә итеп, 2006 елда Берлинда үз нәшриятында бастырып чыгарган иде, без бу китап белән 2007 елның мартында Германиянең Лейпциг шәһәрендә үткәрелгән халыкара китап ярминкәсендә дә катнаштык. Алия Тайсина шулай ук «Урал батыр» дастанын һәм «Сак-Сок» бәетләрен, Вахит Имамовның «Татарларның Ватан сугышы» китабын да алман теленә тәрҗемә итеп бастырды, үз нәселе, Коян авылы турында да хезмәтләр язды. Кояннан чыккан танылган галимнәр арасында медицина фәннәре докторы Равил Кузяев, медицина фәннәре кандидатлары Ф.М.Вәлиева һәм К.Б.Самерханова, техник фәннәр кандидатлары Ф.М.Мурасов һәм Р.Г.Сәфәров, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты С.М.Хаҗиева, тарих фәннәре кандидаты Г.С.Мурсалимов та бар. Тарихчы Ганс әфәнде Мурсалимов туган авылы турында китап та язган. Бу саналган шәхесләр арасында, архив документларына, ревизия материалларына таянып, үзләрен башкорт дип атаучылар да бар. Монысы һәркемнең үз эше, әлбәттә, диндә дә, милләттә дә көчләү юк, әмма моннан чыгып кына, бөтен авылны, аның данлы тарихын башкортлаштыру дөрес түгел.

Октябрь революциясеннән соң Тайсиннарның кайберләре Россиядән китә, Ерак Көнчыгыш, Кореялар аша Япониягә барып урнаша. Чыгышы белән Кояннан булган Саимә Тайсина-Касыйм Токиода беренче ислам җәмгыяте төзүдә башлап йөри, алар биредә мәчет-мәдрәсәләр нигезли, мәктәпләр ача. Әнисе ягыннан үзе дә Тайсиннар нәселенә барып тоташкан Чаллы эшмәкәре, төбәк тарихын өйрәнүче Рафаил Адутов аларны эзләп, узган гасырда Япониягә барып чыга, туганнарын таба, алар белән ярты гасыр буе аралашып яши. Ул 2006 елда Чаллыда «Татаро-башкирская эмиграция в Японии» – «Япониядәге кардәшләребез» дип аталган документаль китап бастырып чыгарды, анда Тайсиннарга да күп урын бирелгән. Коянда да Рафаил Адутовны һәм аның бу китабын яхшы беләләр икән, шуңа күрә, очрашуда Япониядәге Тайсиннар турында да сөйләшү булды. Дөрес, бу Тайсиннарның нәселләре инде анда калмаган, дөнья буйлап таралган, аларны хәзер Америкада, Төркиядә һ.б. илләрдә очратырга мөмкин.

Күргәнегезчә, Уралдагы бер татар авылында гына да күпме тарих, күпме язмыш! Әмонда бит йөзләгән татар авылы, татарлар нигез салган һәм яшәп яткан дистәләгән шәһәр, халкыбызга хезмәт иткән меңләгән шәхес... Әдөнья буйлап таралганнары күпме! Менә бу үзе үк инде милләтебезнең никадәр бай, булдыклы, рухи яктан көчле, гайрәтле халык икәнен күрсәтә. Тарихта шулай булган, әле бүген дә шулай, инде киләчәктә дә татар халкы көчле һәм гайрәтле булып калсын иде!

Фәүзия БӘЙРӘМОВА,
язучы, тарих фәннәре кандидаты.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

18 ноябрь (шимбә). ***Җөмәдел әүвәл аеның 5 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 13.47 сәгатьтә калка, 20.19 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 8.09 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә әти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул, үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

Эч кипкәндә

Эчне йомшарту өчен, 3 чәй кашыгы эт шомырты (зирексыман кошкунмас дигән исеме дә бар – крушина) кайрысы, 1 чәй кашыгы меңьяфрак үләне, 2 чәй кашыгы кычыткан яфрагын кушып, шуның 1 аш кашыгын 2 стакан кайнап торган суга салалар, 10 минут пешереп, марля аша сөзәләр, йокларга ятар алдыннан ярты-бер стакан эчәләр. Яисә 3 чәй кашыгы эт шомырты кайрысы, 1әр чәй кашыгы кычыткан яфрагы һәм чебен кунаксасы (кандала үләне дә диләр – донник) үләнен кушып, шуның 1 аш кашыгын 1 стакан кайнар суда 20 минут төнәтәләр, марля аша сөзәләр, төнгелеккә ярты стакан эчәләр.

19 ноябрь (якшәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 6 нчы көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 14.08 сәгатьтә калка, 21.58 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 8.06 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Май сихәте

Тырнак катламланса, болай дәваланып була. 100 грамм зәйтүн маена берничә тамчы лимон согы тамызып, шуны тырнакка сөртәләр дә, киҗе-мамык перчатка киеп йокларга яталар. Атнасына 2 тапкыр сөрткәндә, 1 айдан соң тырнак тулысынча сәламәтләнә.

20 ноябрь (дүшәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 7 нче көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 14.21 сәгатьтә калка, 23.37 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 8.02 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Тозлы су

Тешләрне саклау, аңкауларны ныгыту, авыздагы сасы исне бетерү өчен, даими рәвештә иртән һәм кичен авызны тозлы су (1 стакан суга 1 аш кашыгы тоз) белән чайкыйлар.

21 ноябрь (сишәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 8 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 14.37 сәгатьтә калка, 1.13 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.59 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин.

Гаймориттан дәва

Помидор сабакларын сындырып алып, сүрән утта бераз пешерәләр. Калын сөлге белән томаланып, 10-15 минут шуның парын сулыйлар: авыз белән сулыш алу-борыннан чыгару, борын аша сулыш алу – авыздан чыгару. Берничә минуттан борыннан су ага башлый. Сеңгерәләр дә, пар ингаляциясен дәвам итәләр. Бу процедурадан соң урамга чыгарга ярамый, шунлыктан аны йоклар алдыннан ясау яхшы. Гаймориттан тулысынча савыгу өчен, берничә тапкыр шулай дәвалану җитә.

22 ноябрь (чәршәмбе). ***Җомәдел әүвәл аеның 9 нчы көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 14.40 сәгатьтә калка, 2.46 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.55 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

23 ноябрь (пәнҗешәмбе). ***Җомәдел әүвәл аеның 10 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 14.48 сәгатьтә калка, 3.39 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.52 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уянырга мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

Сызлавык интектерсә

Чуан чыгып интектерсә, суган кабыгын әз генә суда 5 минут пешерәләр, шулкадәр үк күләмдә вакланган бака яфрагы үләне кушалар, куе камыр барлыкка килгәнче он өстиләр. Кабартма ясап, аны сызлавыкка ябыштыралар, өстеннән бәйлиләр. Чуан сытылгач (гадәттә, 1-2 тәүлектән соң), тирене спирт белән чистарталар.

24 ноябрь (җомга). ***Җомәдел әүвәл аеның 11 нче көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 14.56 сәгатьтә калка, 4.19 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.48 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Каймаклы баклажан

2 баклажанның кабыгын чистартып, 1 сантиметр калынлыкта түгәрәкләп турыйлар да, тугланган йомырка салып болгаталар, ике ягын да үсемлек маенда кыздырып алалар. Табага тезеп, өстенә төрле тәмләткечләр, тоз сибәләр, каймак салалар һәм, капкач каплап, 5 минут пешерәләр. Табынга укроп, петрушка сибеп бирәләр.

«Төрекләр туп атканда безнең күңел боектыр»

(1877-1878 елгы урыс-төрек сугышында татарлар)

Россия империясендә яшәгән татар-мөселман халкының дәүләт тарихында булган һәр вакыйгага да катнашы булган. Алар да башка халыклар белән бер рәттән салымын да түләгән, армиясен дә үткән, сугышларында да катнашкан. Алар да яу кырларында дәүләт өчен башларын салган. Татарларның бу вакыйгалардагы ачы язмышлары, аларның югалтулары, ни кызганыч, әлегә кадәр бар булганы белән яктыртылганы юк. Татарлар өчен, урыс армиясе составында, мөселман дәүләтләр белән булган конфликта катнашулары аерым бер күңел халәте, аерым бер ачы язмышы. Татар кешесе ике ут арасында: үтәргә тиешле бурычы белән, күңел хәяте, вөҗдан газабы арасында кала. Мондый вакыйгалар татар өчен икеләтә, бәлки әле меңнәрчә зур хәсрәттер.

Шундый авыр хәл 1877-1878 елда төрекләр белән барган сугыш, ул татар җәмгыятенә тирән эз сыза, тирән яраларын калдыра. Сугыш беткәннән соң да аның кайтавазы татар тормышында озак вакыт дәвам итә. Татарлар да төрек белән сугышу өчен гаскәргә алына, сугышка алынучыларны озату күренеше үк татар кешесендә аптыраш уята, сугышка китүчеләрнең күңелен күтәрү максатыннандыр инде, химаячеләр акчасына аракы, ак ипи белән сыйлыйлар. Дини гадәтләрне үтәгән, хәмерне хәрам дип кабул иткән татар кешесе өчен бу хәл ничек кабул ителергә тиеш?! Дәүләткә хезмәт итүче буларак, мәчет муллалары да бу сугышта урыс армиясенә җиңү теләп дога кылалар. Шулай итеп, татар җәмгыяте үзе үз эчендә икегә бүленә. Ул Россия дәүләте кешесе буларак, аның мәнфәгатьләре өчен көрәшергә мәҗбүр булса, икенчедән, эчке хәятенә каршы барырга тиеш була.

Бу сугыш татарлар арасында үзенә күрә бер азатлык көрәшен башлап җибәрә, аерым алган төбәкләрдә үз идарәләрен булдыруга омтылыш ясала. Мәсәлән, Янгилде дигән авылда Фәйзулла Хисмәтуллин белән Габдулла Гаффаров дигән ике кеше татарларның үзидарәсе хокукларын булдыру, дин иреге, хәрби хезмәткә алынганнар өчен ясак түләмәү өчен көрәшүгә үз җәмгыятьләреннән акча җыялар. Икесе дә сату-алу белән шөгыльләнүче гади генә кеше булуларына карамастан, халык арасында абруй казаналар, халык аларның сүзен тыңлый, хөрмәт итә. Халыктан җыйган 120 сум акчасын, халык сүзләреннән билгеле булганча, Хисмәтуллин Казанга сәүдәгәр Казаковка җибәргән, ә Казаков исә Төркиядә озак еллар яшәп кайткан Зөя өязенең бер татары беләнТөркиягә барырга җыена икән, дигән хәбәрләр тарала. Жандармия документларында аларның җитәкчеләре Хисмәтуллин власть өчен куркыныч кеше, диелә. Чынлап та, алар аерым бер татар авылында үзидарәләрен урнаштыралар да. Бар гамәлләре дә Хисмәтуллин ризалыгы белән генә башкарыла, дәүләткә ясак бирми башлыйлар.

Татар авылларында хәл катлаулы була, сугышка киткән солдатлар арасында да хәл җиңелдән булмый. Русия белән төрекләр арасында башланган сугышта татар кешесе Русия армиясе составында үзенең кардәше – төрек армиясенә каршы барырга мәҗбүр була. Бу – татар солдаты өчен зур фаҗига.

Сугыш кырында да бу фаҗигага сыкрап, язмышларына бу хәлгә калдырган өчен рәнҗиләр. Бу сугышта татарларның халәтләрен ачык күрсәтә ала торган чыганаклар – алар татар бәетләре. Алар аша татар кешесе күңелендә булган чын халәтне, кичерешләрен ачып бирә алган. Шул вакытта татарлар тарафыннан язылган бу кулъязмалар, начар хәлдә генә булса да, хәзергә кадәр сакланып калган.

Дунай суы агымсу,
Тибеш икән агуы.
Бигрәк авыр икән
Төреккә каршы баруы.
Төрек йиренә чыккачдин
Барып кердек калага
Бу хәсрәтне Хак язмасын
Һич мөселман балага.

Татар-мөселман кешесе шул дәүләт әгъзасы буларак урыс армиясендә сугышырга мәҗбүр булса, аның рухы барыбер мөселман ягында, ул бу сугышта мөселманнарның кырылуы, мәсҗедләрнең җимерелүенә кайгыра.

Безнең якдин аткан туплар
Бары коела чокырга.
Мәсҗед тулы китап-Корьән –
Бары кала кяфергә.
Дунай суын чыккачдин
Утырттылар олауга.
Хәтта йир-күк иңрәде
Мөселманнар йыглауга.
Мендем төрек тавына,
Төрек тавы биектер.
Төрекләр туп атканда
Безнең күңел боектыр.

Урыс-төрек сугышы татарлар тарафыннан диннәре төрле булган ике хәятнең конфликты итеп кабул ителә. Төрек солтаны армиясенең бу сугышта җиңелүе Русиядәге татар җәмгыятенең тынычлыгын бетерә. Сугыштан кайткан урыс солдатлары «төрекне җиңдек, хәзер барлык мөселманнарны да чукындырачаклар», дигән сүзләр таратыла. Мөстәкыйль дәүләтен югалтканнан бирле чукындырылу белән куркытылган татар кешесе өчен бу хәл аеруча куркыныч була. И.Гаспринский язганча, хөкүмәткә каршы башланган хәрәкәтләр Касыймнан башлап Ташкентка кадәр, Пермьнан Ленкоранга кадәр җәелә. Крестьяннар тарафыннан баш күтәрүләр Самара, Уфа, Сембер, Вятка губерналарында да күзәтелә. 1878 ел башына хәл аеруча кискенләшә, властьларның һәр адымы татар җәмгыяте тарафыннан христианлаштыру итеп кабул ителә башлый. 1878 елда янгын куркынычсызлыгы өчен чыгарылган инструкция, хәтта, Казан өязендә крестьяннарның зур күтәрелешен китереп чыгара. Инструкциянең бер пункты итеп янгын куркынычсызлыгын күзәтү өчен авылларда каланча төзү тәкъдимен татарлар мөселман авылларында чиркәү сала башлыйлар, дип кабул итәләр, чөнки алар каланчаны чиркәүгә охшата. Гомумән, һәр нәрсәне татар куркып каршы алган, аның өчен иң куркыганы чукындыру була. Янгын куркынычсызлыгы өчен кабул ителгән инструкцияне дә халык чукындыру белән бәйле булырга мөмкин дип кабул итә, шуңа да халык арасында зур күтәрелешләр башлана. Хәтта халык күтәрелешләрен бастыру, халыкны сугтыру өчен Казан губернаторы Н.Я.Скарятин үзе халык өстенә гаскәр белән бара.

Шушы елларда хәлле татарларны руслар төректән яулап алган җирләргә күчерә башлыйлар икән, Зөя өязендә писарь шундый татарларның исемлеген төзи башлаган, дигән хәбәр тарала. Бу сугыштан соң тагын бер зур буталыш 1897 елда Россиядә халык санын алган вакытта була, монда да татарлар чукындыру куркынычын күрә. Бу хәлдә сиены урыны итеп төрек җиренә, төрекләргә өмет белән карыйлар, алардан ярдәм көтәләр. Шушы чорда, бигрәк тә, Чистай өязеннән төрек җиренә күченеп китүчеләр күбәя. Татар әдәбиятында шул чорны чагылдырган, бу елларның бар фаҗигасын күрсәткән Мәхмүд Галәүнең «Болганчык еллар», яисә «Мөһаҗирләр» дигән әсәре бар.

Урыс-төрек сугышының нәтиҗәсе, аның бу сугыштан җиңелүе буларак чыгышы татар җәмгыятендә зур шаукым ясый, бу сугыш татарда милли-дини хәрәкәт барлыкка китерә. Бу – бер яктан фаҗигале бер чор булса да, сугыш нәтиҗәсе буларак татар җәмгыяте үз динен, милли йөзен саклау көрәшенә әзер икәнен, властьларга аларның мәнфәгатьләрен исәпкә алып эшләргә кирәген дә искәртә. Үзчиратында хөкүмәт кешеләре дөрес сәясәт алып барылмаган очракта зур күтәрелеш килеп чыгу мөмкинлеген аңлый.

Эльмира САЛАХОВА,
тарих фәннәре кандидаты
(канал «Татарский мир»,
https://dzen.ru)

Өч рәссамлы авыл

Һәркемгә үз авылы, аның матур табигате газиз. Аның тарихын, күренекле шәхесләрен белү, аны киләчәк буынга тапшыру – һәрберебезнең дә изге бурычы. Иске Кормаш мәдәният йортында узган «Өч рәссамлы авыл» исемле кичә дә нәкъ менә шул максаттан үткәрелде.

Иске Кормаш башка авыллардан үзенең хискә, җырга, моңга, сәнгатькә гашыйк кешеләре белән аерылып тора. Элек-электән ул алыш-биреш, сәүдә үзәге булган, базары гөрләп торган. Авылда татар дөньясын шаулаткан күренекле шәхесләрнең үсеп чыгуы тикмәгә түгел, моның тамырында әнә шул гореф-гадәткә тугрылык, рухи һәм физик ныклык, белемгә һәм матурлыкка омтылу ята. Йә, әйтегез, илебездә танылган өч рәссамлы авыл тагын кайда бар? Ниндиләр бит әле – илдә һәм дөньяда танылганнар! Якташыбыз, шагыйрә Фәйрүзә Мөслимованың шигырь юллары да тикмәгә генә язылмагандыр:

Безнең авыл иң матуры дисәм,
Үпкәләмәс микән башкалар?
Беренче кат безгә килгән һәркем
Үз җаныңа тиңдәш ямь табар.
Карашларын биһуш итеп, шул ямь
Өч рәссамны бүләк иткән безгә.
Үткәннәрне барлап,
Киләчәккә карап
Иҗат белән яшибез бит без дә...
Безнең авыл иң матуры дидем.
Башкалар да, әйе, ким түгелдер.
Яшәү яме, хикмәте дә шунда:
Һәр кешегә үз авылы матур,
Үз авылы гүзәл, бердәнбер...

Сәнгатькәрләрнең иң өлкәне Әсгать Сәфәргалинның сикәлтәле тормыш юллары туган җиреннән аерып, бик еракка, Украинага ук илтеп ташлый. Рәсем сәнгатенә дә ул шунда өйрәнә, Харьков сәнгать институтын тәмамлый. Бөтенсоюз һәм чит ил сәнгать күргәзмәләрендә катнаша башлый, үзен талантлы рәссам итеп таныта. Ләкин җиңүләр җиңел бирелми, җитәкчелеккә аның татар миллətеннән булуы ошап бетми. Тик Сәфәргалин тудырган картиналарга күз йомып булмый бит, рәссамга Харьков өлкәсе комсомол оешмасының Советлар Союзы Герое Александр Зубарев исемендәге премия, аннары Украинаның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә...

Экранда Казан каласының М.Горький исемендәге мәдәният һәм ял паркы күренеше калка. Анда һәркемне үзенә җәлеп итеп торучы обелиск – соңгы сулышында кулын сузган яралы солдат сыны. Бу һәйкәлнең авторы – күренекле сынчы, авылдашыбыз Васыйл Маликов. Шушы хезмәте өчен ул беренчеләрдән булып Татарстан комсомолының М.Җәлил исемендәге премиясенә лаек дип табылды. Аның күренекле шәхесләребез – М.Җәлил, М.Вахитов, Г.Тукайларга эшләгән сыннары иҗатында зур урын тота. Ул беренче бишьеллыклар батыры, авылдашыбыз Мирсәет Ардуановны гәүдәләндергән бюст авылыбызны бизи.

Өченче күренекле рәссам-сынчыбыз Зилфәт Басыйров авылдашларыбыз өчен аеруча якын. Чөнки ул тормышының соңгы көннәренә кадәр авылга кайтып, туганнары белән аралып яши, вафатыннан соң да туган туфрагыннан аерылмый, җәсәде авыл зиратына кайтарып җирләнә. Зилфәт абый бигрәк тә озак еллар мәктәп директоры булып эшләгән Линиф абый Каһиров белән дус була. Сынчыбызның хезмәт җимешләрен авылга кайтарып, музейга урнаштыру да – Линиф абыйның зур хезмәте.

Зилфәт Басыйровның тагын бер таланты – поэзия. Ул үзенең хисләрен шигъри юлларга да салган. Сәхнәдә аның иҗатын тамашачының йөрәк түренә үтәрлек итеп укучыларыбыз Юнысова Таңсылу, Мадъярова Зифа һәм Мәрданов Сәйдәш башкара. Ә Зилфәт абыйны яңа иҗатка этәрүче, илһамландыручы булган Мостай Кәримнең «Айгөл иле» драмасындагы Айгөл образын «Тамчы» балалар театры түгәрәгенә йөрүче Лиана Фәрдиева бик оста итеп башкарды.

Бәйрәмебезгә якташ шагыйрь Фидаил Мәҗитов та кунак булып кайткан иде. Ул 2008 елда ук «Мәйдан» журналында «Өч даһи» дигән зур мәкалә чыгарды. Сәхнә түрендә ул рәссамнар турындагы истәлекләр белән уртаклашты. Икенче кунагыбыз – Актаныштагы «Туган як» музее директоры Мирсил Әһлетдинов музейдагы рәссамнарыбыз иҗатына багышлап төзелгән күргәзмә белән таныштырды.

Кичәбезне бөек мәгърифәтче Ризаэддин Фәхретдиннең бик тә гыйбрәтле сүзләре белән төгәлләдек: «Әдип вә галимнәре булмаган халык – бәхетсез, мәшһүр кешеләрен оныткан халык – көчсез...»

Олуг затларыбызны онытырга, көчсез халык булырга хакыбыз юк!

Гөлсәрия НӘГЫЙМОВА,
Актаныш районының
Иске Кормаш авылы китапханәчесе.

Илһамлы язмышлар

Күңеле бай уллары һәм кызлары күп халык – үзе дә бай бит. Бу хәзинәне колачлап бетерү дә мөмкин түгел. Ул – зур бер дәрья, иге-чиге булмаган кылганлы дала кебек. Кая гына барып кагылсаң да, чык тамчылары кунган үләннәр шигырь сөйли башлар, зәңгәрсу-сары, кызыл-шәмәхә чәчәкләр җырлап җибәрер төсле.

Татарстан китап нәшриятында әле генә дөнья күргән «Күңелгә илһам килә» (2023) китабында әдәби байлыгыбызның кечкенә генә бер өлеше урын алды. Шигырьләр, хикәяләр, повестьлар һәм бер пьеса. Шунысын да әйтергә онытканмын: халкыбыз тормыштан алынган матур тамашалар да ярата бит әле. Дөрес, безнең каләм ияләре драма жанрында күп эшләми, ләкин язганнары югары дәрәҗәдә килеп чыга. Бу уңайдан Раилә Мөхсинованың «Блогер Хәлимә» комедиясе аерым игътибарга лаек. Анда – бүгенге татар авылы, анда яшәүче сезнең һәм безнең кебек үк кешеләр. Нишләтәсең, заман белән бергә авыл да, адәм балалары да үзгәрә. Әллә киресенчәме?.. Раиләнең ике дистә ел дәвамында пьесалар язуы, үз кыйбласына тугры булып алга атлавы яшьтәшләренә дә, яшь язучыларга да үрнәк булырлык.

Айзирәк Гәрәева-Акчураның «Бирүзә йорт», Лира Ибраһимованың «Дежавю, яисә Ике дөнья арасында» повестьлары, Рушания Гыйләҗева, Зәлидә Зарипова, Ильяс Салихҗан хикәяләре ерак үткәндә калган кеше язмышларын бүгенгегә бәйләп торган ныклы күпер кебек тоела. Чәчмә жанрда эшләүче авторларның хезмәт юллары да әдәбият һәм милли матбугат, республикабызның сәнәгать предприятиеләре белән бәйләнгән. Ильяс Салихҗан – озак еллар армый-талмый хезмәт иткән татар матбугаты ветераны, Айзирәк Гәрәева-Акчура – Төркиягә китеп, анда татар халкы, татар әдәбияты өчен зур яңалыклар ачкан каләм иясе. Лира Ибраһимова – тормыш юлын Яр Чаллы һәм Алабуга яклары белән бәйләгән үзенчәлекле прозаик. Рушания Гыйләҗева икътисадчы, Зәлидә Зарипова оператор һөнәрен сайласалар да, алар – күңелләре һәм яшәешләре белән әдәбият кешеләре.

Людмила Аланлы, Люция Әблиева, Гөлназ Әхмәдиева, Алмаз Әхмәтгалиев, Рәмзия Әхмәтова, Надия Вәлиева, Рәсимә Галиева, Лилия Гарифуллина, Алисә Зарипова, Ринат Мәннан, Сүрия Мингатина, Наилә Миңнеханова, Дания Нәгыйм, Тәслимә Низами, Эльвира Сафина, Тойгын, Камил Фазлый, Фәридә Хаҗи, Кәүсәрия Харрасова, Марсель Шәрапов шигырьләрендә, күңел һәм фәлсәфи лирика, милли шигърият белән беррәттән, нечкә юмор-сатира да янәшә атлый. Татарстанның атказанган артисты Тәслимә Низами – популяр җырлар авторы, композитор һәм моңлы тавышлы җырчы буларак киң танылу алган шәхес. Людмила Аланлы да шушы юлдан бара, шигырьләр, көйләр иҗат итә, аларны зур сәхнәләргә алып менә. Һөнәре буенча табиб Ринат Мәннан – шигърият, балалар әдәбияты дөньясын киң колачлап алып барган талантлы каләм иясе, күпсанлы премияләр, әдәби бәйгеләр лауреаты. Иң кечкенә балаларга белем һәм тәрбия бирүче Надия Вәлиева шигырьләре матбугатта еш дөнья күрә, алардагы милли хисләр күңелләрдә пыскып кына янып яткан салмак ялкынны дөрләтеп җибәрә. Фәридә Хаҗиның лирикасы сагышка да сала, сокландыра да. Республикабыз районнарында яшәүче Рәмзия Әхмәтова (Актаныш), Алмаз Әхмәтгалиев белән Лилия Гарифуллина (Балтач), Рәсимә Галиева (Мамадыш), Сүрия Мингатина (Әтнә), Кәүсәрия Харрасова (Саба), Марсель Шәраповларның (Арча) иҗатлары үз төбәкләре өчен горурлык тудыра һәм киң укучыларда зур кызыксыну уята.

Башкортстанда яшәүче авторлар һәрвакыттагыча актив.Бүгенге көндә җиң сызганып иҗат иткән Люция Әблиеваның лирикасы да, юмор-сатирасы да бердәй кызыклы, Наилә Миңнеханованың дини шигырьләре күңелгә иман орлыклары сала, Камил Фазлыйның балаларга аталган әсәрләре кызыклы вакыйгаларга корылуы, заманчалыгы белән үзенә тарта.

Инде мәрхүм булган Тойгын иҗаты тойгы-хисләренең югарылыгы, ихласлыгы белән күңелне әсир итә.

Яшьрәк буын авторлары, Казанда көн күрүче Эльвира Сафина, Алисә Зарипова, Дания Нәгыйм, Гөлназ Әхмәдиева шигърияте заманча формасы, яңача фикри фәлсәфәсе белән аерылып тора.

Кыскасы, төрле төбәкләрдә яшәүче егерме алты автор иҗатын – илһамлы язмышларны берләштергән яңа һәм саллы китабыбыз котлы булсын!

Ленар ШӘЕХ.

Каһәрләнгән таш сере

Лондондагы Тауэрга килүчеләр королева Виктория таҗына игътибар итми калмый. Ул “Кохинур” дигән зур бриллиант белән бизәлгән. Һиндиләр теленнән бу “нур тавы” дип тәрҗемә ителә. Аның авырлыгы 105 карат (21 грамм). Бу бриллиант турында мәкалә һәм китаплар язылган, фильмнар төшерелгән, әмма аның каһәрле тарихы тикшеренүчеләрне һаман да кызыктыра әле. Тарихчылар Уильям Далримпл һәм Анита Анандның Лондонда дөнья күргән хезмәтендә дә асылташ хуҗаларына килгән зыян турында сөйләнә. Риваятьләрдән күренгәнчә, бриллиант берничә гасыр буе Һиндстандагы Мальва елгасы раджаларыныкы булган, бәхетсезлекләр шул вакыттан башланган. Асылташ хуҗалары гел фаҗигале төстә дөнья куйган. 1739 елны Дәһлине фарсылар яулап алган, аның канаулары тулып кан аккан. Бөек Моголларның хәзинәсен 700 фил, 4 мең дөя һәм 12 мең атка төяп, кәрван белән Иранга алып киткәннәр. “Кохинур” явыз Надир-шаһ кулына килеп эләккән. Тиздән ул акылдан яза башлаган, улын үтертеп, күзләрен чокытып алган, тагын иллеләп вәзирен җәзалап үтерткән. Үзен дә озак яшәтмәгәннәр. Шуннан соң асылташ Әфганстандагы Кандагаргa барып җиткән, андагы шаһ аны дивар ярыгына яшереп куйган. Әмма тиздән падишаһның битендә төзәлмәс җәрәхәтләр пәйда булган, шулар әрнүеннән ул җан тәслим кылган. Бриллиант Пенджаб махараджасы Ранджит Сингх кулына эләккән, ул асылташны гел үзе белән йөрткән. Тиз арада үлеп тә киткән. Аннары “Кохинур” өчен көрәштә тагын өч махараджа үтерелгән. Ун елдан соң бриллиант британиялеләр кулына эләккән, каһәре дә аларга күчкән - асылташны Лондонга алып кайтучы суднода ук холера башланган. 1851 елда ташны король зәркәнчеләре кырлап шомарткач, ул ике тапкырга җиңеләйгән, әмма искиткеч нәфисләнгән һәм үтә күренмәлегә әйләнгән. Гасырлар үтсә дә, “ләгънәт төшкән” бриллиант өчен көрәш туктамый. Һиндләр, пакыстанлылар, иранлылар, әфганнар – барысы да аны үзенеке саный һәм Лондоннан әлеге кыйммәтле реликвияне дәгъвалый. Мөгаен, аларның да үлем белән уйнәйсы киләдер.

(“Goldengod.ru”).

Солы боткасы чирдән саклый

Диетологлар көндәлек рационга инде классикага әйләнгән солы боткасын һичшиксез кертергә куша. Янәсе, ул бөтен ризыктан да файдалырак. Ньюкасл университеты галиме Крис Сил, иртән ашалган бер тәлинкә солы боткасы теләсә кайсы кешенең сәламәтлеген яхшырта ала, дип ышандырмакчы була. Доктор әйтүенчә, анда файдалы азык җепселләре, магний, тимер, бакыр, В төркеме витаминнары күп, май һәм шикәр аз. Солы боткасы ашказанын тыгыз гель кебек урап ала һәм туклану хисе тудыра, шул ук вакытта файдалы бактерияләр өчен ризык булып тора, иммун системаны ныгыта, холестерин микъдарын киметә. Тикшеренү көн саен 70 грамм солы боткасы ашаудан кандагы куркыныч холестерин микъдарының 7 процентка кимүен күрсәткән. Профессор Сил әйтүенчә, солыдагы бета-глюкан – онкологик чирләрдән саклый торган сирәк табигый матдәләрнең берсе. Кайбер белгечләр солы боткасында тимернең артык күплегенә хафаланса да, бу арзанлы продукт иң кыйбатлы даруларга көндәш була ала. 14 еллык тикшеренү күрсәткәнчә, солы боткасы йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан да саклый, гомерне озайта. Әмма Британия докторлары әйтүенчә, сәламәтлек өчен никадәр файдалы булуын белсәләр дә, яшьләр солы боткасын яратып ашамый, алар аны артык гади һәм арзанга саный. Азык җитештерүчеләргә дә файдалырак түгел, бәлки табышлырак ризыкны рекламалау һәм сату кызыграк.

(“The Daily Mail”).

Шәп фаразлаган!

Астронавт Нил Армстронг тәүге тапкыр Айга аяк баскач, бөтен Америка гына түгел, тыйнак кына бер британияле – Дэвид Трелфол да ихластан сөенә. Тугыз ел элек, 1960 елда, ул букмекерлык конторасына килә һәм кесәсендәге 10 фунт акчасын нинди дә булса бер гайре табигый нәрсәгә куярга ниятли. Үзенә тәкъдим ителгән исемлектән Дэвид якындагы 10 елда кешенең Айга сәяхәтен сайлап ала. Ставка 1 гә 1000 була. 10 фунт ул чакта шактый зур сумма исәпләнә – эшченең айлык хезмәт хакы уртача 30-40 фунт тәшкил итә. Шулай да Трелфол тәвәккәлли һәм бу уңышлы була – 1969 елда, бәхәс вакыты чыгарга 1 ел кала, астронавтлар Айга менә. Дэвид отыш акчасына зиннәтле спорт автомобиле сатып ала. Әмма озак юана алмый: шул ук елны машинасы белән һәлакәткә юлыга һәм бакыйлыкка күчә.

(“The Mirror”).

Кем тизрәк?

Җиһан әдәбиятында иң данлыклы пари – Жюль Верннең “Дөнья тирәли 80 көндә” романындагы Филеас Фогг бәхәсе әллә никадәр кешене шуны кабатлап карарга этәргән. Чын тормышта җиһан тирәли Фогг рекордыннан тизрәк вакыт эчендә әйләнүчеләрнең беренчесе – Америка журналисты Нелли Блай. 1888 елда ул үзе эшләгән News of the World газетасы мөхәррире Пулитцерга мондый тәкъдим ясый: үзен 200 фунт акча һәм кечкенә генә чемодан белән Фогг маршруты буенча командировкага җибәрүне үтенә. Нелли сәяхәткә әзерләнгән арада, Cosmopolitan журналы да кызыксыну күрсәтә һәм үз хәбәрчесен капма-каршы якка җибәрә. Кайсы беренче әйләнеп кайтыр, дип бәхәсләшәләр. 1889 елның 14 ноябрендә Нелли Augusta Victoria лайнерында юлга чыга. Әлбәттә, чынбарлыкта аны китаптагыдан күпкә азрак маҗара көтә, тик шулай да поездга соңга калу да, Кытайда махау авырулылар колониясенә бару да, Сингапурда өйрәтелгән маймыл сатып алу да, һәм хәтта Жюль Верннең үзе белән очрашу да була. Боларның барысы турында да Нелли таблоидына язып җибәрә тора. Пулитцер укучылар өчен тотализатор да ача. 21 гыйнварда, Тын океандагы давыл аркасында 2 көнгә соңарып, Нелли АКШка кайтып җитә, әмма әле аңа икенче яр буена барып җитәргә кирәк була. Әгәр журналист кыз гадәти тимер юл буенча китсә, 80 көнгә берничек тә сыеша алмас иде, шунлыктан Пулитцер аны шәхси поезд белән кайтарта. Нәтиҗәдә, Нелли сигез көнгә иртәрәк кайтып җитә! Аның Cosmopolitan журналындагы көндәше исә бу вакытта әле һаман Атлантик океанны гизә һәм вакытында кайтып өлгерми.

(“Daily Mail”).

● **Нелли Блай.**

Космонавт этләр

Без космоска беренче булып Белка һәм Стрелка кушаматлы этләр очкан, дип беләбез. Әмма Галәмне гизгән этләр алар гына түгел, бик күп. Аларның шактые аварияләрдә җан тәслим кылган, кайберләре исән калган. Барлыгы утызлап очыш теркәлгән. Формаль космос саналган 100 километр биеклеккә иң беренче булып 1951 елның июлендә Дезик һәм Цыган кушаматлы мәзмайлар күтәрелгән. Ә чын космик орбитага беренче булып 1957 елның 3 ноябрендә Лайка чыккан. Ул чакта әле корабларны орбитадан кире кайтара белмәгәннәр, шунлыктан Лайка капсулада янып үлгән. Мөгаен, шуңа күрәдер, әлеге факт турында сөйләргә яратмыйлар.

(“Мир новостей”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

20 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.40 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Шаян пластилин».
16.00 «Ватандашлар». 16+
17.30 «Татарстан без коррупции». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
21.00 «Заман көзгесе». 6+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру». 16+
23.30 «ТРЮКАЧ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.15 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Родная земля». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Шәүкәт Галиев турында телеочерк. 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Заман көзгесе». 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
21.25, 0.40 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
21.55 «Туган авылым». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СПУТНИКИ». 12+
11.30 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЖЕНА ОФИЦЕРА». 16+
14.35 «Заповедники РФ». 12+
15.00 «Наука Шерлока Холмса». 12+
15.30 «Романовы. Царское дело». 16+
16.30 «МИНДАЛЬНЫЙ ПРИВКУС ЛЮБВИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МОСГАЗ. ПОСЛЕДНЕЕ ДЕЛО ЧЕРКАСОВА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Археология. История с лопатой».
7.35 Черные дыры. Белые пятна.
8.15 Невский ковчег. Теория невозможного. Борис Смелов.
8.45 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.15 «Человек идет на Север».
12.10 «Забытое ремесло».
12.45 Новости. Подробно. АРТ.
13.00, 20.45 «Алексей Баталов. Благодарен судьбе».
13.30 «Москва слезам не верит» - большая лотерея».
14.10 «Быть женой гения...» История любви Софьи и Льва Толстых.
15.00 Линия жизни.
15.55 «Агора».
17.15 Исторические концерты. Дирижеры XX века. Джансуг Кахидзе и Государственный симфонический оркестр СССР.
18.15 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
19.00 Жизнь замечательных идей. «Забыть нельзя запомнить».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
21.20 «Хождение по мукам. Две жизни сестёр Крандиевских».
22.05 «Сати. Нескучная классика...»
22.50 «КОРОТКИЕ ИСТОРИИ».
23.35 «Всюду деньги, господа!»

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
22.15, 0.00 «ЛИХАЧ». 16+

Сишәмбе

21 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.15 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 18.45 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.15, 0.25 «Если хочешь быть здоровым». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР». 16+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Мин татарча өйрәнәм».
17.15 «Казаннан - казанга». 16+
17.45, 0.40 «Таяну ноктасы». 16+
19.15 Хоккей. «Динамо» (М) - «Ак Барс». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.00 «ТРЮКАЧ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.30, 18.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Халкым минем». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «СПУТНИКИ». 12+
11.30 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЖЕНА ОФИЦЕРА». 16+
14.35 «Заповедники РФ». 12+
15.00 «Наука Шерлока Холмса». 12+
15.30 «Романовы. Царское дело». 16+
16.30 «МИНДАЛЬНЫЙ ПРИВКУС ЛЮБВИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «КУМИР». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МОСГАЗ. ПОСЛЕДНЕЕ ДЕЛО ЧЕРКАСОВА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Археология. История с лопатой».
7.30 Легенды мирового кино.
7.55, 23.40 «Всюду деньги, господа!»
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.15 «Всего несколько слов в честь Мастера... М. Булгаков».
12.45 Новости. Подробно. Книги.
13.00, 20.45 «Алексей Баталов. Благодарен судьбе».
13.35, 13.55, 14.15 «ПОРУС».
14.35 «Игра в бисер» «Поэзия Франсуа Вийона».
15.20 «КОРОТКИЕ ИСТОРИИ».
16.15 «Сати. Нескучная классика...»
17.15 «Эрмитаж».
17.45 Исторические концерты. Дирижеры XX века. Геннадий Рождественский и Государственный симфонический оркестр Министерства культуры СССР.
18.45 «Забытое ремесло».
19.00 Жизнь замечательных идей. «Мир запахов».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
21.20 «Своими глазами. Нами Микоян».
22.15 «Белая студия».
23.00 «КОРОТКИЕ ИСТОРИИ».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
22.15, 0.00 «ЛИХАЧ». 16+

Чәршәмбе

22 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ». 16+
11.00, 0.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР». 16+
13.00, 0.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Шома бас».
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Гаилә учагы». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 Телефильм. 12+
21.00 «Ватандашлар». 16+
23.00 «ТРЮКАЧ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10, 8.30, 18.20, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Зөләйха Хисмәтуллина турында телеочерк. 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 21.25 «Кунак БИТ Шоу». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00, 0.15 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «КУМИР». 16+
11.30 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЖЕНА ОФИЦЕРА». 16+
14.35 «Заповедники РФ». 12+
15.00 «Жизнь замечательных идей». 12+
15.30 «Романовы. Царское дело». 16+
16.30 «МИНДАЛЬНЫЙ ПРИВКУС ЛЮБВИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
20.00 «Как убили Джона Кеннеди». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МОСГАЗ. ПОСЛЕДНЕЕ ДЕЛО ЧЕРКАСОВА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Археология. История с лопатой».
7.30 Легенды мирового кино.
7.55, 23.35 «Всюду деньги, господа!»
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.15 «Княгиня Наталья Петровна».
12.10, 18.45 «Забытое ремесло».
12.45 Новости. Подробно. Кино.
13.00, 20.45 «Алексей Баталов. Благодарен судьбе».
13.35, 13.55, 14.15 «ПОРУС».
14.35 Линия жизни.
15.30, 22.50 «КОРОТКИЕ ИСТОРИИ».
16.10 «Белая студия».
17.15 «Библейский сюжет».
17.45 Исторические концерты. Дирижеры XX века. Клаудио Аббадо и Молодёжный оркестр имени Густава Малера.
19.00 Жизнь замечательных идей. «Боль: враг или друг?»
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
21.20 Абсолютный слух.
22.05 Власть факта. «Сила и слабость советского планирования».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
22.15, 0.00 «ЛИХАЧ». 16+

Пәнҗешәмбе

23 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.15 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 18.45 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Память сердца». 16+
14.15 «Классный час». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.10 «Сөенеч».
15.15 «Учимся вместе» һәм «Музыкаль тәнәфес».
17.15 «Точка опоры». 16+
19.15 Хоккей. «Куньлунь Ред Стар» - «Ак Барс». 6+ По окончании - «Погружение на 100». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Безнең Республика - безнең гамәл». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.15 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.30, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.30 «Гаилә учагы». 16+
10.00 «Туган авылым». 12+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.20 «Кунак БИТ Шоу». 16+
19.15, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 16+
21.25 «Йөрәктән-йөрәккә». Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) турында телеочерк. 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «КУМИР». 16+
11.30 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
12.30, 18.30 «Подружки». 16+
13.00, 23.50 «ЖЕНА ОФИЦЕРА». 16+
14.35 «Заповедники РФ». 12+
15.00 «Жизнь замечательных идей». 12+
15.30 «Романовы. Царское дело». 16+
16.30 «МИНДАЛЬНЫЙ ПРИВКУС ЛЮБВИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+

10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Как убили Джона Кеннеди». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МОСГАЗ. ПОСЛЕДНЕЕ ДЕЛО ЧЕРКАСОВА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.00 «Археология. История с лопатой».
7.30 Легенды мирового кино. Михаил Ромм.
7.55, 23.35 «Всюду деньги, господа!»
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.15 «В мире животных. Дальний Восток. Приморский край».
12.10, 18.45 «Забытое ремесло».
12.45 Новости. Подробно. Театр.
13.00, 20.45 «Алексей Баталов. Благодарен судьбе».
13.35, 13.55, 14.15 «ПОРУС».
14.35 Абсолютный слух.
15.20 «КОРОТКИЕ ИСТОРИИ».
16.10 «2 Верник 2». Ольга Перетятько.
17.15 Моя любовь - Россия! «Оренбургское казачество».
17.45 Исторические концерты. Дирижеры XX века. Бернард Хайтинк и Лондонский филармонический оркестр.
19.00 Жизнь замечательных идей. «Сколько секунд в сутках».
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Кирилл Рябов. «Лихо».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
21.20 «Москва слезам не верит» - большая лотерея».
22.00 «Энигма. Алим Гасымов».
22.45 «ВСТРЕЧАЙТЕ ПРОЕЗДОМ».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БАЛАБОЛ». 16+
22.15, 0.00 «ЛИХАЧ». 16+

Җомга

24 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Төймә».
17.30 «Кто мы татары?» 12+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Наши герои». 16+
21.00 «Юлчы». 16+
22.10 «КВН РТ-2023». 16+
22.40 «СЮРПРИЗ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.30, 18.20, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.30, 16.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.00, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Сибгат Хәким турында телеочерк. 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 21.55 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
18.00 «Яңалыклар». 12+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Туган җир». 12+
21.25 «Кто мы татары?» 12+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «КУМИР». 16+
11.30 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «ЭТО НЕ НАВСЕГДА». 12+
14.35 «Заповедники РФ». 12+
15.00 «Жизнь замечательных идей». 12+
15.30 «Романовы. Царское дело». 16+
16.30 «МИНДАЛЬНЫЙ ПРИВКУС ЛЮБВИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Фантастика». 12+
23.40 «Матадор». «Объединенные цвета Оливьеро Тоскани. Конец века по Годфри Реджио». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.00 «Да, скифы - мы!»
7.40, 12.45 «Забытое ремесло».
7.55 «Всюду деньги, господа!»
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.20 «СУД ЧЕСТИ».
12.10 Цвет времени. Караваджо.
13.00, 20.45 «Алексей Баталов. Благодарен судьбе».
13.35, 13.55, 14.15 «ПОРУС».
14.35 Власть факта. «Сила и слабость советского планирования».
15.20 «ВСТРЕЧАЙТЕ ПРОЕЗДОМ».
16.15 «Энигма. Алим Гасымов».
17.15 Письма из провинции.
17.45 Исторические концерты. Дирижеры XX века. Евгений Мравинский и Академический симфонический оркестр Ленинградской филармонии.
18.20 «Царская ложа».
19.00 Жизнь замечательных идей. «Биохимия чувств».
19.45 Линия жизни. Олег Артемьев.
21.15 «ЛЕТЯТ ЖУРАВЛИ».
22.50 «2 Верник 2».
23.25 Клуб «Шаболовка, 37».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «БАЛАБОЛ». 16+
22.15 «ЛИХАЧ». 16+

Шимбә

25 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Siңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Музыкальный майдан». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «Әнкәемнең ак күлмәге». Гүзәл Идрисова концерты. 16+
16.45 Хоккей. «Витязь» - «Ак Барс». 6+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «ДЕЛО В ТЕБЕ». 16+
23.35 «СТЕЙК ОТ КУТЮР». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Сайра, сайра син, сандугач!» Хәмдүнә Тимергалиеваның иҗат кичәсе. 16+
7.00, 15.00 «Siңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Кайда сез, яшьлек еллары». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 16+
17.15 «Казаннан казанга». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Яратып яшик». Раяз Фасихов концерты. 16+
22.35 Спектакль «Ак калфагым төшердем кулдан...» 16+

«ЭФИР»
5.00 «Заповедники РФ». 12+
5.30 «Водяная». 12+
7.00 «Лекс и Плу: Космические таксисты.». 6+
7.30 «Фиксики».
8.00 «А дома лучше». 12+
8.50 «ТРАВА ПОД СНЕГОМ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЕСЛИ БЫ ДА КАБЫ…». 12+
14.45 «Первые в мире». 12+
15.00 «Обыкновенное чудо академика Зильбера». 12+
15.50 «А СНЕГ КРУЖИТ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «СЕМЕЙНОЕ ОГРАБЛЕНИЕ». 16+
22.35 «СЛУЧАЙНЫЙ МУЖ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Наше всё». 12+
11.05 «ПроУют».
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «Как долго я тебя искала...» 12+
14.15 «9 ДНЕЙ ОДНОГО ГОДА». 12+
16.30 «Горячий лед». Фигурное катание.
18.20 «Я люблю мою страну».
19.20 «Эксклюзив». 16+
20.05 «Кто хочет стать миллионером?»
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.20 «КАМОН КАМОН». 18+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.50 «В кругу друзей».
12.50 «Доктор Мясников». 12+
14.50 «Юморина». 16+
17.50 «Привет, Андрей!». 12+
21.00 «ЖИЛИЩНЫЙ ВОПРОС». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 «Таёжная сказка».
7.15, 7.35, 7.55, 8.15, 8.35, 8.55 «ПОРУС».
9.15 «Мы - грамотеи!»
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «ЛЕТЯТ ЖУРАВЛИ».
11.55 Человеческий фактор. «Наследники - Тевтонского ордена».
12.25 Черные дыры. Белые пятна.
13.05 «Волшебные песни животных с Дэвидом Аттенборо».
14.00 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
14.40 «ВОСКРЕСЕНИЕ».
18.00 Большая опера.
19.45 «МАМАН».
22.00 «Агора».
23.00 Спектакль «Последний поезд».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
7.30 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.10 «Попутчик». 16+
14.20 «Игры разумов».
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Секрет на миллион». 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Суперстар!» 16+
23.40 «Ты не поверишь!» 16+

Якшәмбе

26 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Риваять» төрки-татар этникасы ансамбле концерты. 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 Сөенеч.
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы-шоу».
9.45 «Сәләт».
10.15 «Дуслык иленда». 12+
11.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.45 «Татар сүзе». 6+
14.00 «Безнең Республика - безнең гамәл». 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Профсоюз - союз сильных». 12+
20.45 «Батырлар». 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ПАРИЖ, ВИНО И РОМАНТИКА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять».
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Кто мы татары?» 12+
8.00 «Чын йөрәктән» Габделфәт Сафин концерты. 16+
9.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Сибгат Хәким турында телеочерк. 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 16+
14.20 Концерт «Әниләр һәм бәбиләр». 6+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 «Эльмир Низамов һәм дуслар». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Заповедники РФ». 12+
5.30 «Наша марка». 12+
5.45 «Озеро героев». 6+
7.00 «Лекс и Плу: Космические таксисты.». 6+
7.30 «Фиксики».
8.00 «А дома лучше». 12+
8.50 «А СНЕГ КРУЖИТ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «МИЛЛИОНЕР». 16+
14.50 «Блин.Ком. Некоторые любят погорячее». 16+
15.50 «ТРАВА ПОД СНЕГОМ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ОСОБЕННЫЕ». 16+
22.50 «ЕСЛИ БЫ ДА КАБЫ…». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Легкие деньги». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.05 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
13.30 «Машков». 12+
14.25 «ВОР». 16+
16.20 «Горячий лед». Фигурное катание.
19.00 «Перепой звезду». 12+
21.00 «Время».
23.00 «Что? Где? Когда?»

«РОССИЯ»
6.10 «ВРЕМЯ СОБИРАТЬ». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00 Вести.
11.50 «Большие перемены».
12.50 «БЕЗ ВИНЫ ВИНОВАТАЯ». 12+
16.55, 19.00 «Песни от всей души». 12+
18.00 «Всероссийский конкурс юных талантов «Синяя Птица».
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.15, 7.35, 7.55, 8.15, 8.35, 8.55 «ПОРУС».
9.15 Диалоги о животных.
9.55 Больше, чем любовь.
10.40, 23.50 «АЛЕШКИНА ЛЮБОВЬ».
12.05 «В поисках «Эйры».
12.50 Невский ковчег. Теория невозможного. Вадим Вилинбахов.
13.20 «Игра в бисер» «Алексей Толстой. «Граф Калиостро».
14.00 «Коллекция».
14.35 «Иегуди Менухин. Скрипка столетия».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.15 «Первые в мире».
17.35, 20.25 Линия жизни.
18.25 «Романтика романса».
19.30, 19.45 Новости культуры.
21.20 «СЛУЖИЛИ ДВА ТОВАРИЩА».
22.55 Балет «Идиот».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Шоу Аватар». 12+
23.15 «Звезды сошлись». 16+

Аңлап кылынган акылсызлыклар

Исерек килеш явызлык кылучыларның күбесе тәүбә итә, аек булсам алай кыланмас идем, дип, барысын да сәрхүшлеккә сылтый. Эш узгач, ошбу аклануларның файдасы тими, билгеле.

Быел 16 июль иртәсендә Бөгелмәдәге «Изобилие» кибетенә, сатучы Анна әйтмешли, «местный алкаш» Юрий Иванов килеп керә. Өлкән яшьтәге әлеге сатып алучыны «наглый» дип бер сүз белән бәяли ул. Әмма аракыны оятсыз булганы өчен түгел, ә сәгать 8 тулмаганга күрә сатмый. Шуннан соң 62 яшьлек карт: «Бир бер яртыны, хәзер 15 елга китәм», – ди һәм дусты «Женя Гусь»не чәнчеп үтерүен сөйләп бирә. Анна Евгений Гусевны да яхшы белә, кибеткә, башлыча, Ю. Иванов белән кереп йөргән бу ир-атны тыныч холыклы, хәтта зыялы кеше дип атый. Юрий сөйләгәннәргә ышанмый ул, әйтүенчә, эчә-эчә башы киткән, дип уйлый.

Ю.Иванов кибеткә килешли очраган олы яшьтәге В.Тюряевка да әйткән була бу хакта. Анысы да чынга алмый, полициягә шалтыратырга кушып, өенә кайтып китә. Аннан соң Юрий абзый күрше ханымга тиздән полиция бик озакка алып китәчәген җиткерә, буш калачак фатиры ачкычларын бертуганының Алабугада яшәүче кызы Эльмирага тапшырырга куша.

Ю.Иванов «112» телефонына үзе шалтырата. Ашыгыч ярдәм табиблары кухня өстәле артында стенага сөелеп ярымутырган хәлдәге 1973 елгы Е.Гусевны күрә, әмма аңа ярдәм итүнең хаҗәте калмый. Евгений күкрәгендәге бер җәрәхәт аркасында үлгән була. Суд-медицина эксперты бавыр зарарлану, эчкә кан тулу, нәтиҗәдә нерв системасы, йөрәк туктау турында белдерә. Ю.Иванов табибларга шешәдәше үзенә-үзе кадады дисә, полиция хезмәткәрләренә исә эчеп утырганда Евгенийның акыл өйрәтә башлавы сәбәпле низаг чыгуын, шуннан соң пычак белән үзе дустының күкрәгенә чәнчүен сөйләп бирә, димәк, гаебен шунда ук таный, соңрак тәүбә итүен, үкенүен дә белдерә.

Тикшерү комитетының Бөгелмә бүлегеннән Д.Кабулҗанова 1960 елгы абзыйга шул көнне үк аңлы рәвештә кеше үтерүдә беренчел гаепләү белдерә, шәһәр суды аны сак астына алырга карар бирә. Әлбәттә, Ивановның бик озакка ябылуын белдерә бу. Эчүе аркасында еш кына административ җаваплылыкка тартылса да, төрмә сәндерәсендә яткан кеше түгел ул үзе. 2000 елда кыйнаган, үтерү белән янаган өчен кузгатылган бердәнбер җинаять эше судта туктатылып, җәзасыз калган була.

Гадәттән тыш хәл сәрхүшләрнең гадәти көнендә килеп чыга. 15 июльдә Ю.Иванов, Е.Гусев һәм Сергей, Александр атлы яшьрәк сәрхүшләр иртән үк ишегалдында утырып кәеф-сафа кора, алдан сыра, аннары литр ярым аракы чөмерә. Соңгы икесе төш вакытында «өлгереп» өйләренә кайтып китә. Кич белән шешәдәшләр Иванов фатирында тагын җыелыша, лаякыл исерек хуҗа белән Гусевны калдырып, яшьрәкләр алданрак чыгып китә. Ю.Иванов кадавын яшермәсә дә, пычакны Женя кулыннан тартып алып чәнчедем дип, гаебен шомартырга да омтыла. Кадагач, Е.Гусев өстәл артында утырып калды, пычакны раковинага ташлап йокларга яттым, иртә белән шул ук урындагы дустымның үле икәнен күрдем, ди ул.

* * *

Чистай районындагы Татар Елтаны авылында шешәдәшен теге дөньяга озата язган 1987 елгы Рөстәм Гайфетдинов вакыйганы томанлы хәтерлим дисә дә, авылдашын яралавын таный, аннан гафу үтенүен дә белдерә. Тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Р.Исмәгыйлев ошбу явызлыкка кеше үтерергә омтылыш ясау дип бәяләгәч, Р.Гайфетдинов үтерү нияте булуын кире кагып, тән җәрәхәтләре ясаган өчен җиңелрәк җәзага өметләнә. Әгәр зарар күрүче 33 яшьлек Рузил Миассаровның сул кулы белән муенымнан урап алып суярга кереште, дип әйтүен, анда пычак белән ясалган өч җәрәхәт булуын, аның сәламәтлегенә авыр зыян ясалуын искәртсәк, гаепләү ягы нәтиҗәсе белән килешмичә дә булмас.

Р.Гайфетдинов тумышы белән Чиләбе өлкәсеннән, 2001 елда гаиләләре белән Татар Елтанына күченеп кайткан. Балачагыннан психиатр күзәтүендә торса да гадәти мәктәптә укыган, тракторчы һөнәре алган, 2017 елда әлеге исәптән төшерелгән. Ләкин авылда аның турында бәйләнчек, үчле, исерек вакытында теләсә кемгә сугарлык котырынкы, дигән фикерне әйтүчеләр бар. Моңа аның үтерү белән янаган һәм кешегә уртача дәрәҗәдәге тән җәрәхәтләре ясалган өчен ике тапкыр хөкемгә тартылып иректән мәхрүм итү белән бәйле булмаган җәзалар алып котылуын да өстик. 27 яшендә үзеннән күпкә өлкән ханымга рәсми рәвештә өйләнә ул. Соңгы вакытта Нина (кайбер исемнәр үзгәртелә) Казандагы улы янында яши, авылдагы йортына ял көннәрендә генә кайта, ул юкта әнисе янында торган законлы ире дә килә анда.

26 июльдә дә бергә була алар. Рөстәм иртә белән кибеткә ашыга, анда бераз өлкәнрәк авылдашы Ринатны очрата, аның белән бер литр аракы алып, 57 яшендәге ялгызак Р.Ситдыйковка барып керәләр. Хуҗа инде шактый салмыш була, бераз утыргач, йокларга түнә. Исерә башлагач Ринат та ял итәргә ята. Ләкин Гайфетдиновка чәкештереп эчәргә дус табыла: гөнаһ шомлыгына, бер «чәкүшкә» тотып Рузил Миассаров килеп керә, кибеткә барып килергә дә туры килә.

Янәшә өйдәге сәрхүшләр җыелган җиргә Нина да кергәләп йөри, ләкин эчү өчен түгел, үз йомышлары белән. Әлбәттә, ирен орышып һәм әнисенә әйтү белән өркетеп тә карый, ләкин эчкән саен фикерләү сәләтен җуя барган сәрхүшләр колак салмый. Әйтүенчә, Нина бер мәлне Р.Миассаровның ирен этеп егуын тәрәзәдән күреп йөгереп керә, аңа аягына басарга ярдәм итә, хак булса, аны күргәч, Рузил кулындагы пычакны өстәлгә куя. Тиздән чыгып чабарга туры килә аңа, чөнки Р.Гайфетдиновның теге хәтәр әйберне алып шешәдәшенең муенына кадавын күреп ала. Яралы Р.Миассаров һөҗүм итүчене читкә этәреп, ишегалдына чыга.

Шул мәлдә күрше йортта яшәүче Раилә ханым урамда сул кулына шешә, уңына пычак тотып алпан-тилпән баручы Р.Гайфетдиновны очрата, димәк ки, анысы да өйдән чыгып тая. Ошбу апа каршыдагы өйгә кереп киткән Нинаны да күрә, янәшә өй ягындагы шау-шуны ишетеп шунда керә һәм телефоныннан ашыгыч ярдәм чакырып азапланучы канга баткан Р.Миассаровны күрә. Бик тиз арада килеп җиткән авыл фельдшерына да булыша әле ул. Ашыгыч ярдәм табиблары авыр хәлдәге ир-атны сырхауханәнең реанимация бүлекчәсенә илтә.

Р.Миассаровның вакытында ярдәм күрсәтелү аркасында гына исән калуы бәхәссез. Экспертиза муенындагы өч яраның аркылыга ясалуын күрсәтә, бу инде зарар күрүче әйткәннең хак икәнен дә раслый. Шулай ук йоткылыкка да зарар килгән була. Ярый әле йокы артериясе һәм башка төп кан тамырлары киселми, юкса, яралыны коткарып та булмас иде.

Психиатрлар Р.Гайфетдиновны җинаять кылганда үз гамәлләрен аңлarлык хәлдә булган, дип белдерә. Әлбәттә, аның эчкечелеккә бәйле икәне, явызлыкны да гади исерек хәлдә эшләве әйтелә. Әлбәттә, закон күзлегеннән караганда гына шулай бу. Чынлыкта төп сәбәп «гади исереклек»тә. Бөгелмә, Чистай шәһәр судларында әлеге эшләр буенча хөкем чыгарылмаган әле.

* * *

Ошбу зәхмәтнең адәм баласын нинди хәлгә төшерүен Баулыда булган балталы очрак та бик ачык күрсәтә. 1983 елгы Павел Никифоров быел 26 март кичендә фатирларында хатыны һәм өч кунак белән эчеп утыруларын өстән-өстән генә хәтерли һәм төннең икенче яртысында «сожительница» Лилия һәм аның абыйсы Вячеслав каяндыр кайтып кергәч уянуын белә. Ә аларның аның балта тотып һөҗүм итүе аркасында Вячеславтагы тән җәрәхәтләрен тектереп сырхауханәдән кайтып килешләре була.

П.Никифоров моңа кадәр дә җиде мәртәбә хөкемгә тартылган кеше үзе, ләкин урлау, кыйнау кебек «вак» җинаятьләре өчен җиңелчә җәзалар белән котылып килгән. Бары тик бер тапкыр шартлы хөкем таләпләрен үтәмәгән өчен өч елга колониягә утыртылган. Бу юлы исә балта белән ташланган бәндә алдан ук сак астына алына, чөнки тикшерү комитетының Азнакай районара бүлеге тикшерүчесе Олег Смирнов ошбу гамәлгә үтә кырыс җәза каралган аңлы рәвештә кеше үтерергә омтылу дип бәяли.

Тикшерү барышында ачыкланганча, 26 март кичендә Павел хатыны Лилия һәм аның Алинә, Светлана атлы дуслары белән фатирларына кайталар. Әйтүләренчә, ошбу төркем ул чакта әйбәт үк салмыш була инде. Тиздән хәмерле мәҗлеснe дәвам иттерү җае чыга, чөнки анда хуҗабикәнең абыйсы Вячеслав Кириллов килеп керә. Абыйлы-сеңелле ике кеше кибеттән өч ярты аракы алып кайта. Әлбәттә, утыра, эчә торгач, барысы да «өлгерәләр». Иң алдан җәелмә кәнәфигә ятып, кунак Кириллов йокыга тала, башкалар да ятарга хәзерләнә.

Әйтелгәнчә, П.Никифоров шул чакта кабынып китү сәбәбен дә, башкасын да хәтерләми. Әмма аеграк булган хатыннар шактый төпле фикер йөртеп вагыйганы ышанырлык итеп сурәтли. Ягъни йокы бүлмәсендә сыйланып утырганда Павелның кунак Вячеславка җикеренә, «зарублю» дип кычкыра башлавын хәтерлиләр. 2019 елда бәрелешкән идек, шуннан соң мөнәсәбәтләребез начарайды, дип моны Вячеслав та раслый, Павелның шуны искә алып холыксызлануын әйтә. Әмма уртак тырышлык белән ул вакытта тынычландыралар аны. Ләкин төнге сәгать 12 нчедә йоклап яткан кунакның гырлый башлавына ачуы чыккан хуҗа кинәт коридордагы шкафтан агач саплы балта алып кереп, аның йөзе белән яткан кунакның башына суга. Күрәсең, бар көченә ормый һәм теләгәнчә эләктерә дә алмый. Юкса, Вячеслав сикереп торып балтаны тартып алырлык куәт таба алмас иде. Шуңа күрә, колак, муен, иңбаштагы яра бик тирән һәм куркыныч булмый.

Бу хәл өйдә ыгы-зыгы куптара, билгеле. Котлары алынган хатыннар ашыгыч ярдәм чакыра, канны туктатып азаплана. Тиешле ярдәм сырхауханәдә күрсәтелә: кан агу туктатыла, яра эшкәртелеп тегелә, В.Кириллов анда калырга теләмичә сеңлесе фатирына кайта. Экспертиза әлеге җәрәхәт сәламәтлеккә җиңел дәрәҗәдәге зыян салган дип белдерде. Шулай итеп В.Кириллов чагыштырмача җиңел котыла. Ә менә аек булсам мондый явызлыкка бармас идем дип тәүбә итеп торган П.Никифоров, гадиләштереп әйткәндә, кеше үтерергә керешкән дип табыла һәм 6 елга ирегә белән хушлаша.

Наил ВАХИТОВ.

Энҗе-мәрҗән калфагым...



Чистай үзешчәннәренең Казандагы Ленин мәдәният сараенда узган смотр-конкурсында нинди генә хикмәтләр юк иде, әмма барыннан да бигрәк тыйнак кына калфак чигеп утыручы кыз игътибарны җәлеп итте. Дөрес, хәзер калфак чигү белән берәүне дә шаккаттырып булмый, кул осталарыбыз буа буарлык. Ләкин бу кызның калфаклары бөтенләй башка, моңа кадәр күргәннәргә охшамаган. Чигүченең бай күңеле, нечкә зәвыгы ярылып ята. Өстәвенә, калфаклар белән тулган өстәлдә тамчы бөртеге кебек бер-берсенә охшаган ник ике данә булсын! Аларны нәни генә шедеврлар дисәк тә, һич арттыру булмас.

Тик чигүчесе Фәнзилә Данданова аз сүзле булып чыкты. Чигәргә махсус өйрәнмәгән, мәдәниятка бернинди катнашы юк. Калфакларны буш вакытларында күңел булсын өчен генә чигә. Авыл Сабан туйларына алып чыга, сораучы булса, аларга да чигеп бирә.

– Төп һөнәрең нинди? - дип кызның серен ачмакчы булам.

– Хисапчы да, пешекче дә булып эшләдем, – ди.

Юк инде, дим үземә эчтән генә, мондый калфакларны гади кеше чигә алмый. Экспозицияне урыйм да, тагын серле кыз янына әйләнеп киләм.

– Чистайның кайсы авылыннан? – дип сорыйм.

Нарат Елгадан икән. Әһә, минәйтәм, бертуган Закировлар авылы бу. Шамил Закиров байтак еллар Камал театрын җитәкләп, кешелеклеге, ярдәмчеллеге белән артистлар арасында олы хөрмәткә ия булды. Бүген дә гел җылы хисләр белән генә искә алалар. Ринат Закиров Бөтендөнья Татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе буларак бөтен дөнья буенча сибелеп яшәүче милләттәшләребезне берләштерү өчен күп эшләр эшләде, «Казан» милли мәдәният үзәгенең җитәкчесе вазыйфасында Ленин бабай рухын саклаган бинага милли рух индерде. Кызның сорауларга артык хискә бирелмичә, кыска һәм төгәл җавап бирүендә, үз-үзен гади, әмма горур тотышында да бу шәхесләр белән охшашлыгы бар сыман тоела. Бер чишмә суын эчеп үскәнгәдер, күрәсең. Һәр районда шул як кешеләренә генә хас сыйфатлар була бит.

Кызыксыну артканнан-арта бара.

– Бу кадәр калфакны кая куеп бетермәк кирәк? – дим аптырагач.

– Соратучылар күп, «Хыял» вокаль ансамбленә калфаклар чигеп бирдем, аны беләсезме икән?

Белмәскә! Чистай районының данлыкны «Хыял»ына Ленин мәдәният сараенда узган смотр-конкурста да бөтен халык шаккатып карады. Шулкадәр чиста тавыш, белмәгән җырлары юк, борынгы җырларны торгызулары үзе бер мәртәбә! Шулай итеп әңгәмәдәшем зур, профессиональ сәхнәләрдә чыгыш ясый торган «Хыял» ансамблен киендерүче, бизәндерүче булып чыкты бит әле.

Менә сиңа пешекче, менә экономист! Хәзер инде яныннан һич китеп булмый, сорау артыннан сорау бирүне дәвам итәм. Ни кызганыч, кызның вакыты тар булып чыкты, гафу үтенеп, янымнан йөгереп диярлек китеп барды.

Нәкъ шул вакытта смотр-конкурсның жюрие экспозицияне карап бетереп, тамаша залына кереп китте. Концерт башлана икән. Кәеф кырылды. Хикмәтле калфакларның серен чишмичә китәргә туры киләчәкме инде? Юк, китмим, кызны концерттан соң барыбер тагын бер күрәм, минәйтәм. Аңа кадәр исә тамаша залына кереп торудан башка чара калмады. Сәхнәгә бер-бер артлы коллективлар чыга. Биилəр, җырлыйлар. Ә күңелдән һаман серле калфаклар китми. «Народные узоры» дигән нинди бию ансамбленигълан иттеләр. Карап-карыйк соң анысын да, дип битараф кыяфәттә сәхнәгә күз ташлыйм. Һәм шулвакыт имәнеп киттеп. Бәрәкалла! Сәхнәдәге биючеләр арасында калфак чигүче кыз да бар. Бии генәме соң? Бөтенесеннән уздырып бии! Ансамбльнең җитәкчесе кем диделәр әле? Рәзит Минһаҗев бугай ялгышмасам. Рәзит. Сәер исем. Актаныш кешесе булса, гаҗәпләнмәс идең... Туктале! Казанда бер Рәзит бар иде бит. Казан театр училищесын тәмамласа да, биюче булып китте. Нинди генә биюче әле! Пародияле биюләр остасы.

Аеручa шәрык биюләрен оста бии иде. Чын елан тотып сәхнәгә чыгулары һаман да истә. Ул да Чистайдан иде бугай...

Ахыр чиктә очына чыктым бит. Рәзит дигәннәре, чыннан, да Казанны гына түгел, Татарстанны шаулаткан Рәзит Минһаҗев булып чыкты. Хәзер туган ягына әйләнеп кайткан. Ансамбль җитәкли. Ә калфакчы кызым аның бертуган апасы! Үзе калфак чигә, үзе бии. Димәк, бер гаиләдә – ике талант. Нәкъ Закировлар кебек.

Әйттем бит, гади генә калфаклар түгел бу...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип
Мөнирә СӘГЫЙДУЛЛИНА

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;
222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;
222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;
222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 17.11.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2550 данә

Заказ 2644

16+